Безнең МИРАС

01

гыйнвар 2015

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ТАРИХИ, МӘДӘНИ, ПЕДАГОГИК, ДИНИ МИРАС, ТӨПЛЕ ФАРАЗ, ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

Зариф Бәшири эзләре буйлап...

2014 елның 23 нче декабрендә Кайбыч районының Олы Кайбыч урта гомуми белем бирү мәктәбендәТатарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы, Чувашиянең мәгариф хезмәткәрләре, Башкортстанның һәм Татарстанның муниципаль районнары мәгариф идарәләренең милли мәгариф һәм төбәкара хезмәттәшлек буенча методистлары катнашында «Зариф Бәшири эзләре буйлап...» дип аталган семинар уздырылды. Тугандаш өч республика мөгаллимнәре үзара киңәш-табыш вә тәҗрибә алышты. Кайбыч районы башлыгы Альберт Рәхмәтуллин белән «Безнең мирас» журналы вәкиле күренекле әдип һәм мәгърифәтче Зариф Бәширинең бай мирасын халыкка кайтару мәсьәләсен күтәрде.

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдмәнд

Безнең МИРАС 12 +
01(36)
гыйнвар 2015

Журнал «ТАТМЕДИА» ААҖ
тарафыннан гамәлгә куелды.
2012 елның май аеннан чыга.

13

28 КАРА ГЕНЕРАЛ.
Рәис Зарипов

84 ИЛ КЫЗЫ.
Рухия Ахунҗанова

ЭЧТӘЛЕК

3 **Баш мөхәррир мөнбәре**

ТАРИХИ МИРАС

4 **«Инде алмаган ни калды?»**
8 **Мишәрләр.** *Зариф Бәшири*
13 **Гыйлем хәзинәсе, хәтер сакчысы...** *Ирек Һадиев*

ПЕДАГОГИК МИРАС

18 **Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз, дигән сүз — раст сүз**
25 **Әхлак.** *К.Бикколый, Г.Госмани*

ҖИҢҮ — 70!

28 **Кара генерал.** *Рәис Зарипов*
40 **Дәһшәтле еллар хатлары.** *Әлфия Шамова*
46 **«Гөлсем өйгә кайтадыр».** *Равил Сәйфетдинов*
49 **«Минем шәҗәрәдә — Бөек Ватан сугышы еллары» конкурсы нигезнамәсе**

ХӘТЕР САНДЫГЫ

50 **Сүз һәм сурәт.** *Рәдиф Сәгъди*

ӘДӘБИ МИРАС

52 **Кутадгу билик (Котайткыч белем).** *Йосыф Баласагуни*
58 **Солдат.** *Гаяз Исхакый*
63 **Киткәннәрнең юлы уралы...** *Факил Сафин*
68 **Мөхәммәт Шәйхи шигырьләре**
70 **Ачы тәҗрибә авазы.** *Габдулла Тукай*
72 **Тукай шигърияте — Төркиядә.** *Алия Мөбарәкшина*
76 **Тукай энциклопедиясе.** *Зөфәр Рәмиев*

БЕР БӘЙЛӘМ БЕРКЕТМӘ

78 **«Кыйссаи Йосыфны» нәшер итү кыйссасы**
83 **Хәситә.** *Руфия Мөхетдинова*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб ЛЕРОН)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары-җаваплы сәркатип
Марат Закиров
(Марат Закир)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр Комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Ирек Миннәхмәтов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары — ТР фән һәм мәгариф министры)
Фәрит Шаһиәхмәтов
(«ТАТМЕДИА» ААҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы,
2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

СӘНГАТИ МИРАС

84 **Ил кызы.** *Рухия Ахунҗанова*
89 **«Яшәү барыбер кызык».** *Айдар Фәйзрахманов*

ХӘТЕР САГЫНДА

93 **Мавзолей.** *Фазыл Искәндәр*
95 **Туган як һәм әдип кадере.** *Марат Закир*
98 **Тирән тамырлы Туйкиннар.** *Эльмира Шәрифуллина*
101 **Яңа китаплар**
102 **Такташ һәм аның гаиләсе.** *Касыйм Хәмзин*

ТЕЛ КҮРКЕ — СҮЗ

108 **Миллият сүзлеге.** *Адлер Тимергалин*

100 ЕЛ ЭЛЕК...

112 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1914 елның гыйнвар ае.** *Ленар Гобәйдуллин*

ШАЯН МИРАС

116 **Кыш бабай интервью ала.** *Марсель Галиев*

119 **Мирасворд**
120 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Гыйнвар*

Заказ №0-25. Тираж — 1563 данә. Формат 70 X 108 1/16
Басарга кул куелды: 13.01.2015
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Нурислам Исмәгыйлев һәм Ленар Гобәйдуллин төшергән, Абдулла Дубин, авторларның һәм Татарстан Милли музее архивларыннан фоторәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Тышлыкның 1 нче битендә — «Сәйяр театры». 1988 ел. Йон, кулдан тукылган. *Р.Килдебәков эше*

ГАМЬЛЕ БУЛЫЙК!



...Ил, дөнья күләмендәге хәвефле хәл-әхвәлләр отыры арта гына бара. Безнең, борынгы майя кабиләләре сыман, тарихсыз да, телсез дә, мирассыз да калуыбыз бик тә ихтимал. Тирә-юньдә кырын-кырын караучы «конкистадорлар» хәттин ашкан…

Илнең, халыкның дәрәҗәсе күпме «кара алтын» табуы белән түгел, ә аның фәлсәфи-рухи байлыгы, фәнни вә сәнгати казанышлары, тарихи мирасы белән бәһаләнә ләбаса! Гәрчә «кара алтыны» да, уйлап баксаң, табигый мирас инде анысы…

«Без — китаплы милләт, без — мираслы милләт!» дибез. Әнә шул мирасны саклау, халыкка кайтару — күңелендә милли гаме булган һәркемнең бурычы югыйсә. Бер генә мисал. Җир шарының төрле кыйтгаларындагы архивларда, музейларда, китапханәләрдә әллә никадәрле язма мирасыбыз тузан җыеп ята. Әнә шул асыл хәзинәне өйрәнеп кайтырдай, гамьле, тел белгән яшь галимнәребез кайда? Аларның юл чыгымнарын, хезмәтен күтәрердәй дәүләтебез бармы соң?! — «Безнең мирас» бу хакта да уйлана.

Узган ел журнал шактый үзгәрешләр кичерде. Уңай яккамы, кайсы якка — анысы сезнең хөкемегездә, хөрмәтле укучыларыбыз. «Тарихи мирас», «Дини мирас», «Педагогик мирас», «Әдәби мирас», «Табигый мирас», «Шаян мирас»… — утызга якын сәхифә пәйда булды. Бу, әлбәттә, 120 битлек юка гына бер журналда бинибая зур милли мирасыбызны хәл кадәри колачлырак итеп чагылдыру ниятеннән башкарылды. Янә бер яңалыгыбыз — сайт (www.beznenmiras.ru) эшли башлады. Әлегә анысында аудио, видео язмаларга, фотосурәтләргә өстенлек бирәбез. Шөкер, редакция папкасы көннән-көн калыная — сайлап алырдай язмалар байтак. Хәер, авторлар җәһәтеннән дә журнал демократик юнәлешкә йөз тота. Мисалга, фән докторы белән беррәттән, мәктәп укучысының да язмасы дөнья күргән саннар бар. Иң мөһиме — милли мирасыбызны кайгыртсын ул, гамьле булсын!

Сүземне хәвефле хәл-әхвәлләрдән башлаган идем. Әмма дә адәм баласын өмет һәм ышаныч яшәтә! Яңа еллар хәере белән килсен, иминлек вә бәрәкәт насыйп әйләсен!

Марат Закир,
«Безнең мирас» журналының
баш мөхәррир урынбасары

«ИНДЕ АЛМАГАН НИ КАЛДЫ?»*

(милли фаҗигабезне яктыртучы фарсы чыганагы)

Хикәячеләр һәм тарихчылардан ишеткәннәремнән чыгып, Болгар тарихын тасвирлыйм.

Аксак Тимер хәзрәтләре Болгарны яулап алгач, Болгар халкы арасында «Аллаһ барысын белүче», дигән бер-берсен юату сүзләре тарала. Аллаһка ышану, аны ярату яшәргә көч бирә аларга. Аннан Аксак Тимер, Иделне кичеп, рус халкы яшәгән чиккә кадәр барып җитә. Аксак Тимернең илчеләре Михаилга гаскәр килүен хәбәр итәләр. «Яхшылык белән, сугышсыз, кан коюларсыз гына бирелегез! Каршы килсәгез, без сезне җирдән себереп түгәбез. Хатыннарыгызны, балаларыгызны алып китәбез», — дип сөрән сала Аксак Тимер. Аның көчле, данлыклы булуын ишеткән Михаил князь куркып кала, хәтта йөзеннән кан кача, бөтен тәне калтырый башлый.



Аксак Тимер күп җирләрне яулап килгән, бу җирләрне дә тиз арада алырга карар кылып, сугышка әзерләнә башлый. Гаскәр әзер булгач, кинәт Аксак Тимер янында Хидр[1] пәйда була. Ул, атларның тезгененнән тоткан килеш, Аксак Тимергә болай ди: «Сугышырга кирәкми, күрәсең бит, алар болай да бик курыккан. Аллаһ исеме белән әйтәм, ул сиңа сугышырга

[1] Хидр — автор Хозыр Ильясны шулай дип атый.

рөхсәт итми. Бу урынны син аларга калдыр». Аксак Тимер, Хозыр Ильяснең сүзләренә колак сала, аны тыңлый һәм бу урыннан китә.

Алар шулай барганда таулы-ташлы урыннарга туктыйлар. Аксак Тимернең гаскәрендә үз тәртипләре булган. Ул сугышка керер алыннан һәр солдатка берәр таш алып, аны уртак өемгә өйдерә. Моны солдатлар бик теләп эшлиләр. Сугыштан чыккач, алар бу ташларны өемнән кире алалар. Ләкин алынмаган ташлар да кала. Болар инде сугышта үлеп калган солдатларныкы. Әнә шулай итеп, күпме солдат үлүен белгәннәр.

Шуннан, Аксак Тимер гаскәрен, Аллаһ кушуы буенча, бу урыннан 1,5 мил ераклыкка алып китә. Юллары Үзбәкстан, Сәмәрканд якларына таба дәвам итә. Юлда аларга Әмир хәзрәт[2] кешеләре очрый. Әмир хәзрәт кешеләре Иске Болгар шәһәре яныннан агучы Кара Идел буена[3] киләләр. Ләкин ул караңгырак булганга, алар тагын 3 мил көнбатышкарак китәләр. Монда алар шәһәр төзергә уйлыйлар, ләкин байтак кешеләргә урын ошамый. Алар бәхәсләшләр һәм кояш караган, яктырак урынга китеп шәһәр төзергә уйлыйлар. Бу урынны Казансу елгасы буеннан сайлыйлар. Озак та үтми, анда крепость-шәһәр барлыкка килә. Аны Яңа Болгар[4] дип атыйлар. Шулай итеп, бу шәһәрдә ислам дине белән яшәгән, матур, тыныч тормыш башлана. Аллаһның рәхмәте белән аларның дине ислам була. Коръән укып, пәйгамбәребезнең тарихын өйрәнеп, чын күңелдән дин белән яши халык. Аларның күңелендә ышаныч, киләчәккә өмет була. Бу халык белән барлыгы 16 хан идарә итә.

Әйтүләренчә, Иске Болгар белән башта Абдулла хан идарә итә. Үзе үлгәннән соң, аның 2 улы кала — Алтынбәк һәм Алимбәк. Шәһәр төзегәннән соң, канун буенча, аның белән хан идарә итәргә тиеш була. Алтынбәк хан итеп сайлана. Аннан: Алимбәк, Мөхәммәд, Мүмүтәк, Хәлил, Ибраһим, Илһам, Мөхәммәдәмин, Габделлатыйф, Шаһгали, Сәхибгәрәй, Сафагәрәй, Җангали, Үтәмешгәрәй, Ядкәр ханнар.

[2] Әмир хәзрәт — Алтын Урдада һәм татар ханлыкларында берәр олыс яки ыруг башлыгы, үзәк хөкемдарга буйсынган идарәче.
[3] Кара Идел — Идел елгасы.
[4] Яңа Болгар — Казан шәһәре.

*XIX гасыр башында язылган бу хезмәтнең авторы билгесез. Аның төп нөсхәсе Санкт-Петербург Милли китапханәсендә саклана. Фарсы телендә язылган, халкыбызның XIV-XVII гасырлардагы милли фаҗигасен чагылдырган бу хезмәт әлегә кадәр татар һәм рус телләренә тәрҗемә ителмәгән.
Хикәятне сөйләүче, үз чорының тарихчыларыннан ишеткәннәрдән чыгып, Алтын Урда, Казан ханлыгы һәм аннан соңгы татар тарихына кагылышлы вакыйгаларны бәян итә. Чыганактан, тулаем алганда, татар халкының авыр, фаҗигале тормышы күз алдына килә. Мөселманнарга каршы эшләнгән төрле явызлыклар, күтәрә алмаслык җәзалар, кимсетүләр аларны нык какшаткан. Иван Грозныйның татарларга мөнәсәбәте, явызлыгы кульязмада кат-кат истбатлана. Шунысын да онытмыйк, кульязма шул чор историографик традицияләре нигезендә язылган.

Ядкәр хан үлә һәм шуннан соң халык хан итеп кемне куярга белми аптырый. Шаһгали ханны алып кайтып, Яңа Болгарның ханы итеп куялар. Ул Иван Грозныйда әсирлектә була. (Мөселманнар аны руслардан әсирлектән ала булып чыга инде.)

Кара Идел елгасы өстенең Казан ягында, һиҗри елы белән 691 елларда 6 ел буе[5] мөселманнар белән руслар арасында ызгышлар була. Бу сугышта беркем дә җиңми. Шаһгали ханның рус кешеләре белән хат алышуы да билгеле була. Бу сугышларда руслар бик мәкерле булалар. Алар пушкаларга агулы, дарулы матдәләр салып та аталар. Ә мөселманнар бу турыда белмиләр һәм бу сугышта җиңеләләр. Җиңелүнең сәбәпләре, әлбәттә, аларның күп хаталар кылуында да була. Аллаһ — барысын белүче.

Тарихчылыр һәм акыл ияләре сөйләве буенча, Кара Идел өстендә, көнбатыш ягыннан рус армиясе күренә. Аларның полководецы Ибо ибне Василий[6] була. Ул Зувия елгасы[7] буена крепость төзетә[8]. Алар барлык әйберләрен дә шунда саклыйлар. Крепость янында гына зур тау була. Исеме — Бакыр тау. Рус армиясенең гаскәре шунда урнаша, аларның зур һәм кечкенә пушкалары була. 6 ел буе шунда төпләнеп яшиләр, сугышка әзерләнәләр. Язмыш шулай яза: мөселманнарның иң көчле, иң танылган батырлары Чура ибне Мәлик шәһит китә, һәлак була. Мөселманнар моны бик авыр кичерәләр, нишләргә дә белмиләр. Ходай күрсәтмәсен! Мөселманнар өстеннән кяферләр җитәкчелек итә башлагач, бик авыр тормыш башлана. Руслар мөселман картларын, хатын-кызларны, балаларны үтерәләр, матур җиткән кызларны үзләренә алалар. Халыкның бар малын талыйлар, терлекләрен үзләренә алалар. Мондый тормышны Ходай Тәгалә беркемгә дә язмасын. Мөселманнар армиясе җиңелә, исән калган сугышчылар төрле җирләргә тарала. Бигрәк тә Бакчасарай, Яхса[9] якларына күпләп китәләр. Бу шәһәр бик матур һәм зур шәһәр була. Идел буенда башка шәһәрләр дә бар. Алар: Актүбә, Сарытау[10], Сарига[11]. Качучы кешеләр елга буйлап барып, кайсылары казакларга кушыла. Бер өлеше Ак Идел буйлап Уфа якларына китә. Иделнең бу ягы якты, кояшлы була, шуңа күрә аны Ак Идел дип атаганнар. Уфа ягыннан матур вә серле Дим елгасы да ага, аның янындагы крепостьны Куиграт[12] дип атаганнар. Шул урында алар йортлар салганнар. Туган җирләрен сагынып, әрнеп җырлар да җырлаганнар:

«Иделне алды, ятимне алды,
Инде алмаган ни калды?»

Ак Идел ярлары буенда Туртау[13] исемле зур таулар бар иде. Тур исеме Куиграт ханына багышлап әйтелгән. Хан иң биек тау башына зур Урда төзетә. Биек манарадан Куиграт шәһәренә килгән һәр кеше, һәр юлчы күренгән. Руслар басымы астыннан качкан мирзалар да шул шәһәргә килеп урнаша. Алар монда үзләренә сыеныр урын таба. Руслар барлык мөселманнарга үзләренең диннәрен үзгәртергә кушалар, буйсынмаган очракта үтерәләр, яшәгән урыннарыннан куалар. Аллаһ сакласын! Кан-

[5] 6 ел буе — 1537,1540, 1541,1548,1552 елларда зур сугышлар була.
[6] Ибо ибн Василий — Иван Грозный.
[7] Зувия елгасы — Зөя елгасы.
[8] Крепость төзетә — Зөя 1551 елда төзелә.
[9] Аксай (кум. Яхсай) — Дагыстан.
[10] Сарытау — Саратов.
[11] Сарига — Царицын, ягъни хәзерге Волгоград шәһәре.
[12] Куиграт — Кунгурат (Башкортстан).
[13] Туртау — Башкортстанның Ишимбай районында урнашкан (баш.Торатау).

далагин, Калчугин, Идряков, Салтыков кушаматлы руслар бик тә явыз булалар, мөселманнарның хәле бик начарая. Алар Иван Грозный тозагына бик нык кабалар, ачлык белән интегәләр, барчасын да Иван Грозный үз ихтыярына буйсындыра. Болар төп Казан һәм якын тирәдәге авыл халкы була. Аллаһ сакласын!

Менә шулай итеп, Иван Грозный Казанга төпләнә һәм үзенең кяфер законнарын урнаштыра. Шаһгали ханны Мәскәү ягына озаталар. Тарихчылар әйтүе буенча, ул Мәскәү янындагы Кармои шәһәрендә[14] торган, дигән фикер дә бар. Шаһгали хан русларга буйсынырга мәҗбүр булган. Һиҗри елы белән 970 елда (1567 елда) ул үлә.

Гурга (Иван Грозный) беркем дә каршы тора алмый. Ул Казан халкының төп хуҗасы була. Уфада ике төрле халык яши: башкортлар һәм бубиләр[15]. Алар Гур белән килешү төзиләр. Гур аларның килешүен кабул итә. Халык һәр ел саен Гурга төлке, тиен тиреләре түләп торырга тиеш була. Кайберләре хәтта рус армиясендә хезмәт итә. Ләкин налогларны түләмәүчеләр дә була. Ясак түләмәүчеләрне батырханнар[16] дип атаганнар. Шулай итеп, һәр ел саен башкортлар һәм бубиләр даими рәвештә ясак түли. Түләүче кешеләрнең барысын да Гур ясак дәфтәренә яза барган. Түләмәүчеләрне, ягъни Батырхан төркемен аерым дәфтәргә язганнар.

Ясак түләүче кешеләрне руслар үз иткәннәр, алар белән дуслашканнар һәм дәфтәргә дә аларны дус диеп язганнар. Бубиләр ай саен 40 тиен тиресе белән ясак түләргә тиеш булган. Гур аларны походларга алып барган. Ләкин иярченнәре: «Аларга ышанма! Һәрвакыт куркытып, угыңны төбәп тор!» — дип, аңа киңәш биреп торган. Халыктан җыелган налогны Мәскәүгә озаталар. Бу авырлыкларга түзә алмаганга, кешеләр баш күтәргән. Күп кеше бу ясакларны түли алмаган.

Татарларның рус казнасын талаган вакытлары да була. Ак Идел буена крепость төзеп, аны Уфа дип атыйлар. Руслар җыелган налогны шунда саклый. Бу крепость янына башкортлар, качып килгән халыклар җыелышып, Гур турында, аның гаскәре, законнары турында сөйләшәләр. Гур бу хәлләрне барысын да белеп тора, халыкны үз законнарына буйсындырып яшәвенә барыбер ирешә.

Шулай тормыш дәвам итә. Соңрак татарлар башкортларга, казакларга кушыла. Кырымга, казах далаларына да таралалар алар. Рус изүе астында калган мөселманнарга бик авыр була. Шулай булса да, алар түзә. Түзә алмаганнары, ераграк китеп, башкортларга кушыла. Башкортларда төрле ырулар була, татарлар алардан сыену урыны сорый. Башкортлар белән яши башлагач, аларны дәфтәрләргә башкортлар дип яза башлыйлар. Кемнәр ясакны түли, аларны дәфтәргә киптәрләр[17] дип язганнар. Беркем дә түбәнсетүләргә каршы баш күтәрмәгән.

Фарсычадан Г.Ибраһимов исемендәге
ТӘһСИ аспиранты ***Алсу Газымова****
тәрҗемәсе

Дәвамы бар ■

[14] Кармои — хәзерге Рязань өлкәсе Касыйм шәһәре.
[15] Бубиләр — бобыльләр.
[16] Батырханнар — төрки халыкларында «батырхан» сүзе кеше исеменә кушылып килгән, бу исемгә бары кыю, сугышта батырлыклар күрсәткән шәхес кенә ия була алган.
[17] Киптәрләр — типтәрләр.

МИШӘРЛӘР

Зариф Бәшири

7. ТЕЛӘНЧЕ ВӘ СӘҮДӘГӘРЛЕКЛӘРЕ, СӘФАҺӘТ (МАЛНЫ ӘРӘМШӘРӘМ ИТҮ, БОЗЫКЛЫК).

Бар милләтнең кадер вә кыйммәтен, намус вә гыйззәтен җуйган нәрсә ике төрле шәй булып, бере — теләнчелекнең күплеге вә икенчесе — фахишә вә фәхеш хатыннарының мәйдан алуыдыр. Бу ике төрле нәрсә ул милләттә гыйлем вә мәгарифнең, мәгыйшәт вә интизамның (тәртиплелек), һиммәт вә иҗтиһадның ни дәрәҗәдә булуын ачык белдерер. Мәсәлән, теләнчелекнең күбәюе — милләтне ялкаулык каплап алып, һөнәр вә сәнәгатьтән ерак булуын күрсәтә вә фахишәләрнең мәйдан алуы милләтнең хатын вә кызлары гыйлем вә һөнәрдән мәхрүм, хөрлектән өмидсез идекен белдерер.

Бу җәһәтләрдән мишәр халкы икегә аерылып, чистай вә хвалын мишәрләренең бар белгән эшләре вә һөнәрләре — теләнчелек вә сукыр суфыйлыктыр. Бу мишәрләрдә теләнчелек шулкадәрле тәрәккый иткән ки, араларында баерак булганлары да, ун-унбиш кадәр сабыйларны, ирсез вә фәкыйрь хатыннарны, җыелган нәрсәләренең һәммәсен хуҗага бирү шарты белән, айлык вазифа биреп яллап чыгаралар да, теләнчелек белән сәүдә иттерәләр. Моны бәян өчен озын юллар кирәкми. Русиянең һәр тарафында, кирәк шәһәр урамнарында вә кирәк авыл юлларында булсын, кыш буе авыз туңдырып, нечкә киемнәр кию сәбәпле, бөтен барлыгы белән тетрәп, ишектән-ишеккә, авылдан-авылга йөргән теләнчеләрнең һәркайсыннан: «Сез кайдагы?» — сораленә: «Чистай» яки «Хвалын» җавапларын алырсыз.

Бу мишәрләр теләнчелек һөнәрендә шулкадәр тәрәккый итеп искитәрлек оятсызлыкка өйрәнгәннәр ки, аларның моңлы күңел вә сынык бер тавыш күрсәтеп: «Атам үлде, тәрбиячесез калдым», «Йортыбыз вә бөтен игенебез янды, ач калдык», — дип ялган сүз вә түгәрәк яшьләре белән үзләрен кызгандырып соранууларына ирекле-ирексез сәдака бирми чыдый алмассың. **Әгәр алар бу кадәрле оста телләре белән сәүдә эшләренә тотынсалар иде, һич шик юкдыр ки, иң маһир сәүдәгәрләрдән булган яһүдиләрдән дә алга китәчәкләрдер.** Чистай вә Хвалын хәерчеләре арасында нарат кеби кызарып торган таза вә сәламәтләре, зәгыйфь вә сабыйларга нисбәт илә күп артык күренеп, теләнчелек сәүдәсеннән кайтканнан соң һичбер төрле эшкә тотынмый, караул өйләрендә «Алты батыр» хикәяләрен сөйләп гомер үткәрүләре мәйдан алмыштыр. Шулай ук болар арасында гыйффәте белән сәүдә итеп тамак туйдырган фахишәләрнең дә күплеге беленде. Шәһәрләрдә фәхешханәләр тотучы мишәр динчеләре дә аз түгелдер.

Менә бу мишәрләр бөтен мишәр милләтенең гыйззәт-нәфес вә намусын җыеп, мондый кабахәт сыйфатлардан пакь булган Пенза вә Тамбов һәм бер такым (төркем) Сембер вә Мәләкәс мишәрләрен дә «хәерчеләр» сүзен ишетергә мәҗбүр итәләр. Хәлбуки бу

Ахыры. Башы журналның 2014 елгы 10 нчы санында.

мишәрләр, аеруча Пенза вә Тамбов мишәрләре, бу ике кабих сыйфатлардан пакь булып, яхшы тормыш вә мәгыйшәткә өстерәгән сәүдәгәрлектә гаять маһиранә рәвештә (оста) булалар. Бу мишәрләр, үзләренең мишәрлекләре белән горурланып, намусларын саклауны артык сөюләренә күрә дә, чистай вә хвалын мишәрләренә бөтен күңелләреннән әрниләр вә ләгънәтләр яудыралар.

Бу мишәрләрнең сәүдәгәрлекләре хакында, бер мишәрнең үз авызыннан милләтен мактауга караганда, башка милләтләр тарафыннан макталуын артыграк күрүемнән, мишәрләр арасына сәяхәтем вакытында шатлыклы бер очрашуны гына язып китәргә теләдем. Тарбеев станциясенә төшкәч, Тамбов губернасын үтеп, Пензага караган мишәрләр арасына килергә тиеш булуымнан, беркадәр чакрымнарны бер мукшы (мордва) егете алып барырга булды. 18-19 яшьләрендә булган бу мукшы баласы урысчаны яхшы гына белә вә татарчаны да бераз җырткалый ала икән. Һәм дә урысчадан байтак кына роман вә газеталар, рисалә вә журналлар да укыганлыктан, фикере дә чибәр генә ачылган булып, үзендә «милләт кайгысы» барлыгы да аңлашыла. Берничә чакрымнарга кадәре моның белән җитди мәсьәләләрдән бәхәс ачып, сүз кузгата алмадык. Чөнки мине әллә нинди бер тирән уй-фикер басканлык-

Әгәр алар бу кадәрле оста телләре белән сәүдә эшләренә тотынсалар иде, һич шик юкдыр ки, иң маһир сәүдәгәрләрдән булган яһүдиләрдән дә алга китәчәкләрдер.

Сергач мишәрләре. XIX гасыр азагы

Саратов губернасы мишәрләре. XX йөз башы

тан, бер дә сөйләшәсем килми иде. Әмма егетнең сөйләшәсе килгәнлеген вә үзенең эчендәге кайгысын түгәсе килгәнлеген миңа карап төрлечә сораулар биргәнлегеннән аңладым. Ләкин мине күңелемдәге төрле фаразлар вә планлар шулкадәрле каплап алганнар иде ки, аның сораулары бер колагымнан кергәнче икенче колагымнан чыгып киткән булалар иде. Егетнең эчендә моңы көчләде булса кирәк, мукшы телендә булган җыруларны җырламый чыдый алмады. Моның җырулары миңа тәэсир итте. Татлы вә куәтле фаразлар мине җиңә алды. Күңелем яңа бер хәзинә тапкан кеби булып, башым кинәт кенә аның тарафына әйләнде.

Бу вакыт каршыбыздагы кызыл түбәле биек-биек өйләр, ялтырап торган озын-озын манараларга күзем төшеп: «Бу нинди шәһәр?» — дип сүз башладым. Минем белән сөйләшер өчен ничек юл ачарга аптырап килгән егетнең теле чишелде:

— Бу шәһәр түгел, ә Юна исемле бер мишәр авылы. Синең бәлки бу биек өйләргә күзең камашкандыр. Бу бер дә гаҗәп түгел. ***Мондагы мишәр авыллары һәммәсе шулай бай.*** *Мондагы авылларның һәммәсендә 3-4 йөз мең сум, бәлки дә миллионнар белән эш йөрткән мишәрләр күп. Ничек бай булмасыннар соң! Үзләре барысы да әрсез сәүдәгәрләр. Балалары бераз үстеме, байга керешеп,*

сәүдәгә китә. Анда бераз шаяра, сәүдәгә вә телгә остара да, үзе сәүдәгә тотына. ***Ул гына да түгел, бер-берсен гаҗәеп дәрәҗәдә күтәрешәләр.*** *Яшьрәкләренә урын булмаса, байлары йә үзләреннән, йә кәфил (поручитель) булып, башкалардан алып мал бирәләр дә, аны сәүдәгә тотындыралар, белмәсә, өйрәтәләр.* ***Ә башка милләтләрне, никадәрле укыган вә сәләтле күренсә дә, ак хезмәтләргә һич алмыйлар.*** *Күптән түгел бер мишәр бае бер урыс егетен сәүдә хезмәтенә алган иде. Шуңа башкалары тәмам нәфрәт иткәннәр, хәтта ачуларыннан тотып кыйнаганнар. Кара хезмәтләрдә, мәсәлән, утын кисү, су ташу, тирес түгү, йомышка йөрү кебиләрдә, һичбер мишәрне күрмәссең, һәммәсе дә урыстан вә мукшыдан булыр. Мин аларда бозыклык, ягъни эчке фәхеш артыннан йөрү кебек нәрсәләрне дә күп белмим. Менә шулчаклы әрсез вә тырыш булу өстенә милли тәгассыб та (үз халкын, милләтен артык сөю) булгач, ул милләтнең икътисади хәле ничек яхшырмасын соң! Ләкин алар әлегә аз укыйлар. Әгәр укысалар, тагын да башкача булырлар иде. Мин алардагы сәләтлелек, булдыклылыкка да гаҗәпләнәм. Бу да юлда калмас, уку кирәклеген дә яхшы ук аңлап киләләр бугай. Шушы елларда гына берничә бае, зур бер мәктәп вә җәмгыяте хәйрия ачарга теләп, күп кенә акча да җыйган иде. Ләкин эш башында йөрүчеләренең начарлыгыннан вә алары да руханилардан булганлыктан гына барып чыкмый тора. Шулай инде ул,* ***бер эшкә руханилардан берәү катышты исә аннан хәер өмид итү кыен.***

Беркадәр тынып торганнан соң мукшы егете янәдән сүзгә керешеп: *«Безнең мордваларның мишәр белән бер нәселдән идеге бик яхшы аңлашыла, ләкин алар ник болай түгел икән? Кирәк гыйльми җәһәттән вә кирәк икътисади җәһәттән булсын, дөньяда иң түбән вә югалырга әзерләнгән бер кавем булса, ул да безнең мукшы милләтедер. Боларның*

Мишәр хатыны. XVIII гасыр.
И.-Г.Георгиның «Описание всех обитающих в Российском государстве народов» китабыннан

Аеруча аның «мукшылар мишәр вә татарлар белән бер нәселдән булулары аңлашыла» җөмләсе форсат килгәндә, аларның да хәлен тикшерүгә юл ачты.

бар белгәннәре өйдә тик яту, эчү, наданлыкка баш июдер. Шуннан башка һичнәрсәләре күренми, тик ашарларына бетсә генә мишәрләргә баралар да, көненә егерме тиенгә арыш сугып кайталар. Бумы авылда көн итү? Бу хәлне аңлаган вә милләтне сөйгән бер кеше өчен моннан артык кайгы-хәсрәт булырмы?» — диде.

Егетнең моңа кадәрле һич күргәнем булмаган мукшылар хакында уйламаган җирдән бер мәгълүмат бирүе минем өчен тагын да бер яңа хәзинә булды. Аеруча аның «мукшылар мишәр вә татарлар белән бер нәселдән булулары аңлашыла» җөмләсе форсат килгәндә, аларның да хәлен тикшерүгә юл ачты.

***

Мондагы мишәрләр сәүдә җәһәтеннән шулкадәр тәрәккый иткәннәр ки, нинди генә бер мишәр гаиләсен күрмә, ул гаиләнең эчендә ике-өч кеше сәүдә белән чит шәһәрләрдә (үзләренчә «янтыкта») йөри торган була. Шәһәрләрне вә әллә никадәр мәмләкәтне әйләнеп чыкмаган һичбер мишәр юкдыр. Начар гына бер мишәр белән сүз ачарга тугры килсә, ул үзенчә Төркия вә Франция, Болгария вә Германия һәм дә Кытай мәмләкәтләрен сөйләп шаккатырадыр. **Укый вә яза белү читтә торсын, гомумән укуның ни икәнен дә белмәгән бу мишәр халкының бөтен мәмләкәтне әйләнеп, үзләренең авылларын шәһәр хәленә кертүләре, тирә-якта булган бөтен урыс вә мукшы кавемнәрен үзләренә кол итүләре, үзләренең йөргән мәмләкәтләренең икътисади хәленнән генә түгел, бәлки дә бөтен әхвәлләреннән саф вә тугры мәгълүмат бирә дә алулары искитәрлек бер хәлдер.** Бу аларның, авыз күтәреп йөрүче бер халык булмаулары белән бергә, сәләтлелек һәм булдыклылыклары ни дәрәҗәдә идекләрен дә бик яхшы белдерсә кирәк. Аңлашылганча,

Мишәрләр сәяхәт вә сәүдәгәрлекне, хәтта милли эш хөкемендә йөртеп, артык сөя. «Бу безгә бабайлардан калган мөкаддәс бер мирас», – диләр.

мишәрләр искедән бирле сәүдәгәрлек белән мәшгуль булган бер халык булганга охшый. Чөнки һәр мишәр карты үзенең вә аталарының сәүдә белән йөрүләрен ләззәт вә тәфахирга (үз-үзен, бер-берен мактауга) чумып сөйли.

Мишәрләрдә элгәре «кыздырып сату» дигән сәүдә бик модада булган. Ялган ефәк яулык вә ялган мехларны хәйлә белән бик нык үткәрә алганнар. Кыздырулары болай була: бер сатлык товарны берәр байның өенә, бигрәк тә бояр хатыннарына алып бара да кыйммәт бәһагә алырга өнди. Алмасалар: *«Әй бетле, синнән буламы соң моны алу! Синдә моны алырлык акча юк бит!»* — дип кыздыралар вә хурландыралар икән. Үзләрен кеше алдында бай күрсәтеп вә мал белән кибәр (горур)тотарга теләгән байлар, табигый, кыздыруга бирешеп, үзләрен бик нык оттырганнардыр. Мишәр каракларының бу сәүдә белән бик күп мәмләкәтләрдә йөргәнлекләрен, моңа бигрәк тә урыс вә юнан милләтенең алданганын, ләкин төрек вә болгарларны һич тә кыздыра вә алдый алмаганлыкларын сөйлиләр. Мишәрләр сәяхәт вә сәүдәгәрлекне, хәтта милли эш хөкемендә йөртеп, артык сөя. ***«Бу безгә бабайлардан калган мөкатдәс бер мирас»***, — диләр. Мишәр баласы, кеше арасында күренә алырлык булды исә, сәүдәгә китү ниятен тота. Чөнки, аларда сәүдә гыйлемен белмәү гаеп хөкемендәдер. Мишәрләрнең, күбрәк сәүдә иткән җирләре Төркия, Франция, Кытай вә Сибирия мәмләкәтләре булып, сәүдәгәрләре дә җон-җабага, мех вә тире-җары сәүдәләредер. Моннан башка комиссионер, маклер булып йөрүчеләре һәм вокзалларда буфет тотучылар, җоз (сату йөге) йөртүчеләре дә күптер. Бүгенгедә Сибирия вә Манчжурия әтрафында сәүдәгәрлектә иң зур роль казанган сәүдәгәрләр дә — мишәрләрдер.

Кыскасы, мишәрләр, сәүдә җәһәтеннән яһүдиләргә бәрабәр диелсә дә, хаклыктан чит булмас. Фәкать алар — артык әрәм-шәрәм итүче, өй икътисадында тәдбирсез (эшнең ахырын уйлап эшләмәү, алдан күрмәү) вә чиктән тыш ясалма кыланучы бер халыктыр. Үзләренчә гыйлем вә дин юлына тоткан исрафлары да, тирә-яктан ишан вә муллаларны, мөәзин вә сукыр суфыйларны җыеп бөек вә гаять ясалма мәҗлесләр ясау вә дога алудыр.

1912 ел

Текстны басмага
***Салават Галимов** әзерләде.* ■

ГЫЙЛЕМ ХӘЗИНӘСЕ, ХӘТЕР САКЧЫСЫ...

Ирек Һадиев,
Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең фәнни эшләр буенча директор урынбасары

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе нигезләнүгә быелның гыйнварында 150 ел тула*. Ул Россиядәге һәркем файдалана ала торган җәмәгать китапханәләренең иң әүвәлгеләреннән берсе булып санала. Башлангычы Казан шәһәрендә 1865 нче елның 10 (24) гыйнварында ачылган Казан җәмәгать китапханәсенә барып тоташа. Ә аның нигезен танылган китап сөюче (библиофил) Иван Алексеевич Второвның шәхси китапханәсе тәшкил иткән. Кечкенә генә җәмәгать китапханәсе шушы гасыр ярым вакыт эчендә Россиядәге иң зур милли китап хәзинәләренең берсенә әверелде.

**З.Ушкова йорты
Архитектор К.Л.Мюфке**

*Редакциядән: китапханәнең моннан 100 ел элек булган 50 еллык юбилее турында журналның 113 битеннән укып белә аласыз.

1844 елда «Казан губернасы хәбәрләре» газетасының бүлек мөхәррире, әдәбият белгече, археолог һәм этнограф **Николай** Иванович **Второв** Казаннан Петербургка хезмәткә күчкәндә, әтисе **Иван Алексеевич** гомере буе туплаган, 1908 нөсхәдән торган китапханәне шәһәргә бүләк итеп калдырган. Бу китаплар бәйләмнәрдән киштәләргә күчеп, җәмәгать китапханәсен тәшкил иткәнче 20 ел вакыт үтеп киткән. Бер урыннан икенчесенә күчерелә-күчерелә шактый гына томнар югалган. Ул заманнарда да гади халыкка игелек-изгелек эшләүдән тайчыну, рухи кыйммәтләргә битараф карау җитәкче аппарат вәкилләре, «йомшак урындыкларда» утыручылар өчен ят гамәл булмаган икән. Ниһаять, күп киртәләр алып ташланып, 1865 елның гыйнварында Казан шәһәр җәмәгать китапханәсе ачылган. Моңа кадәр университетта, Духовная семинариядә китапханәләр эшләгән булса да, шәхси кулларда китаплар сакланса да, җәмәгать китапханәсе үз укучыларын тапкан, фондлары да елдан-ел үсә барган. Бик озак еллар Казанның беренче бушлай җәмәгать китапханәсен **«Второвлар китапханәсе»** дип тә атаганнар. Әйтергә кирәк, аталы-уллы Второвлар — шул чорның зыялы һәм күренекле кешеләреннән булып, Казан шәһәре һәм Идел буе төбәкләрендә үзләреннән соң тирән эз калдырган шәхесләр.

Ул заманнарда китапханә, нигездә, «өлкән туган»га гына хезмәт иткән. Ә китапны гомере буена җан юлдашы иткән татар халкы шәхси кулларда-гы, мәдрәсәләрдәге, соңрак җәмгыяте хәйрияләр оештырган китапханәләрдән файдаланган. Шанлы дәүләтләре бар чакта китапханәләре гөрләп торган халыкка, дәүләтеннән мәхрүм калгач, җәбер-золым, милли-дини изү астына эләккәч, әлбәттә, җәмәгать китапханәләре оештыру хокукы да бирелмәгән. Ләкин XIX гасырның 70-80 нче елларында ук мондый уйфикерләр, өмет-хыяллар белән янып йөрүчеләр була. Аларны тормышка ашырырга 1905-1907 еллардагы инкыйлаб мөмкинлек бирә, аның нәтиҗәсендә халык китапханәләре оештыруда зур урын тоткан татар хәйрия һәм төрле мәдәният-мәгариф җәмгыятьләре барлыкка килә. Күренекле татар журналисты, тел галиме һәм җәмәгать эшлеклесе **Әхмәтһади Максуди** инициативасы һәм тырышлыгы белән 1906 елның башында **«Көтебханәи исламия»** — Казан шәһәр җәмәгать китапханәсенең мөселман филиалы ачыла. Ул башта Печән базарындагы **Кәримовлар йортында**, аннары **«Болгар»** кунакханәсенең өченче катында урнаша. Беренче эш көннәреннән үк «Көтебханәи исламия» белән кызыксынучылар күп булган. Моны укучыларга хезмәт күрсәтү һәм китаплар, газета-журналлар бирү турында безнең көннәргә кадәр сакланган мәгълүматлар раслый.

1906 елның 2 гыйнварында Казанда ачылган татар китапханәсе үз эшен уңышлы дәвам иткән. Советлар хакимияте урнашкач, 1920-1929 нчы елларда китапханә **«Мәркәз шәрык көтебханә-музее»** исемендә эшләп килгән. 1920 нче еллар ахыры — 1930 нчы еллар башында китапханә төрле фәнни оешмаларга таркатылган. Нәтиҗәдә, хәзерге вакытта, «Мәркәз шәрык көтебханә-музее» фондының борынгы гарәп һәм фарсы кульязмаларыннан, газета һәм журналларның еллык төпләмнәреннән, күп санлы башка китаплардан гыйбарәт булган зур бер өлеше Казан университеты Фәнни китапханәсендә, бер өлеше Татарстан Матбугат архивында һәм аз күләмдәге бер өлеше Татарстан Милли китапханәсендә саклана.

***

1919 елда Казан шәһәр җәмәгать китапханәсен шәһәр үзәгенә урнашкан ике катлы матур бинага — элекке **Зи-**

Систематическій
КАТАЛОГЪ
русскихъ книгъ
филіальнаго (мусульманскаго)
отдѣленія
Казанской Городской Публичной Библіотеки.

наида Ушкова йортына — күчерәләр. Бу бина бүген дә **Китап Сарае** вазифасын үти. Ул XX йөзнең башында архитектор **К.Л.Мюфке** проекты буенча төзелгән.

Менә сез тышкы яктан сәнгати-архитектур алымнарның бик күп төрләрен мул кулланып бизәлгән, зур тәрәзәләре, көмеш сыман гөмбәзчеге, турыпочмаклы һәм түгәрәк балконнары, балконнарның челтәрле кырлары белән үзенчәлекле бер сәнгать һәйкәле булган бинаның әүвәлге авыр ишекләрен ачып эчкә үтәсез, Сарайның тыныч, серле һәм гаҗәеп дөньясына чумасыз. Сезне ишек тоткаларына, баскыч култыксаларына, диварларга, тәрәзә пыялаларына ясалган кошлар, җәнлекләр, әкият каһарманы — аждаһалар каршы ала, идәннәргә, түшәмнәргә һәм диварларга төшерелгән үсемлек, чәчәк-яфрак бизәкләре күзне иркәли. Монысы — кытай-япон стилендә эшләнгән вестибюль. Бамбук таяклары белән бер-берсеннән аерылып торган рәсемнәр — шушы халыклар көнкүрешен чагылдырган күренешләр. Зур тантаналар залы (хәзер зур уку залы) үзенең күзне камаштырырлык аклыгы һәм алтын йөгертелгән, ампир стилендәге сынлы бизәкләре белән ялтырап тора. Ашханә (хәзер техник әдәбият бүлекчәсе) кара агачтан эшләнгән, оркестр өчен югары күтәртеп махсус сәндерә ясалган. Кунаклар бүлмәсендә һәм йорт хуҗасының бүлмәсендә (хокук әдәбияты һәм гуманитар фәннәр әдәбияты бүлекчәләре) искиткеч шәп каминнар. Залларның берсе сталактитлы мәгарә рәвешендә ясалган, бер дивары уелып, аквариум куелган. Мәгарәнең уртасында элек фонтан атып торган, аның идәндәге эзләрен бүген дә күрергә мөмкин. Түгәрәк балконлы почмак бүлмәнең (хәзер күргәзмәләр залы) бизәлеше мавритан стиленә карый, балконга чыгу юлындагы түгәрәк бүлмә мәчет манарасын хәтерләтә, анда тавыш бик яхшы яңгырый. Ишекләргә сырлап үсемлек орнаментлары, тоткаларына

Әхмәтһади Максуди

гарәп язуы элементлары төшерелгән. Рәссам-архитектор шул дәрәҗәдә фантазиягә бай кеше булган ки, йортта бүлмәләр бик күп булса да, бизәкләр, сырлар, төсләр бер дә кабатланмый. Ике бүлмәне тоташтыручы ишекнең ике ягы ике төрле, бер бүлмәгә чыга торган берничә ишек уртак бер стильдә ясалган. Йортны бизәүдә мәрмәр һәм бронза, кара агач, төсле пыяла, йөгертелгән алтын, ифрат күп көзге кулланылган.

Бизәлештәге үзенчәлекләр турында бик күп сөйләргә мөмкин булыр иде. Гомумиләштереп шуны әйтәсе килә: бизәлештәге һәм эшләнештәге зәвыклылык, сәнгать бөтенлеге рәссамга, бинаны төзүчеләргә ихтирам һәм соклану уята.

***

Инде Милли китапханәнең бүгенге тормышына күчик. Аның китап укучыларга тиешле дәрәҗәдә хезмәт күрсәтүен, өстәмә уңайлыклар тудыруын ике дистәгә якын бүлек һәм бүлекчә тәэмин итә. Мәдәният хезмәткәрләренә түләнә торган аз хезмәт хакына кара-

мыйча, эшләрендә бернинди тоткарлык тудырмыйча, «китап укучы һәрвакыт хаклы» дигән сүзләрне үзләренә кагыйдә итеп алган тәҗрибәле-оста һәм белемле-тырыш 200дән артык хезмәткәр эшли биредә.

Китаплар туплау, аларны эшкәртү-каталоглаштыру, саклау бүлекләренең вазифалары турында исемнәре үк әйтеп тора. Уку залы (ул гуманитар фәннәр әдәбияты, хокук әдәбияты, техник әдәбият бүлекчәләреннән тора), башка китапханәләр белән китаплар алышып-бирешеп торучы китапханәара абонемент эшли. Китапханәдә китапларны, газета-журнал мәкаләләрен, һәртөрле информацияне эзләп табу эшләрен автоматлаштыру һәм компьютерлаштыру бүлеге яңа технологияләргә нигезләнеп елдан-ел камилләштерә. Белешмә-библиография бүлегендә төрле фән тармакларына караган библиографик мәгълүматлар, белешмә-консультацияләр алырга мөмкин. Татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү бүлегендә татар телендәге, республикабызда яшәүче башка халыклар телләрендәге, татарлар турында башка телләрдәге һәм туган якны өйрәнүгә караган китаплар, милли библиография һәм матбугат материаллары, башка басмалар тупланган.

Борынгы татар кулъязма һәм иске басма китаплары, татар тарихына караган әүвәлге документлар һәм фотосурәтләр, гарәп һәм латин язуындагы татар газета-журналлары, китапханәгә нигез салган Второв китаплары коллекциясе, 1917 елга кадәр басылган, сирәк очрый торган рус китаплары, хәзерге заманның сирәк китаплары, язучыларның китапханәгә бүләк иткән имзалы китаплары кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге киштәләрендә урын алган. Милли китапханәнең икенче бинасында (Карл Маркс урамы, 36 нчы йорт) вакытлы матбугат, чит ил телләрендәге әдәбият, фәнни-методик, патентлар, китапханә-мәгълүмати технологияләр, халыкара һәм төбәкара китап алмашу бүлекләре, өченче бинасында (Театр урамы, 5 нче йорт) сәнгать, редакция-нәшрият, китапларны реставрацияләү бүлекләре урнашкан.

Бүлекләрнең барысы да халыкның китапка, язма сүзгә, мәгълүматка булган ихтыяҗларын канәгатьләндерү һәм биредәге рухи байлыкны киләчәк буыннар да файдаланырлык итеп саклау бурычын үти.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе — татар мәдәниятен таныту үзәге, татар китабын һәм республикабыз турындагы әдәбиятны туплау, саклау, тарату мәсьәләләре белән максатчан рәвештә шөгыльләнә торган, Россиядәге, якын һәм ерак чит илләрдәге татар укучыларына хезмәт күрсәтүче китапханәләр белән традицион элемтәләре булган бердәнбер зур китапханә. Аның фондларында 3 млн 300 мең нөсхәгә якын һәртөрле басмалар, шул исәптән татар телендәге 120 мең, чит телләрдәге 82 мең китап тупланган. Милли китапханә хезмәтләреннән ел саен 35 меңнән артык китап укучы файдалана, аларга 2 млн.га якын китап һәм башка төрле басмалар бирелә.

***

150 еллык олуг юбилей мөнәсәбәте белән язылган бу кыска мәкаләдә китапханәнең проблемаларына тукталмадык. Татарстан хөкүмәте, Мәдәният министрлыгы, китапханә җитәкчелеге аларны яхшы белә, уңай хәл итү юнәлешендә эшли. Республикабыз Милли китапханәсенең 150 еллыгыннан соң киләчәк юбилейларын (155, 160 еллыклар) каршылаганда мөһим проблемаларның күбесе (шул исәптән, яңа бина төзү мәсьәләсе дә) хәл ителгән булыр, алдагы зур бәйрәмнәрне дә китап сөючеләрдән, мәгълүмат эстәүчеләрдән аерылмыйча, фән, мәдәният, мәгариф, каләм әһелләре китапханә белән бәйләнешләрен өзмичә, бергә-бергә үткәрербез, дигән өмет-ышанычлар белән калабыз... ■

ЕГЕТ КЕШЕГӘ ҖИТМЕШ ТӨРЛЕҺӨНӘР ДӘ АЗ, ДИГӘН СҮЗ – РАСТ СҮЗ

Хикәят[1]

Үткән заманда Бохара шәһәрендә бер дөкяндә [кибеттә] утырып, сәүдә кыла торган Габдулла нам [исемле] бай бар иде, үзенең сәрмаясы [акчасы] 3000 алтын иде. Шул 3000 алтынның файдасына канәгать кылып, җәмәгате берлән Аллаһы Тәгаләгә хәмде итеп, ничә еллар гомер кичерделәр, ләкин Габдулла бай җәмәгате берлән һәр заман адәм балаларының гаебен сөйләрләр иде.

Мәсәлән, фәләннең углы атасыннан соң бу кадәр акчасын бетерде, яисә фәләннең углы атасы сәламәтлегендә бу кадәр маллар бетереп, җир Мәккәләрдән кайттылар, дип **һәр заман, ирле-хатынлы кеше хәлен тикшермәк иде**. Әмма Габдулла байның фәкать бер углы бар иде. Мәдрәсәдә гыйлем эстәп, дәрес укып, 18 яшьләренә җитәдер иде. Исеме Әмин бай иде. Беркөн Габдулла байның җәмәгате Габдулла байга:

— И, бәнем гакыллы хуҗам, безләр имде картаеп барамыз, **үземез һәрзаман кеше балаларыннан көлдек**, безнең үземезнең углымыз Әмин бай үсеп җитте, имде безләр аны мәдрәсәдән алып, үземез сәламәт вакытта кәрванга, мең алтын кулына биреп, кушып җибәрик. Кәрван берлән барып, сәүдәгәрләремез нә мал алсалар, бу да шул малдан үз акчасына карап алыр, иншаллаһ. Баламызның күзе ачык, ничек булса да мал төяп Бохарага кайтса, бер бай җирдән кыз алырмыз. Юкса безнең баламызның укып мөдәррис буласы юк. Әлбәттә, үземезнең сәламәт вакытымызда бер сәүдәңезгә кушып җибәрик бер шәһәргә, — дип әйтте.

Габдулла бай:

— Бик мәслихәт, хатын, бер һәфтәдән [атнадан] Бинарис шәһәренә кәрван чыгачак, үземезнең Миргаяс байлар алган малдан алыр, бәһасе һәм алар бәһасе булыр, — дип, мәдрәсәгә барып углына әйтеп, мөдәррискә алып барып, сәдакалар биреп, күп догаларны алды.

Анасы берлән атасы Габдулла бай углы Әмин байга:

— Без сине бер һәфтәдән кәрван берлән Бинариска, сәүдәгәр Миргаяс байга кушып җибәрәмез, мең алтын бирәмез, ничек булса да мең алтынлык мал алып кайтырга тырыш, зинһар исраф кыла күрмә, безләрне адәмнәргә көлдермә, — дип әйттеләр.

Бик үтенеп, мең алтынны кәмәргә [билбауга] тезеп, биленә бәйләп, яхшы чапаннар кидереп, яхшы аргамакка мендереп, Миргаяс бай берлән бергә кәрванга кушып җибәрделәр.

Габдулла бай иртәгәсен кибеткә чыгып, күршеләренә сөйләде:

— Әй, дустлар, догадан фәрамуш итмәңез [онытмагыз, истән чыгармагыз], балам Әмин байны кәрван берлән Бинариска җибәрдем, сәламәт барып килсә икән, кулына мең алтын акча бирдем, Миргаяс байлар нә мал алса, әлбәттә, шул малны ала, — диде.

Күршеләр бар да беравыздан:

— Бәрәкалла, бик яхшы, иншаллаһ, сезнең углыңыз Әмин байның күзе ачык, имди сез ике-өч елдан мәсҗед карты булып, мәсҗедтә генә утырырсыз, Әмин бай кулыңыздан эшне алыр, бик яхшы, Аллаһы хәерле әйләсен, — диделәр.

Инде без килик Әмин байга. Кәрван берлән юлда барадыр. Яхшы чапан киеп, яхшы аргамакка менеп, байбәтчә булып, авызы әйткәнне колагы ишетми барып, берничә вакыттан соң Бинарис шәһәренә җитеп, бер зур кәрвансарайга төштеләр. Берничә сәгать истирахәт кылгач [ял иткәч], Әмин бай кәрвансарай алдына чыгып утырды. Бераз утыргач, кәгазь өләшүче Әмин байның кулына берсен биреп китте. Әмин бай игълан кәгазен укыса, күрде: «Әй, миһманнар [кунаклар], боерасыз бу көн бәнем багымга [бакчама]. Тамаша кыласыз, ничә җирдә мусика [музыка] уйналачак, хосусан [аеруча] дөб-дөби чишмәләргә әвереләчәк, ничә җирдә камәри [ай] кеби кызлар наз берлән шигырьләр әйтәчәк, ләкин багның тамашасына дөхуль [керү] өчен бер тәңкә алтын алыныр. Тамаша фәлән сәгатьтән башланачак, дигәч», — Әмин бай сәгатен алып карады, вакыт якын калганын күрде. Бер адәмнән сорады:

— Бу баг еракмы? — дип.

— Шул каршыда күренгән баг — бик нәфис җир, тамаша кыл, мондай баг

Бохарада булмас, — дигәч, Әмин бай чапаннарны төзәтеп, акрын гына ялгызы багка кереп китте.

Дөхуль өчен акчаны бирде, бераздан күрде: багка утлар яндырдылар, берничә җирдә уен башланды. Әмин байның кылы башыннан чыкты. Хәйран булып, тамаша кылып йөргәндә, бер дворец кеби йорт күрде. Эченә әллә ничә җиргә кандильләр асып, ут яндырганнар, һәркем шул дворецның тәрәзәсеннән эченә карый. Әмин бай да барып карады. Күрде: дворецның эчендә егермеләп яшь егет, һәркаюсының кулында скрипка, урталарында бер зур мыеклы адәм бар, аның да кулында скрипка. Шул адәм бу яшь егетләрне өйрәтәдер. Яшь егетләрнең һәркаюсының башына кигән нәрсәләренә исемнәре һәм кайсы җирлектән икәнлекләре язылган. Болар һәркаюсы — падишаһ балалары. Әмин бай боларны күргәч, хәйран калып, бер кешедән сорады:

— Әй туган, бу падишаһ балалары ни өчен скрипка уены өйрәнәләр? — диде.

Ул кеше:

— Әй җегет, бу дворецның ишегеннән кер дә сора, әлбәттә, әйтерләр, — диде.

Әмин бай, сабыр итәргә түземлеге җитмичә, дворецның ишегенә барып җитсә, күрде: ишек өстенә алтын берлән язган: **«Яшь вакытта җегет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз. Әлбәттә, һич булмаса, җитмеш төрле һөнәрне үгрәнсен. Каю һөнәр хәляллык [кулланырга яраклы], иясенә файда китерсә, шунысын истигъмаль кылсын [файдалансын], ул бервакытта да зарар китермәс, ниндәй һөнәр булса да. Әлбәттә, данын күрер»**. Әмин бай башын салып уйлап, акча һәр заман табыладыр, әмма һөнәр яшь вакытта гына табыладыр, тукта, бән бу һөнәрне үгрәнәем, дип, ишектән керде. Бер бүлмә, берничә өстәл бар, язучылар утыра. Әмин байга урын биреп:

— Нә хезмәт боерасыз? — диделәр.

Әмин бай әйтте:

— Бән скрипка үгрәнмәк буламын, нә тарика [нинди ысул белән] үгрәтәсез, — диде.

Әйттеләр:

— Бер елда Алмаз падишаһ балалары ашаганны ашарсыз, алар берлән бергә үгрәнерсез, хакы — мең алтын, — диделәр, — әмма белмәсәң, бер елдан артык асрамамыз, әгәр торасың килсә, янә еллык акча бирәсез.

Әмин бай:

— Хуп ула, — дип, кәмәрне чиште һәм мең алтынны санап бирде. Аның кулына кәгазь язып бирделәр.

Әмин бай кәрвансарайга кайтып йоклады. Иртә берлән Миргаяс байга әйтте:

— Бән бу шәһәрдә бер сәнә [ел] калмак булдым, бәнем берлән мәдрәсәдә укыган егет тугры килеп, кичә зыяфәт кылды [кунак итте]. Ул бер байның углы икән, миңа әйтте, монда кал, әлбәттә, бер сәнәдә күп файда хасил итәрсең, дип, миңа муафыйк күренде, хуш буласыз, — диде һәм видаглашып [саубуллашып], аргамагына менеп, тугры багка китте.

Аргамагын сатып, падишаһ балалары янына кереп, кулына скрипка алды һәм үгрәнергә бер елга калды. Скрипкага шулкадәр остарды ки, хәтта остазы хәйран каладыр иде. Бер ел тулгач, Әмин байга кантордан төшеп әйттеләр:

— И Әмин бай! Ел тулды, нә фәрман кыласыз? Әгәр калмак теләсәгез, 1000 алтын бирәсез, — диделәр.

Әмин бай «аһ» итеп:

— Кайда миндә мең алтын? Бер парә дә юк, — дигәч, кантор Әмин байга бер ишәк, юл расходына биреп:

— Хуш-хуш, сафа килдеңез, хуш-хуш! — дип калды.

Бичара Әмин бай ишәгенә менеп, бер кәрванга ияреп, чөнкәрә-чөнкәрә ишәкне

куып, кайда Бохараи шәриф, дип юлга чыкты. Берничә заманнан соң кәрван Бохарага җитешкәч, Әмин бай кәрваннан калып, ялгызы, ишәкне һәм ташлап, йортларына намаз дигән вакытында кайтып керде. Атасы каршы чыгып, анасы каршы чыгып, Әмин байны кочаклап алдылар. Өйгә алып кереп, бик тиз пылау сусып, дәстәрханга куйгач, исән-иминлек сорашып бетергәч, Габдулла бай сүз башлады:

— И углым, ни маллар алып кайттың? — диде.

Әмин бай әйтте:

— И бәнем гыйззәтле атам берлән анам! Бән яшьлек кылып, яшьлек хатасына алданып, мең алтын биреп скрипка үгрәнеп нә мал китердем, нә мал күрдем, бар гаеп миндә булса да, сезләрдән мәрхәмәт, гафу сорыйм, — диде.

Габдулла бай җәмагате берлән бу сүзне ишеткәч бик елап:

— Аһ хәсрәт! Ваһ хәсрәт! **Адәмнәрнең балаларыннан көлгәнемез җитеште**, — диделәр.

Бераздан Габдулла бай җәмагате берлән киңәш итте:

— Углымызны кеше күзенә күргәзмәек, янә мең алтын биреп, Фәйрузабад шәһәренә иртәгә кәрван чыга, шул кәрван берлән җибәрик, — диде.

Хатыны әйтте:

— Хуп ула, — диде.

Әмин байның кулына мең алтын биреп, үтенделәр:

— Ничек булса да, биш дөя булса да, мал алып кайт. Безнең йөземезне күршеләремез алдында оятлы кыла күрмә, — диделәр.

Бичара Әмин бай, әлбәттә:

— Сәламәт булсам, мал алып кайтырмын, инде нәфесемә болай ирек бирмәм, — дип, атасыннан мең алтынны санап алып, яхшы чапаннар киеп, яхшы атка менеп, байбичә булып, мәхәллә кешеләренә күренмәстән кәрванга кушылып, Фәйрузабадка сәфәр кылды.

Берничә вакыт кәрван берлән сәфәрдә хозур кылып, Фәйрузабадка килеп җитте. Кәрвансарайга төштеләр. Берничә сәгать истирахәттән соң, юлдашлары берлән Фәйрузабадны тамаша кылырга чыгып, бер зур урамга чыкты. Күрделәр: урамда никадәр кеше булса, һәркаюсы урамның бер тарафына баралар. Бу адәмнәр анда, әлбәттә, бер тамашага бара торганнардыр, без дә барыйк, дип адәмнәр артыннан киттеләр. Урам башына җиткәч, адәмнәр бер зур бакчага керделәр. Әмин байның юлдашлары әйттеләр:

— Әйдәңез, бу бакчаны тамаша кылыйк, — диделәр.

Әмин бай:

— Юк, бән тамаша кылмаем, — дисә дә, юлдашлары ихтыяр бирмәеп, барыбер алып керделәр.

Кергәч, күрделәр: бер зур бик нәкышле бакча, ничә җирдә мусыка уйнап, ничә җирдә шагыйрьләр шигырь әйтеп, ничә җирдә кыйсса укып, һәр адәмгә төрле уеннар берлән бакчада йөрүчеләрнең хозурын китереп торалар. Болар да, һәр уенны карап йөргәндә күрделәр — бер зур бина, әллә ничә тәрәзәсе бар, һәр тәрәзәдә ничә кандильләр, бәгъзесендә ал ут, бәгъзесендә зәңгәр утлар янып тора. Бу бинаның эчендә әллә ничә нәфис егетләр, һәркаюсының кулында алтын саплы каләм һәм зөбәрҗәт савыт берлән кара кәгазьләре сәдәф [перламутр] кеби ялт-йолт килеп, язу язып торалар. Араларында бер зур сакаллы адәм бу егетләрне язуга өйрәтәдер. Бу бичара бохаралылар, хәйран калып, бер яхшы күренгән адәмнән сорадылар:

— Болар ниндәй егетләр, ниндәй язу өйрәнәләр, — дип.

Ул кеше әйтте:

— Болар падишаһзадәләр. Дөньяда ниндәй язу булса, шуны өйрәнәләр һәм ниндәй

язуны бар күрсәләр дә, шуны язу итеп язалар. Бу шундый һөнәр, ул — һөнәрләрнең рәисе. **Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр аз яшь вакытта**, дигәннәр, — диде.

Бичара Әмин бай, бу егетләр һөнәр өйрәнгәнне күргәч, аһ итеп, йөрәге ут кеби янып: «Бән юк һөнәргә мең алтын бетергән икәнмен. Һөнәр — скрипка булырмы? Бу язуны өйрәнсәм, Бохарага кайтып әмирнең язуын бер күрсәм, күчереп, Әмин байга ун мең алтын бирелсен, дип язып, хәзинәдардан ун мең алтын алсам, әлбәттә, бу һөнәр буладыр! Юкса, бән скрипка уйнап, бер тәңкә акча ала белмәем. Аеруча, безнең Бохарада кем скрипканың кадерен беләдер? Бән, кулда форсат барында, бу язу һөнәрен үгрәнәем», — дип уйлап, юлдашлары берлән кәрвансарайга кайтып йоклады.

Иртәгәсен юлдашлары берлән видаглашып:

— Бән бу шәһәрдә бер сәнә каламын, — дип, атына менеп, тугры бакчага китте.

Канторга кергәч, Әмин байга урын бирделәр. Әмин бай утырып, сорады:

— Язу үгрәнер өчен ничек аласыз? — дип.

Җавап бирделәр:

— Бер елга тәмам ашау-эчү берлән падишаһ балалары янында йөрерсез — мең алтын аламыз, — дип.

Әмин бай:

— Бән мең алтынга разыймын, — дип, мең алтын санап бирде.

Аннары, Әмин бай, атны сатып, ак якалар, канатлы камзоллар алып, падишаһ балалары янына керде һәм кулына каләм алып язуга утырды. Төгәл бер ел үгрәнеп, әллә ничә мәртәбә остаз булып, язу язып биш-ун алтын акча кантордан алды. Остазы һәм тәхсин кылды [мактады] Әмин байның оста булуына, ләкин, нә чара, бу бичарага зыян уларак, ел тулып, беркөнне Әмин байны кантордан дәшеп әйттеләр:

— И Әмин бай! Ел тулды. Нә диячәксең? Әгәр калырга теләсәң, эстәсәңез, мең алтын бирәсез, — диделәр.

Әмин бай, бичара, күзләрен тутырып, аһ итеп:

— Миндә кайда мең алтын? Бер парә дә юк һәм бер кисәк нан [икмәк] табарлык һөнәр дә юк. Бән атам берлән анам каршына нә йөз берлән кайтачакмын? — дип еглады.

Кантор, мәрхәмәт кылып, кулына бер алтын һәм менәргә ишәк биреп, озатты. Әмин бай, ишәккә менеп, урамга чыкты. Бер кәрван барганын күрде. Аннан сорады:

— Бу кәрван кайда бара? — дип.

Әйттеләр:

— Бохара аркылы Һиндстанга бара, — диделәр.

Әмин бай шул кәрванга кушылып, берникадәр вакыттан соң, Бохарага кайтып җитте. Ишәген кырда калдырып, акрын гына өйләренә керде. Атасы-анасы куанып, еглап, кочаклап күрешеп, дәстәрхан җәеп, нигъмәт куеп утыргач, Әмин байдан сорадылар:

— И күз нурымыз! Нә улды? Файдамы булды? Нә маллар кайтачак? — дигәч, Әмин бай күзләрен тезенә таба куеп:

— И газиз атам берлән анам, гаеп миннән, мәгъфирәт [гафу кылу] сездән. Бән мең алтын биреп язу үгрәндем, — диде.

Атасы Габдулла бай аһ итеп:

— Бән сине 18 яшькә кадәр мәдрәсәдә укыттым. Син шунда язу үгрәнгән идең, шул язу җитәр иде. Хәер, нә файда? Буласы эш булган! Имди баламыз, ничек булса да, моннан ары болай эш кылма! — диде.

Хатыны берлә киңәш кылып, Габдулла бай әйтте:

— И углым, Әмин бай! Без сине янә сәфәргә чыгарамыз. Мачин тарафына, Әхмәдабад шәһәренә. Бүген кәрван чыгадыр, син шул кәрван берлән Әхмәдабадка бар. Мең алтын бирәмез, исраф кыла күрмә, актык алтыннарымыз. Мал алып кайта күр. Дусларымыз хафа булмасын, дошманнарымыз да шат улмасын, — дип еглап, мең алтыннарны биреп, канатлы камзолларны салдырып, шаһичапаннар кидереп, яхшы атка мендереп, кәрванга кушып җибәрделәр.

Бичара Әмин бай кәрван берлә барганда үз-үзенә: «Әхмәдабадка сәламәт барып җитсәм, һич тамашага бармам, насыйп булса, мал алырмын, атам берлән анам еглап әйттеләр, актык алтыннарымыз дип, һәм картайдык, ничек көн күрермез, дип бик егладылар. Гакылны башка җыеп, мал алып, кулда мал барында эшне карарга кирәк. Бу бән үгрәнгән һөнәрләр бернәрсәгә дә ярамый, чөнки әмир булып, язу язып, хәзинәдардан [казначыдан] акча алырга язу һөнәре генә җитмидер, хаин [хыянәтче] булырга да кирәк. Бән хыянәтнең һәм хаинлекнең ни икәнен белмәем. Хаинлеккә гайрәт юк миннән», — дип әйтеп бара иде. Үз-үзен беркетеп юлда барып, беркөн Әхмәдабадка җитте. Бер кәрвансарайга төшеп, истирахәт кылып, вакыт хушлагач, болар янына бер дәллял [маклер] килеп әйтте:

— И җәмәгать, бер байда ничә елдан бирле сатылмай яткан зәгъфран [шафран] бар, нәкыд [кулда булган мал] акчага арзан бирәдер, — диде.

Әмин бай:

— Ярый, бән аламын, — диде һәм дәллял берлән бергә байның дөканенә барды.

Бер яшь егет зәгъфранны күрсәткәч, бик арзан бәһагә килештеләр. Әмин бай хисап кылып күрде: мең алтынлык булды. Алтыннарны бирим дигәндә, кибеткә пар ат җиккән, яхшы киемнәр кигән кеше килеп керде дә, Әмин бай берлән күрешеп:

— Хуш килдеңез, алучымыз хәзрәтләре! — диде.

Бу килгәч, бай шатланып:

— Рәхмәт, бездә ничә ел сатылмый ятты, без зарар кылдык, инде Аллаһ сезгә файда насыйп әйләсен, — диде.

Әмин бай әйтте:

— Бән үз вакытым берлән зәгъфранны алырмын, акчасын хәзер бирәем, — диде.

Бай әйтте:

— Яхшы, әйдә, бән отельга барамын, шунда кофе эчәрмез, хисапны һәм шунда күрермез, — диде.

Әмин байны, фаэтонга утыртып, бер зур отель бакчасына алып бардылар. Бакчага кергәч, бай әйтте:

— И Әмин бай! Сезнең Бохарада мондай тамашалар юктыр, бән сиңа күрсәтәем, — дип, бакчада йөртте.

Ничә җирдә мусикалар уйнап, каһвәләр эчеп, шигырьләр әйтеп торалар. Боларның һәр җирен бай, Әмин байга берәм-берәм, бу мондый уен, бу мондый шигырьләр, дип күрсәтеп йөрде.

Бай, уеннарны күрсәтеп бетергәч, әйтте:

— Әйдә, Әмин бай, бән сиңа бер гаҗәп эш күрсәтәем, — дип, бер мәрмәрдән салган йортка алып керде.

Кергәч, күрделәр: йортның эчендә, әллә ничә җирдә өстәлләр бар, һәр өстәлгә икешәр егет утырып шатранҗ [шахмат] уены уйныйлар, тактасы алтыннан, шакмаклары бәгъзесе — алмаздан, бәгъзесе кызыл якуттан.

Бай әйтте:

— И Әмин бай! Күр, бу егетләрне. Болар һәркаюсы бер зур падишаһның углы. Болар шатранҗ уены үгрәнәләр, — диде.

Әмин бай әйтте:

— Бикяр [файдасыз] һөнәр, — диде.

Бай әйткән:

— Юк, Әмин бай, хата әйтәсез, **шатранҗ уены — җәмигъ һөнәрләрнең падишаһы, чөнки адәмнең зиһенен якты кыладыр, гакылны куәтле итәдер. Моның кеби хуш һөнәр булмас**, — дигән.

Әмин байның кан тамырлары хәрәкәтләнеп, үзендә ихтыяр калмастан, байдан сорады:

— Канторы кайда? — диде. Бай канторны күрсәтте.

Әмин бай әйтте:

— И бай, бән зәгъфран сәүдәсеннән кайттым, шатранҗ һөнәрен белмәй такатем юк, — диде.

Канторга кереп сорады:

— Нә тарика [нинди ысул белән] үгрәтәсез? — дип.

Җавап бирделәр:

— Падишаһ балалары берлән бергә ашап-эчеп, бергә тәрбиядә улып үгрәнерсез, елына — мең алтын, — дип.

Әмин бай калтырап:

— Хуп, — дип, алтын санап бирде.

Кәрвансарайга барып, атны алып килде, янә атны-чапанны сатты. Казаки киеп, падишаһзадәләр янына кереп, шатранҗ үгрәнергә калды. Мескин Әхмәдабад бае, зәгъфран саттым, дип сөенгән иде, юкка алтыннарны алмадым, дип хафа булып кайтып китте.

Хәбәр нә улса улды, без килик Әмин бай хәленә, Әмин бай бер ел шатранҗ үгрәнеп, шулкадәр оста булды, остазны 12 шакмак берлән һәр заман калдырадыр иде. Һәрбер уенчы мактады, ләкин ни чара, ел тиз үтеп китеп, Әмин байны конторга дәшеп әйттеләр:

— И гыйзззәтле Әмин бай! Янә бер сәнә калачакмы сез? — диделәр.

Ул гакылы башына килеп, аһ итеп:

— Бән нә кылдым? Аллаһ ахырысын хәер әйләсен! Кайда миндә мең алтын? Бер пул [акча] да юк. Хәтта Бохарага кайтыр хәлем юк, — дигәч, кантор, кызганып, бер алтын берлән бер ишәк биреп озатты.

Шул көннәр Бохара ягына бер кәрван чыга икән, Әмин бай, шул кәрван берлән бергә кушылып, Бохарага кайтып китте. Берничә вакыттан соң Бохарага җиткәч, Әмин бай ишәген кырга җибәреп, үзе өйләренә кайтты. Атасы берлән анасы күрешеп, күп шат улып, дәстәрханнар җыеп, нигъмәтләр куеп ашаганда сорадылар:

— И углымыз, нә маллар алдыңыз? — дигәч, Әмин бай еглап әйтте:

— Мал алмадым, бән шатранҗ уены үгрәндем, мең алтын биреп, — диде.

Атасы берлән анасы егладылар. Хәер, еглап нә файда, бетәсе алтыннар беткән, буласы эш булган, Габдулла бай хатынына:

— Инде безгә Бохарада торып булмас, дәүләт бетте, адәмнәр бездән көләрләр. Без Сәмәркандка китик. Йортымызны сатармыз, кибетемезне сатармыз. Ләкин Әмин бай өйдән чыкмасын, күршеләремез күрмәсен. Халыкка, углымыз Сәмәркандны яраткан, сәүдә кылырга анда яхшы икән, аның анда белешләре күбәйгән, безне Сәмәркандка чакырып хат язган, шуның өчен кибетемез берлән йортымызны сатамыз, дип әйтик, — диде.

Дәвамы бар

Текстны басмага ***Рәйсә Шәрәфиева*** *әзерләде.* ■

---

[1] Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр аз дигән сүз — раст сүз. Хикәят / Мөхәммәдҗан вә борадәре Шәрифҗан әл—Кәримиләрнең хәраҗаты илән. — Казан: Домбровский табгыханәсе, 1896.

ӘХЛАК

К.Бикколый, Г.Госмани

13. ЯЛГАНЧЫЛЫК

Алдау вә ялганчылык бик начар вә ярамас холыклардан булып, бар милләт каршында кабих вә чиркәнеч сыйфаттыр. Ялганчылык дигәнебез, һич булмаган эшләрне бар итеп, әйтмәгән вә сүзләмәгәнне әйтте вә сүзләде, күрмәгәнне күрдем, дип кешене алдау, ышандырудыр. Бу исә, үзең кеби адәм балаларын хурлау, вә җәберләү булганлыктан, шәригатьтә бик гөнаһ вә хәрәм эш. **Ялганчы кешенең бер ялган сүзе беленсә, аның мең мәртәбә дөрес сүзенә дә ышанучы булмас.** Ялганчы кешенең кеше арасында һич кадере вә игътибары булмый, аңарга ышанычсыз, алдаучы диләр. Ялганчының яман аты бөтен дөньяга җәелер. Яман ат илә йөрүдән дә яман ни булыр? Бабаларыбыз: *«Атың чыкканчы — җаның чыксын!»* — дигәннәр. Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре ялган сөйләүдән тыеп: *«Ялган сөйләмәгез! Ялган сөйләүчеләргә бик каты газап булыр!»* — диде. Пәйгамбәребез өч нәрсә олуг гөнаһлардан, диде. Аларның берсе — ширек. Икенчесе — ата-анага гөнаһлы булу. Өченчесе — ялган шәһадәт вә ялган сөйләү. Ялган сөйләү — монафикълык галәмәте булып, Аллаһы Тәгалә каршында аның җәзасы үзенә, аның сүзенә ияручеләргә булыр. Мөселман булган кеше мондый монафикъ була торган начар вә яман сыйфаттан сакланырга тиеш. **Тугрылык — изгелек-яхшылыкның зиннәте булган кебек, ялганчылык — явызлык вә начарлыкның галәмәтедер.** Сез, балалар, мондый начар вә яман сыйфаттан бик саклана күрегез!

14. НӘМИМӘ (СҮЗ ЙӨРТҮ)

Нәмимә дип сүз йөртүгә әйтәләр. Бер кеше килеп, икенче берәү хакында

Касыйм Бикколый

яман сүз сөйләсә, ул сүзне ул кешегә ирештерү — нәммамчылыктыр. Бу эш шәригатебездә бик зур гөнаһлы, бик олуг гаепле, явыз холыклардан. Сүз йөртүче икейөзле, ике телле, ягъни ике яклы булып йөрүчедер. Аннан бик сакланырга кирәк. Ул кеше синең яныңда бертөрле сөйләп, берәүне синнән сөйләтер дә, синнән ишеткән сүзне хәзер икенче кешегә барып җиткерер. Сине оятлы итәр вә мөселман карендәшең илә бозыштырып кычкырыштырырга, талаштырырга тырышыр. Шуның өчен галимнәр: *«Сүз йөртүчелек зарары шайтанның зарарыннан олуграктыр»,* — дигәннәр. Чөнки **шайтан сиңа күренми, кальбеңә генә вәсвәсә салыр. Әмма сүз йөртүче сиңа күренеп, тел илә сөйләп, сине тәмам ышандырып, карендәшеңә дошман итәр.** Мондый икейөзле кешеләр — дөнья вә ахирәттә үкенечтә калучы бәхетсез кешеләрдер. Пәйгамбәребез: *«Бер кеше дөньяда ике телле булса, кыямәт көн аңа Аллаһы Тәгалә уттан булган ике тел бирер, шуның илә газап кылыныр»,* — диде. Сез, балалар, үзегез андый яман холыктан сакланганыгыз кеби, андый яман

Дәвамы. Башы журналның 2014 елгы 9 нчы санында.

сыйфатта булган кешеләргә ышанудан да бик сакланагыз. Андый икейөзле, ике сүзле кешеләргә ышану нигездә ярамас, чөнки алар хәрәм булган эшне хәләл күреп, зур гөнаһка төшеп йөрүче, мөселманнар каршында шәһадәте дөрес түгел кешеләрдер. Әгәр андый кеше сезгә килеп, фәлән кеше сине шулай әйтте, болай әйтте дисә, син аңа инанып карендәшеңә дошман була күрмә, бәлки бу кешенең үзенә дошман күзе илә карап, моннан соң андый ике телле булып йөрүдән сакланырга кушып, күркәмлек илә вәгазь-нәсыйхәт кыл.

Хәкимнәрдән берсенә үзенең дусларыннан бер кеше килеп: *«Әфәндем, сине фәлән кеше бик яманлап сөйләде»,* — дигәч, хәким: *«Әфәндем, хуш алайса, минем яннан ерак бул, син өч төрле ярамаган эшне китереп, зиярәт [күрешү] савабын югалттың. Әүвәл, карендәшемә мине дошман иттең. Икенчедән, тыныч күңелемне хафага салдың. Өченчедән, мин сиңа һәрвакыт инана идем, имди үзеңне ышанычсыз кылдың»,* — диде.

15. ӘДӘПЛЕ БУЛУ

Әдәп-инсаф дигән нәрсә — бик газиз вә бик хөрмәтле нәрсә. Адәмнең хайваннан аермасы гакыл илә булса да, әдәпсез гакылдан гына файда юктыр. **Гакыл өстенә әдәп — нур өстенә нур.** Адәмнең олуглыгы нәсел вә нәсәбе илә булмыйча, гакыл вә әдәпле булуы иләдер. Әдәпсез кешенең нәселе никадәр олуг вә мәртәбә иясе булса да, аның адәмнәр арасында бер тиенлек кадере юк. **Бәлки нәселе олуг булган кешеләргә, хәзрәт вә дамелла кебиләрнең баласына бигрәк тә әдәпле булу тиештер.** Әдәпсез балалар үзләренең генә түгел, ата-аналарының да кадерен җибәреп, дәрәҗәсен төшерерләр. Сез, балалар, әдәпле булырга бик тырышыгыз! Әдәпле булу — әдәпсез эшләрдән вә ярамаган холыклардан саклану илә булыр. Бер бик әдәпле, гакыллы кешедән сорадылар: «Син бу кадәр әдәплелекне кайдан өйрәндең?» — дип. Әдәпле кеше җавабында: *«Надан вә әдәпсез кешеләрнең наданлыгыннан вә әдәпсез фигыльләреннән гыйбрәт алып өйрәндем»*, — диде. **Байлыкның кадере юмартлык белән булган кеби, гакылның кадере дә әдәп иләдер.**

Шулай булгач, **кешенең кадере дә сакал илә булмыйча, әдәп вә гакыл иләдер. Әдәпсез карт әдәпле балалардан берничә дәрәҗә түбән булыр.** Ашау-эчү, сату итү, кешеләр илә мәҗлестәш булу, сүз сөйләшүләрнең һәркайсының үзенә махсус әдәбе бар. Боларны китаплардан карап белерсез.

16. ГЫЙЛЕМ ВӘ ҺӨНӘР

Гыйлемне һәркемгә гыйбадәт кылу өчен өйрәнү кирәк булган кеби, дөньяда тереклек итү өчен бер һөнәр өйрәнү дә кирәк. **Гыйлем үзенең иясен олы мәртәбәләргә ирештерүче газиз вә шәриф нәрсә булган кеби, һөнәр дә үзенең иясен мохтаҗлыктан вә фәкыйрьлектән азат итүче бик олуг вә хөрмәтле эштер.** Пәйгамбәребез с.г.в.: *«Ирләр өчен яхшы һөнәр — тегүчелек, хатыннар өчен — җеп эрүчелек»,* — дип, бер һөнәрне өйрәнергә тиеш идекен белдергән. Һөнәрнең ниндиендә дә гаеп юк. **Һөнәр һичвакыт синнән ашарга сорамас, бәлки үзе сине ашатыр.** Бабаларыбыз: *«Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз»*, — дигәннәр. **Никадәр күп һөнәрең булса, шулкадәр хөрмәтең артып, дөнья мәшәкатьләреннән, көн тарлыгыннан азат булырсың.** Һөнәрсезлек — бик начар эштер. Һөнәрсез кеше ярлы була, йә угры була, мохтаҗлыкта калып, ишектән-ишеккә тилмереп, сорап йөрергә кала. Сау булып та, сорап йөрүдән дә яманлык булмас.

17. КӨЛҮ

Күп көлү — ярамас холыкларның башыдыр. **Күп көлгән кеше үзен яман сыйфатлардан саклый алмас, авызына ни килсә, шуны сөйләр, күп вакыт ялган сөйләүдән дә тартынмас.** Адәмнәрне көлдерәм дип, булмаган эшләрне дә бар итеп сөйләр — мондый кеше әхлаксыз, тәрбиясез кешедер. Күп көлешү шәригатебездә дә бик зур

гөнаһлы эштер. *«Күлеп гөнаһ кылучы еглый-еглый тәмугка керүчедер»,* — күп көлүче кешенең халык каршында да һичбер абруе булмас. Аның күп сүзе ялган булыр. Ялганчы кешегә һичкем ышанмас, чын сүзенә дә ышанучы булмас. Ул халык каршында ышанычсыз, кадерсез кеше булып калыр. Сез, балалар, урынсызга гаҗәпсез көлүдән бик сакланыгыз.

Хакимнәр: *«Гаҗәпсез көлү — ахмаклык, гакылсызлык галәмәте»,* — дигәннәр. **Чөнки гакылы камил булган кеше дөньяда үз кирәген кайгыртып, юк-бар нәрсә өчен көлергә бушамас.** Күп көлү — бигрәк эшсез кешеләр эшедер. **Эшсез, хезмәтсез, уйнап көлеп гомер уздыручы хайван — дөньяда яман, бәхетсез, гакылсыз кешедер.**

18. КАРШЫЛЫК

Ата-анага хилаф булып, аналарның сүзен тотмау, хәлфә вә остазларның нәсыйхәтен кабул итми, изгеләргә һәм итагать кылмый йөрүне каршылык диләр. Мондый балалар иң холыксыз, яман балалардандыр. Яхшы кеше һичвакыт ата-анасына, хәлфә вә изгеләргә каршылык кылмый, аналарының әйткән сүзләрен, кушкан хезмәтләрен җиренә җиткерергә тырыша. **Үз гакылың илә генә йөреп, үз теләгәнеңне генә кылу — хайваннар сыйфатыдыр.**

Син никадәр гакыллы вә никадәр белекле булсаң да, остазларыңнан вә олуглардан артык белә алмассың. Изгеләр сине һичвакыт яман вә ярамас эшкә кушмаслар. Бигрәк тә хәлфәләргә каршы булудан, аларның нәсыйхәтен тотмау, үз белдегегез илә йөрүдән саклана күрегез.

Аналар сүзе илә гамәл кылсагыз, дөньяда вә ахирәттә бәрәкәт табарсыз. Әмма хәлфәләргә итагать кылмый, үз ихтыяры илә теләгәнен кылучы һәм ата-анасына каршылык итүче — иң бәхетсез, холыксыз, ахмак кешеләрдән булып, дөнья вә ахирәттә һәлак булачактыр. Аллаһы Тәгалә андый каршы вә явыз холыклардан барча мөселманнарны сакласын иде. Амин.

19. ЯМАНЛЫККА КАРШЫ — ИЗГЕЛЕК

Берәү сиңа иткән яманлык вә явызлыкка каршы изгелек итү — иң гүзәл холыкларның берседер. **Гакыл ияләре дошманнарының яманлык вә начарлыкларына каршы сабырлык илә һич сүз әйтми, изгелектә булып, аларны җиңәрләр.**

Хәзрәти Сөләйман с.г.в.: *«Дошманың ач булса — икмәк, сусыз исә су бир. Моның илә аның башына ут яктырырсың, әмма Аллаһы Тәгалә сиңа аның каршысына ярдәм итәр»,* — дигән. Дошманыңа каршы ул миңа нинди яманлыклар кылды исә, мин дә аңарга шуларны кайтарам, димә. Чөнки син яманлыкка каршы яманлык итәчәк булсаң, үзең сөймәгән начар эшне кылган булырсың да, кабих вә яман дигән адәмнең үзе булырсың. **Олуг, мәртәбәле адәмнәр дошманнарны ярдәм вә изгеле эшләре илә йөзләрен кызартырлар.** Ислам дине кешегә дошманлык итүдән тыеп, мәхәббәт вә дуслык илә гамәл кылырга боерыр. Дин яманлыкка каршы изгелек илә кушар. **Кайсыбер вакыт иң кечкенә бер дошман үзеңә зур кайгы булып, күптөрле зарарларга сәбәп булыр, ләкин аңарга яхшылык итсәң, бәлки аның үкенүенә сәбәп булырсың.** Солтаннарның беренә: *«Фәлән кеше сине хурлый, синең хакыңда яман сүзләр сөйлидер»,* — дигәч, солтан: *«Әүвәл аның болай сөйләвенә яхшылап төшенергә кирәк, үзебездән берәр төрле сәбәп юк микән?»* — дигән. Ул бичарага ач вә ялангач вә мохтаҗ вакытында сарай тарафыннан һич ярдәм булмавы мәгълүм булу илә, солтан тарафыннан аңарга күп ярдәм вә изгелекләр ителде. Ул адәмнең дә солтанны сүгүе вә хурлавы мактау вә зурлауга алмашынды. Солтан моны күреп: *«Халыкка яхшы күренү дә, яман күренү дә үз кулыңда икән!»* — дип әйткән.

Дәвамы бар

Текстны басмага
***Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.*

КАРА ГЕНЕРАЛ

Рәис Зарипов

Уфадагы фатирында сөйләшеп утырганда, Даян ага Мурзинның, көтмәгәндә, кисәк кенә: «Генерал Власовны без кулга алдык...», – дип әйтеп куюына баштагы мәлне бик үк игътибар биреп бетермәгән идем. Дөресрәге, шактый ук бәхәсле булып тоелган фикерне колак тирәсеннәнрәк уздырып җибәрдем шикелле. Әмма баштан һич тә чыкмады үзе, гел генә күңелне кыбырсытып, борчып торды.

Ни бу? Бөек Ватан сугышына бәйле тагын бер серле табышмак яки вакыйга-табышмы? Әллә инде Даян ага бераз ялгышамы? Алай уйлар идең, үз акылында данлыклы партизан, хәтере дә бер дигән. Сөйләгәннәре ышандыра, дәлилләре саллы, һәр сүзен нык-лап уйлап, өздереп әйтә. Тугызынчы дистәсен төгәлләп килүенә карамастан, корычтай ихтыяр көче ташып торучы һәм күзгә туры карап әңгәмә коручы, канлы сугыш кырында әллә күпме дәһшәтле вакыйгаларның шаһиты булган каһарман шәхес, «Кара генерал» аты белән Гитлерның шәхси дошманына әйләнгән партизаннар бригадасы командиры юк-бар нәрсә сөйләмәс. Күренеп тора: ниһаять, ул хакыйкатьне ачарга карар кылган!

Сугышның соңгы биш аенда Мурзин партизаннарына власовчылар белән еш чәкәләшеп торырга туры килә. Ә инде апрель ае керүгә, Чехиягә Власов карамагындагы хәрби көчләр күпләп агыла башлый. Вермахт ягында сугышкан совет коллаборационистларының күбесенең язмышлары биредә сынала. КОНР (Россия халыкларын азат итү комитеты) Кораллы көчләре башкомандующие, Кызыл Армия генерал-лейтенанты, КОНР Кораллы көчләре генерал-лейтенанты, Вермахт генерал-полковнигы ставкасы буенча (кайбер чыганакларда — СС ведомствосы буенча) хезмәт хакы алучы **Андрей Власов** үзе дә Чехия башкаласы янында әсир төшә. Әмма тарихи хезмәтләрдә һәм күпсанлы авторларның эзләнүләрендә Власовны кулга алу бертөрле генә яктыртылмый. Иң сәерсендергәне — шул вакыйгага бәйле рәсми чыганакларның әле һаман да бәян ителмәве. Үзеннән-үзе сорау туа: бәлки бу чынбарлыкны яшерү өчен махсус шулай эшләнә торгандыр? Дистә еллар узгач та сөйләргә ярамаган нинди сер соң ул? Ни өчен Даян ага моңарчы бу турыда дәшмәгән? Хәер, монысы инде артык сорау, билгеле. Әгәр хәрби серне саклау турында имза куйгансың икән, телеңне тешләвең хәерле. Әнә ич, «Дошман тылындагы фронт» дигән документаль китабында бу турыда ләм-мим — бернинди мәгълүмат та юк. Легендар диверсант-разведчик май башында Злин каласындагы (1949-1989 елларда — Готвальдов) мәйданда бул-

Дошманның өнендә хәрәкәт итүче
Даян Мурзин партизаннары,
Власовтан тыш, янә бер алман
генералын да әсирлеккә
төшерәләр.

ган митинг турында яза һәм күп нокталар куеп, дистә көнгә алга «сикерә».

Шуның белән, ветеран бригаданың сугышчан юлын тасвирлаудан туктый һәм гомуми нәтиҗәләргә күчә. Югыйсә, милләттәшебез **Даян Мурзин** җитәкләгән **Ян Жижка** исемендәге 1 нче **Чехословакия** партизаннар бригадасы өчен сугыш алай гына тәмамланмый: Кызыл армия белән бергә алар Чехияне тулысынча азат итүдә катнаша, СС обергруппенфюреры **Ганс-Адольф Прютцман** оештырган **«Вервольф»** партизан отрядларына һәм **Карпат** таулары аша үтеп кергән бандерачыларга каршы көрәшә.

***

Никадәр генә гаҗәп тоелмасын, дошманның өнендә хәрәкәт итүче Даян Мурзин партизаннары, Власовтан тыш, янә бер алман генералын да әсирлеккә төшерәләр. Әйтүе генә ансат. Бу бит — Гитлер гаскәрләре мыжлап торган һәм Мурзинга кадәр бер генә партизан да аяк баса алмаган Чехия һәм Моравия протектораты территориясе. Бу инде Брянск урманнарында, Белоруссия сазлыкларында яисә Карпат тауларында посып ятып кына кылынган батырлык түгел. Каһарман милләттәшебез шәхсән үзе генералны кулга алуда катнашмый, әмма әлеге уникаль операцияне оештыруга һәм башкарып чыгуга башыннан ахырына кадәр җитәкчелек итә. Ә вакыйга 16 нчы танк дивизиясе командиры, генерал-лейтенант Дитрих фон Мюллерның элеккеге яхшы танышы барон **Дубскийга** кунакка килүеннән башлана. Бу визитның төгәл вакытын баронда хезмәтче булып эшләүче бригада элемтәчесе **Анчо** белеп ала һәм тиз арада партизаннар отряды командиры **Ольга Франтишковага** хәбәр итә. Аннысы, үз чиратында, бригада командиры Мурзинга донесение җибәрә. Генералны кулга алган вакытта гестапоның **Кромержиж** каласы бүлеге башлыгы, СС полковнигы Коближек үтерелә.

Даян ага үзе Мюллер белән бик озак мәшәкатьләнүләрен сөйләде. Генералны кулга алу белән, тиз арада Киевка хәбәр итәләр. Берничә сәгать үтүгә Мурзин радистлары 2 нче Украина фронты командующие маршал **Малиновскийдан** радиограмма ала. Маршал алман генералын әсирлеккә төшергәннәре өчен партизаннарга рәхмәтен күндерә һәм аны **Зур җиргә** озату буенча чаралар күрә башларга куша. Әмма, башта-

гы мәлне, самолёт килүе тоткарлана, аннары алман гаскәрләренең партизаннарга каршы фон Мюллер өчен «үч алу» белән бәйле зур масштаблы һөҗүмнәре башланып китә. **Гестапо** агентлары эзләренә төшмәсен өчен генералны бер урыннан икенче урынга күчереп йөрткән арада, Кызыл армия Словакия территориясен бөтенләй диярлек басып ала һәм, ниһаять, паризаннар «кыйммәтле йөк»тән котыла. Апрель ахырларында, Советлар Союзы Маршалы Родион Малиновский кушуы буенча, генерал-лейтенант **Дитрих фон Мюллерны** өч совет офицеры 2 нче Украина фронты штабына алып китә.

Бу урында, соңгы вакытта кайбер авторларның матбугат битләрендә, аерата Интернет челтәрендә Мурзин партизаннарының алман генералын әсирлеккә төшерүләрен шик астына алырга тырышу омтылышлары уңаеннан кайбер нәрсәләргә ачыклык кертеп китү һич тә артык булмастыр. «Кара генерал» китабы авторы Генрих Гофман, ни сәбәпледер, бер тапкыр да диярлек Дитрих фон Мюллерның исемен телгә алмый. Бу исә, үз чиратында, төрле имеш-мимешләргә җирлек тудыра. Ник дигәндә, алманнарда Мюллер фамилиясен йөртүчеләр еш очрый. Билгеле инде, андый фамилия йөртүчеләр арасында генераллар да шактый була. Вермахтның 4 нче армиясе командующие пехота генералы **Фридрих-Вильгельм Мюллер** һәм 12 нче армия корпусы командиры генерал-лейтенант **Винценц Мюллер**, ягъни мәсәлән. Шулай ук, Алманиянең яшерен дәүләт полициясе башлыгы, сугыш тәмамланыр алдыннан эзсез юкка чыккан һәм шул сәбәпле төрле мифлар тууга этәргеч биргән СС группенфюреры һәм полиция генерал-лейтенанты **Генрих Мюллер** да бар бит әле. Ни гаҗәп: әллә белмәве аркасында, әллә хаталанып, әллә махсус рәвештә, язучы **Генрих Гофманның** Даян Мурзин турында язган **«Кара генерал»** дигән китабында әсир төшкән генералны бары тик

Отто Скорцени

Скорцени гомеренең соңгы көннәренә кадәр, «Кара генерал»ны «үтерү» буенча оештырылган оперцияне уңышлы башкарып чыкканлыгына ышанып яши.

бер мәртәбә, нәкъ менә «Генрих» дип атыйлар. Богемия (Чехия) һәм Моравия протекторатында империя эшләре буенча дәүләт министры вазифаларын башкарган обергруппенфюрер (1943), СС гаскәрләре һәм полиция генералы **Карл Герман Франкның** генерал Мюллерның партизаннар кулына эләгүе уңаеннан, **Гитлерның** яраткан диверсанты **Отто Скорцени** белән очрашып сөйләшүеннән өзек:

*«—...**Злин** һәм **Всетин** тирәләрендә партизаннар бандасы хәрәкәт итә. Минем кешеләр аларны җиңә алмый. <...> Алар бөтенләй азындылар. Ике көн элек алар 16 нчы танк дивизиясе штабын тар-мар иттеләр. Югары чиндагы җиде офицер һәлак булды. Ә дивизия командиры генерал-майор фон Мюллер алар кулына эләккән. <...> Хөрмәтле Скорцени, уйлап кына кара-*

гыз, әгәр генерал Мюллер серләрне чишә башласа, совет командованиесе нинди мәгълүматларга ия булчак бит...

— Мин Генрих Мюллерны беләидем һәм мондый хәлнең булмасына ышанычым зур. Ул үзен өзгәләп ташласалар да, серне чишмәячәк, — дип Франкның сүзен бүлде Скорцени. — Җәл мескенкәй, мөгаен, исән дә түгелдер инде үзе.

— Юк шул! Минем агентлар хәбәрләренә караганда, партизаннар аның тормышын саклап калганнар һәм үзләре белән йөртәләр...»

Гофманның тагын бер хатасы — Мюллерның званиесен дөрес күрсәтмәүдә. Генерал-майор Дитрих фон Мюллер 1945 елның 19 апрелендә Мурзин партизаннары кулына эләгә, ә икенче көнне аңа генерал-лейтенант чины бирү турындагы боерык дөнья күрә. Әлбәттә, моңа аптырыйсы юк, сугышта андый хәлләр еш булгалап торган.

Табигый ки, партизаннарның Мюллерны урлап китүләре «Үзәк» гаскәрләре командующие генерал-фельдмаршал Шёрнерны соң дәрәҗәдә ярсыта, җен ачуын чыгара. Ул шунда ук Гитлер ставкасы белән элемтәгә керә һәм Чехия белән Моравия протектораты министры Франкны партизаннарга каршы нәтиҗәле чаралар күрмәүдә гаепли. Фюрер эшне тиз тота: хәрбиләргә ярдәмгә яраткан диверсантын җибәрә. Ә менә Мурзин бу яңалыкны үз каналлары аша СС оберштурмбаннфюреры (Вермахт подполковнигына тиң) Отто Скорцени Моравия биләмәләренә аяк басканчы ук ишетә. Мурзинның **«Дошман тылындагы фронт»** китабыннан өземтә:

«Гитлер Моравиягә берничә ай элек итальян дучесе Муссолинины коткарган өчен имән яфраклары бизәгән Тимер Тәре белән бүләкләнгән Скорценины җибәрде...

Безгә аның килүе турындагы хәбәрне чыкылдап торган акгвардиячеләр җыела торган «Рус клубы»на кертелгән Быков ирештерде. Әйткәндәй, клуб әгъзаларының берсе барон Юденич иде. Без Оттоның кунакка гына килмәгәнен яхшы аңладык».

СС обергруппенфюреры, СС гаскәрләре һәм полиция генералы **Карл Герман Франк** янында булганнан соң, Скорцени, Злин каласына шалтыратып, тиздән килеп җитәсен әйтә. Аның телефоннан нәрсә сөйләшкәнен Франта Новак аша 1945 елның гыйнвар аеннан Мурзинга «эшләүче» Злин полициясе башлыгы майор Дурдик ирештерә. Икенче көнне майор, кичен Скорценининың Визвицага барасын да кисәтә. Андагы бер алман бароның замогында гестапо агентлары җыеласы икән. Мондый киңәшмәнең юкка гына оештырылмавы һәм партизаннарга каршы җитди ау башланачагы төгәл билгеле булуга, Мурзин бригаданы вак төркемнәргә бүлеп, Словакия чиге янына чигенә. Нәтиҗәдә, ун меңләп солдаттан, гестапо агентларыннан, полиция һәм жандармерия хезмәткәрләреннән тупланган гаскәрләр «бушлык»ка китереп ора. Бары тик Мурзинның чигенү турында җибәргән язуын (алар белән радиоэлемтә булмый) соңарып укыган Костин отряды гына Плоштина авылында камалышта кала. Тиңсез сугышта партизаннарның барысы да һәлак була. Авылны, авиация һәм артиллерия ярдәмендә җир белән тигезләргә боерган Скорцени шул шатлыктан, Гиммлерга, Кальтенбруннерга һәм Франкка: «Мурзинның партизаннар бригадасы тар-мар ителде», — дип телеграмма суга.

Партизаннарга ул телеграммаларның күчермәләрен шул ук майор Дурдик тапшыра. Ә Алманиянең беренче диверсанты күкрәгенә тагы бер Тимер Тәре тагалар. Күп санлы авторлар, шул исәптән Мурзинның үзе раславынча, Скорцени гомеренең соңгы көннәренә кадәр, «Кара генерал»ны «үтерү» буенча оештырылган оперцияне уңышлы башкарып чыкканлыгына ышанып яши.

Мурзин бригадасы турындагы шушы кыска гына хатирәдә, партизаннарның бөтен җирдә диярлек «күз-колак»лары булуы ачык күренә. Мисал өчен, Все-

тин каласында көрәш алып баручы **Тимерхан Макоев** җитәкчелегендәге идән асты оешмасы белән ныклы элемтә булдырыла, Голешов каласындагы сак батальоны командиры майор **Йозеф Гюбнер** алар белән хезмәттәшлек итә, Злин каласындагы гестапода аларның элемтәчесе Марта эшли. «Смерть зовётся Энгельхен»(«Энгельхен» — фәрештә — ***Р.З.***) фильмы аның турында төшерелгән. Гитлерның Моравиягә киләсен хәбәр итеп, «Үзәк»не Мурзин кисәтә. Ә инде Моравия җирләрендә көннән-көн кыюлана баручы Мурзин партизаннарыннан шикләнеп, Карл Франк Гитлерны Венгриянең кара алтын чыгару төбәге Балатонга протекторат территориясе аша бармаска күндерә. Әле генә бәян иткәннәрне геройның үзе раслаганнары белән ныгытыйк:

*«Берләшмә **Мәскәү** һәм **Лондон** белән радиоэлемтәдә торды. Инглизләргә даими рәвештә алманнарның ПВО (Һава куркынычсызлыгы оборонасы) системасына һәм һава торышына кагылышлы мәгълүматлар, шулай ук идән асты көрәше алып баручылар тарафыннан **Чехия, Моравия, Судет** һәм **Көньяк Алманиядә** урнашкан хәрби объектлар, предприятиеләр турында тупланган хәбәрләр җибәреп тордык. <...> Безнең мәгълүматларны **Дрезден, Брно, Пльзень** калаларындагы заводларны бомбага тотканда һәм союзниклар авиациясе тарафыннан **Румыниягә** һава һөҗүмнәре оештырып, **Плоештидагы** нефть эшкәртү заводларын юкка чыгарганда да бик теләп файдаландылар. <...> Ватандашлар безнең СС офицерын (СС иерархиясе буенча генерал званиесенә тиңләшә) кулга алуыбыз һәм аның сөйләгәннәре буенча, **Балатон күле** янына берничә СС дивизиясе туплануын, шулай ук иң яңа **«Королевский тигр»** танклары турында мәгълүматлар алуыбыз турында да начар беләләр булыр. Болар Мәскәү өчен аеруча мөһим яңалыклар иде».*

*«Бөек Ватан сугышы тарихы» эпопеясының 5 нче томын язучылар да, Мурзинның Чехиядә ныклы элемтәләр булдыруын игътибарсыз калдырмаганнар. Аннан күренгәнчә, «әле 1944 елның ахырында ук, көнчыгыш Моравиягә Словакиядән авыр сугышлар белән **Ян Жижка** исемендәге партизаннар бригадасы үтеп керә. Бригада белән Чехословакиянең данлыклы улы, словак халкы герое Я.Ушьяк, ә ул һәлак булгач, Д.Б.Мурзин командалык итә. Коммунистларның идән асты оешмалары һәм җирле Каршылык хәрәкәте төркемнәре белән элемтә булдырганнан соң, бригада **Моравия-Силезия Бескидларында** сугыш хәрәкәтләре башлап җибәрә».*

Әмма мондагы чекрәеп торган кайбер төгәлсезлекләрне күрсәтеп китүдән тыелып калып булмый. Беренчедән, элекке хәрби әсир **Ян Ушьяк** бригаданың командиры исәпләнсә дә, бөтен эшне, нигездә, штаб башлыгы һәм комиссар вазифаларындагы Даян Мурзин башкара. Икенчедән, Мурзинның кат-кат кисәтүенә карамыйча, Ушьякның үҗәтлек күрсәтеп, провокатор **Франта Дворжакны** яклавы һәм аңа җил-яңгыр тидермәскә тырышуы партизаннарга бик кыйммәткә төшә: алманнар партизаннар бригадасы штабын тар-мар итә. Ноябрь аенда булган шул хәвефле көннәрдә Ян Ушьяк үзе дә һәлак була. Тагын бер хата: партизаннар бригадасы Моравия территориясенә 1944 елның ахырында түгел, ә бәлки берничә айга алдарак үтеп керә. Даян Мурзин истәлекләренә мөрәҗәгать итик:

*«Величко шунда ук киң күңелле һәм игелекле кешегә әйләнде. Хәтта, без Моравиягә үтеп керү турында көтелмәгән боерык алгач, бер взвод пулемётчыларын бирде. Ул боерык турындагы радиограмма 1944 елның 21 августында иртәнге сәгать алтыда килеп ирешә. Аңа Украина партизаннар хәрәкәте штабы башлыгы генерал **Строкач** һәм КПЧ ҮК вәкиле **Рудольф Сланский** кул куйганнар иде».*

Әлбәттә, аңа кадәр Чехия һәм Мора-

вия протекторатында бер генә партизан отрядының яисә бригадасының булмавын исәпкә алсак, әлеге бурычның никадәр җитди булуын аңлавы читен түгел. Мурзин үз партизаннары белән өч мәртәбә омтылыш ясаганнан һәм күп көрәштәшләрен югалтканнан соң гына, дошман мыжлап торган гитлерчылар биләмәләренә үтеп керә.

Генерал-лейтенант Тимофей Строкачның куалап торуына карамастан, бригада партизаннары ике мәртәбә чикнең теге ягында «ябышып» кала алмыйча, кире чигенергә мәҗбүр булалар. Моннан соң Ушьяк тәмам төшенкелеккә бирелә. Чөнки партизаннарны Чехия биләмәләренә үткәрмәү өчен гитлерчылар командованиесе аларга каршы зур көчләр туплап өлгерә. Ә Мурзин югалып калмый: чикне вак төркемнәргә бүленеп үтәргә, дигән ныклы карарга килә. Моның өчен әүвәл, дошманның игътибарын читкә юнәтү өчен, Моравиягә 50-60 кешедән торган төркем ташларга да тәкъдим итә. Мондый кыю план Ян Ушьякның да күңеленә хуш килә. Кабат Мурзинга әйләнеп кайтыйк:

«Ниһаять, 10 нчы сентябрьнең киче җитте... Без өченче мәртәбә Чехия һәм Моравия протектораты территориясенә аяк бастык. Таң атканчы, 20 чакрымлап араны йөгереп үттек. Һәм сирәк агачлыкка кереп постык.

Көн буена яңгыр астында яттык. Төнлә кабат протекторат эченә ташландык.

Икенче көнне иртән Княгинога барып җиттек. Мин Янга язу җибәрдем: «Штурм төркеме Моравия чиген үтте. Без — 1257 нче биеклектә». Бу Княгино биеклеге иде», — дип яза ул үзенең истәлекләрен бәян иткән китабында.

Күргәнебезчә, Ян Жижка исемендәге 1 нче Чехословакия партизаннар бригадасы ел ахырында түгел, ә сентябрьнең беренче яртысында ук Чехия территориясенә бәреп керә. Шуннан соң дошман өчен тынгысыз көннәр, мәшәкатьле тормыш башлана. Дөрес, кайбер авторларның, Мурзин партизаннарының Чехия һәм Моравия протекторатындагы ярты миллионнан артып киткән дошман гаскәрен «дер селкетеп торулары»н ассызыклаулары бераз арттырып җибәрү буларак кабул ителсә дә, чынбарлыкта, өч меңнән артык кешене берләштерүче партизаннар бригадасы зур көчкә әйләнә. 1962 елда запастагы генерал-майор **А.Н.Асмоловның** партизаннар бригадасы командиры Даян Мурзинга биргән «Хәрби характеристика»сында бу турыда бик төгәл әйтелә:

«...иптәш Мурзин <...> Чехословакия территориясендә 22 десантчыдан торган төркем тирәсенә өч меңнән артык партизанны берләштергән зур партизаннар бригадасы оештырды һәм аның белән 1944 елның октябреннән 1945 елның май аена кадәр шәхсән үзе командалык итте.

...1944 елның октябреннән 1945 елның май аена чаклы алман-фашист басып алучыларының бригада тарафыннан күргән иң җитди югалтулары — яр астына җибәрелгән 20 эшелон, Моравиянең Пржеров (Пршеров — Р.З.) каласы янында 18 самолёты белән кулга төшерелгән аэродром, юк ителгән 19 танк һәм 200 автомашина, шартлатылган 6 тимер юл күпере, сафтан чыгарылган 3 меңнән артык фашист солдаты һәм офицеры.

Мурзин командалык иткән бригада дошманга хәрби яктан зыян салу белән беррәттән, Моравия һәм Чехия территориясендә партизаннар хәрәкәтен көчәйтүгә дә зур этәргеч бирде».

***

Сугыш вакытында «Кара генерал» аты белән легендага әверелгән Даян Мурзин, Чехия территориясенә үтеп керердәй куәтле бригада оештырыр алдыннан, шактый тәҗрибә туплый, өч мәртәбә махсус партизаннар мәктәбендә күнегүләр үтә. Данлыклы разведчик

Шуннан соң партизаннар станы кырмыска оясына охшап кала. Элемтәчеләр, кайсы велосипедка атланып, кайсы җәяүләп, яшерен көрәш алып баручы патриотларны кисәтергә чыгып чаба...

һәм диверсантның тормышындагы кайбер маҗаралы хәлләр аны чыныктыра, меңнәрчә кешегә командалык итү дәрәҗәсенә ирешү мөмкинлегенә юл ача. Мисал итеп, 1943 елның җәендә 22 яшьлек Даян Мурзинның эре коммерсант **Армедис Стокоска** «әйләнеп», дошман тылында **Төркестан легионын** таркату яисә үзебезнең якка чыгару буенча эш алып барган мәлен китерик. Вакыйга **Донбасс** үзәгендәге **Макеевка** каласында төенләнә. Бик купшы киенеп йөрүче «грек эшмәкәре» идән асты көрәше алып баручы җирле патриотларны шиккә сала. Бер мәлне шулай, үзе белән элемтәдә торучы яшь кыз Надя, кичен аның янына кунак киләсен, шул сәбәпле өйдә булырга кирәклеген искәртә. Моннан соң, киресенчә, Надяның гестапо агенты булу ихтималын уйлап, инде Мурзин ике ут арасында кала. Мәгәр, башка чарасы булмаганлыктан — каладагы элемтәләрне һич тә югалтырга ярамый — үзе яшәгән фатирында кунакны көтеп алырга карар кыла. Даян ага үз китабында бу вакыйганы менә ничегрәк тасвирлый:

«Сәгать төнге унберләр тирәсендә ишекне шакыдылар, һәм мин аны ачарга дип, урынымнан кузгалдым. Барып ишекне ачтым һәм ирексездән артка чигенеп куйдым: минем каршыда маскарадка килгән шикелле, йөзен маска белән каплаган берәү басып тора иде.

— Сезме, Юра?

— Мин.

Әзмәвер мине иңбашы белән генә этәреп, өстәл янына үтте. Аннары маскасын салды һәм куеныннан пистолетын тартып чыгарды. Мин бу манзараны сүзсез генә күзәтеп тордым, әмма таныш булмаган бу кешенең пистлолетка тотынуы миңа ошап бетмәде. Кулымны кесәгә тыктым, әмма теге пистолетын өстәлгә — минем борын төбенә ташлап, сораштыра башлады:

*— Мин — полковник **Шведов**. Үзәк белән элемтәне минем аша тотарсыз. Сезнең нинди үтенечләрегез бар?*

— Радио аша кемгә хәбәр иттегез?

*— Полковник **Метеловка**. Җитәме?*

— Җитә, дип әйтергә ярый.

— Алай булгач, үзеңнең үтенечләреңне чыгарып сал!

— Миннән шикләнүләрен әйтегез!

— Шул гынамы?

— Әйе!

— Уңышлар сиңа. Әмма сак бул!

— Яхшы, — дидем мин. — Тырышырмын.

— Ике көннән мин сиңа Үзәкнең боерыгын җиткерермен, шуңа кадәр түзәргә тырыш. Гомумән, вазгыятькә карап эш йөрт, син бит — разведчик!

Шведов кабат маскасын киде, пистолетын куенына яшерде һәм караңгылыкка кереп югалды».

1943 ел тәмамланып килгәндә Мурзин кабат парта артына утыра. Бу юлы ул партизаннар хәрәкәте штабының ***Бердянск-Осипенко*** каласында урнашкан махсус мәктәбендә Молдавиягә партизаннар отряды оештырырга җибәрү алдыннан хәзерлек үтә, Мәскәүдә алган белемнәрен камилләштерә. Бирегә башкаланың данлыклы профессорлары һәм танылган партизан хәрәкәте җитәкчеләре дә еш килә. Тәҗрибәле белгечләр дошман тылында көндез һәм төнлә хәрәкәт итү серләренә өйрәтүдән тыш, молдаван һәм румын телләре, ул илләрнең икътисады, гореф-гадәтләре һәм мәдәнияте турында җентекләп сабак бирәләр, әле хәтта болар белән генә чикләнеп калмыйча, маршал ***Антонескуның*** амбицияләренә кадәр төшендерәләр. Әлбәттә инде, диверсантларга дошман тылында үзләре хәрәкәт итәргә тиешле территориядәге сала-кала, санторий-курорт атамаларын һәм румын дивизияләренең тәртип саннарын да, төнлә уятып сорасалар да онытмаслык итеп хәтерләренә сеңдерергә туры килә. Ниһаять, Мурзиннар төркеме утырган **«Дуглас»** самолёты аэродромнан күтәрелә һәм Молдавия тарафына юл тота. Әмма тиешле урынга җитәрҗитмәс, бер моторны дошман зениткасы снаряды сафтан чыгаруы сәбәпле, очучы аларны Украина белән Молдавия чигендәге **Кодым** урманына ташлап калдырырга мәҗбүр була.

Тәҗрибәле диверсант-разведчик Даян Мурзин тиз арада 350 кешедән торган отряд туплый, алдан килешенү буенча аңа **В.М.Молотов** исемен бирәләр һәм шуннан соң төбәктәге алман, румын гаскәрләре тынычлык төшенчәсен тәмам оныта. Бер генә эпизод. Мурзин отрядына мең ярым хуҗалыгы булган **Будей** авылындагы ике алман ротасыннан, бер румын батальоныннан, ике йөзләп полицайдан торган һәм өч урта танкы, алты тубы булган зур карательләр төркеме һөҗүм итә. Тиңсез сугышта Мурзин партизаннары өстен чыга: карательләрнең 200дән артык хәрбие юк ителә, ике танк яндырыла, ә 6 туптан торган батарея трофейга әйләнә. Әмма Мурзинның әлеге уңышлары турында радист җибәргән хәбәр Украина партизаннар хәрәкәте Баш штабындагыларны шиккә сала. Мурзин, билгеле, ул турыда белми: аның партизаннары әлеге алыштан соң да, 1944 елның апрель азакларына кадәр, ягъни Кызыл армия масштаблы операция башлаганчыга тиклем, Украина һәм Молдавия чигендә дошман гаскәрләренә каршы һөҗүмнәр оештырып тора. Ниһаять, көткән көн туа: отряд сугышчылары, нәкъ менә әлеге Будей авылы янында, шул елның май аеннан 2 нче Украина фронты командующие итеп билгеләнгән армия генералы Родион Малиновский гаскәрләре белән очраша. Күпләр Кызыл Армия частьларына кушыла, ә отряд командирын фронт штабында көтәләр. Кабат Мурзинның истәлекләренә күз салыйк:

*«Мине шунда ук **Николевск** каласына, фронтның Хәрби Советы әгъзасы полковник **Асмолов** янына чакыртып алдылар.*

Анда җентекле хисап язарга куштылар. Билгеле, моңа аптырап калмадым, чөнки миннән һәрвакыт башкарган эшләр турында дәлилләп бәян итүемне сорыйлар иде. Бу мине тикшерү өчен генә түгел, ә бәлки минем белән элемтәдә булган кешеләрнең гамәлләрен ачыклау өчен дә эшләнә иде.

Хисап белән танышып чыкканнан соң, Асмолов мине үз янына чакыртты һәм турыдан ярып салды:

— Син, Мурзин, үпкәләмә, ләкин без сине тикшерергә тиешбез. Кабат Будейга җыен. Синең белән майор ***Артюхов*** *һәм* ***Морозов*** *барачак.*

— Тыңлыйм, иптәш полковник. Ләкин минем бер үтенечем бар.

— Нинди үтенеч?

— Майор Будейга тикшерү өчен килүләрен әйтмәсеннәр.

— Ә нәрсә була?

— Андагылар минем өчен үпкәләргә мөмкиннәр.

— Ярар, — дип көлеп җибәрде Асмолов, — комиссияне «маскировать» итәрбез».

Кунакларны Будей авылы советы янында җыелган йөзләрчә кеше каршы ала. Мурзин халык төркемен күргәч, баштагы мәлне, мөгаен, ниндидер җыен үтә торгандыр, дип уйлап куя. Әмма **«Виллис»** автомобиле күренүгә, кешеләр кул чабарга һәм кулларындагы чәчәк бәйләмнәрен болгарга керешәләр, шатлыклы тавышлар тагы да көчәя төшә. Мурзин аптырап, тирә-якка карана башлый. Шулчакны Артюхов вазгыятькә ачыклык кертүне кирәк таба: «Аптырама, сине шулай каршылыйлар. Райкомнан искәртеп өлгергәннәр, күрәсең», — ди.

«Виллис» туктау белән, аларны авыл кешеләре чолгап ала. Таныш, шатлыклы йөзләрне күргәч кенә, Мурзин аларның үзен каршыларга җыелуларына төшенә һәм «Исәнмесез, иптәшләр!» дип әйтергә тели, әмма тамагына төер килеп утыра. Ул соң дәрәҗәдә шомланып, үзенең сүз әйтер хәлдә түгеллегенә төшенә. Ярый әле, Артюхов башын читкә борып һәм «Виллис» бортын бармаклары белән төя башлый. Бу аны табигый халәтенә кайтара. Командирларын яңадан күрү шатлыгыннан, **Курбала** белән **Мукан** Мурзинга тантаналы рәвештә бик матур фаэтон бүләк итәләр. Әлбәттә, бу шатлыклы очрашу мизгелләре генә, фронт штабыннан җибәрелгән офицерларга ашыгыч нәтиҗәләр ясау өчен җирлек бирми. Алар бөтен нәрсәне җентекләп һәм бөртекләп тикшерә. Тик кылган батырлыкны ничек яшерәсең, ди. Иртә белән урманга баралар. Ә анда беренче бәрелештән соң алманнар калдырган алты туп үз урынында... Шартлатылган танклар да, махсус комиссия килүгә куйган кебек тора...

Комиссия Мурзинның хисабында хилафлык тапмый. Берничә көн дигәндә, Артюхов белән Морозов шундый нәтиҗәгә килә. Шунысы әһәмиятле: җирле патриотлар үзләренә нинди «корреспондентлар» килүен бик тиз төшенә һәм, 1944 елның кыш айларында Мурзин партизаннары алып барган сугыш хәрәкәтләре турында бәйнә-бәйнә язылган характеристика әзерли. Озатканда, Будей бистәсе советы рәисе Мукан, идән асты оешмасы җитәкчесе Курбала һәм шул оешма әгъзалары **Гандзя** белән **Джевецкий** кул куйган документны, көрәштәшләре үз командирларының кулына тапшыра.

Чехия һәм Моравия территориясендә көрәш алып барганда бригаданың бер отряды белән командалык итүче хәрби очучы өлкән лейтенант **Александр Долинов** белән булган вакыйга да шактый ук гыйбрәтле. Дворжакның хыянәтеннән соң күпмедер вакытлар узгач, Мурзин бригадасында «Курск сандугачы» кушаматы алган **Николай Нечипуренко** атлы власовчы пәйда була. Бригада штабы туздырылгач һәм бригада командиры яраланып урманда үлем белән көрәшеп ятканда килеп кушыла партизаннарга бөдрә чәчле гитарада оста уйнаучы Нечипуренко. Болай да шикчел Мурзин, бик сәер шартларда партизаннар ягына чыккан власовчыны баштан ук өнәми, аңа ышанып бетми. Әле җитмәсә, бераз гына алдарак, генерал Строкач Моравиягә абвер тарафыннан власовчылардан торган берничә төркем җибәрелүе турында аны кисәтеп тә куйган була. Провокаторлар озак көттерми, ул яралы вакытта Траяктагы ресторанга 25ләп ир-ат килеп керә һәм үзләренең партизаннар белән очрашырга теләүләрен белдерә.

Бригада белән элемтә тотучы ресторан хуҗасы **Карел Пучик** шикле кешеләр турында «урманга» хәбәр юллый. Бер атнадан партизаннар очрашу сылтавы белән ресторанга килә һәм абверга эшләүче власовчыларны кырып сала. Бары тик төркем җитәкчесе **Пинкус** кына качып котыла, Нечипуренко исә атыш барышында өстәлгә сикереп менә һәм кычкырып җибәрә:

— Мин аларны беләм — алар сатлыкҗаннар, гестапо агентлары!

Мурзин бу вакыйга турында, терелеп аякка баскач кына, бригада комиссары Степановтан белә.

Нечипуренко исә кыска гына вакыт эчендә партизаннар арасында тәмам үз кешегә әйләнеп беткән була, әле хәтта берничә хәрби операциядә дә катнашырга өлгерә. Аерата аны Долинов үз итә.

Берчакны шулай, Даян Мурзин янына Александр Долинов килеп керә һәм үзенең идеясен ачып сала:

— Даян Баянович, Курск сандугачы, ягъни Николай, миңа ***Лисковицыда*** *власовчылар батальоны урнашуын һәм аларның партизаннар ягына чыгарга теләүләре турында җиткерде.*

— Шуннан, — ди комбриг кырыс кына. — Моны ничегрәк тормышка ашырып булачак соң?

— Бик гади рәвештә, — дип җавап бирә Долинов. — Николай комбатны үзенең якын дусты булуын һәм аның күп тапкырлар партизаннар ягына чыгу юлларын эзләвен ирештерде.

Гомумән алганда, идея командирга ошый. Әмма булачак операциянең төп герое — Николай шиккә сала. Аерата власовчы Нечипуренконың элекке гестапо агенты булуы тынгылык бирми. Моның өстенә ул әле — Николай барырга кодалаган батальон хәрбиләренең күп каратель операцияләрендә катнашып кына калмыйча, мәрхәмәтсезлекләре белән аерылып торуларыннан да хәбәрдар. Ресторандагы вакыйганың импровизацияле тамашага корылган булу ихтималын да күз уңыннан ычкындырмый. Аннан килеп, йөзләрчә кеше язмышы өчен җаваплы булган командир, власовчыга артык ышанып ташлап, баштан ук бригадада хата җибәрүләрен дә бик яхшы чамалый. Чөнки, даими күзәтү астында булуына карамастан, Нечипуренко бу вакытка инде бригада штабының кайда урнашуын, партизаннарның элемтәчеләре яшәгән йортларны һәм кайбер агентларның фамилияләрен ачыклап өлгергән булырга да мөмкин ич. Мурзин боларның барысын да Долиновка ачып сала. Әмма тегенең үз туксаны туксан: үҗәтләнеп үзенекен тукыпмы тукый. Бик үтенеп сорагач һәм үзенең алман әсирлегендә булмавын дәлил итеп китергәч, Долиновны һәм аның адъютанты Вася «Маршал»ны Нечипуренконы күз уңыннан ычкындырмау шарты белән, Лисковицыга җибәререгә карар кылалар.

Тик иртәсен Траякка илтүче сукмактан икәү генә — Саша Долинов һәм аның алыштыргысыз адъютанты Вася «Маршал» гына кайтып керәләр. Сашаның йөзен танырлык түгел, кайгыдан кара янган. Ул Мурзин янына керә, каешын салып пистолетын өстәлгә куя һәм... елап җибәрә.

— Ычкындырдыгызмы?

— Әйе!

Степанов котырынып китә:

— Син нәрсә эшләгәнеңне беләсеңме?

— Мин үлемгә әзер, — ди төшенкелеккә бирелгән Саша Долинов.

Шулвакыт аның адъютанты түзми, акырып җибәрә:

— Мин гаепле! Мин, мин, мин! Ул кабахәтне мин ычкындырдым.

Мурзин дәшми. Чөнки ул, әгәр Николай кача калса, үзен атачаклары турында Долиновны кисәткән була. Димәк, бу эшне ул үзе башкарырга тиеш. Командир тешен кысып, Долиновның тагын нәрсәдер әйтүен көтә, аның сөйләгәннәрендә, аз гына булса да, гаебен йомшартырдай кечкенә берәр дәлил кисәге булуына өметләнә. Үкенечкә каршы, Долинов сөйләгәннәрдә андый дәлил булмый.

Аны тыңлап бетергәч, соңгы сүзне бригада комиссары әйтә:

— Бар да ачык, — ди Степанов катгый итеп. — Авыз ачып калганнар. Настенко, монда булганнарның берсен дә калдырма — тизрәк китсеннәр!!! Безгә дә, Юра, кузгалырга вакыт.

Шуннан соң партизаннар станы кырмыска оясына охшап кала. Элемтәчеләр, кайсы велосипедка атланып, кайсы җәяүләп, яшерен көрәш алып баручы патриотларны кисәтергә чыгып чаба... Мурзин исә Долиновны урамга чыгарга чакыра. Ул да инде тынычланып калган, үз-үзен кулга алып өлгергән. Нык басып ишегалдына чыга һәм сарай стенасы янына барып баса да:

— Монда әйбәтрәк булыр, — ди.

Мурзин Бельгиядә ясалган маузерын күтәргәч, Саша кабат телгә килә:

— Бәхил булыгыз, иптәшләр!

«Маршал» күз яшьләрен яшермичә елый. Мурзинның да авызы кибә, тамак төбенә төер тыгыла. Шулчакны Степанов:

— Тизрәк, — дип кычкыра һәм башын читкә бора.

Командир атып җибәрә...

Яңа урынга урнашканнан соң, Мурзинның боерыгы дөнья күрә:

«Өлкән лейтенант Александр Долинов бригада командованиесенең хәрби бурычын үтәгәндә, хәрби боерыкны бозды.

Бөтен шәхси составка мәгълүм булганча, аның гамәле бик авыр нәтиҗәләргә китерде. Шулардан чыгып, Долинов минем тарафтан атып үтерелде».

Даян аганың сөйләвенә караганда, шул вакыйгадан соң «Курск сандугачы»ның да көннәре санаулы кала. Дөрес, ул әле күпмедер вакыт партизаннарның очрашу урыннарына (явка) карательләрне алып бара. Аның сатуы нәтиҗәсендә фашистлар берничә патриотны асып үтерә, ә качып өлгергән элемтәчеләрнең өйләре янып күккә оча. Әмма сатлыкҗанны яңа хуҗалары да бик үк өнәп бетермәгән, күрәсең: бер уңышсыз операциядән соң, жандарм офицеры кушуы буенча, аны тотып утка аталар.

Ахыры киләсе санда

ДӘҺШӘТЛЕ ЕЛЛАР ХАТЛАРЫ

Бөек Ватан сугышы чорында Шәйхи Маннур, 1942 елның февралендә, ГлаПУРККА күрсәтмәсе буенча, Калинин фронтына – 61 нче Армиянең «Боевой призыв» дигән газетасына эшләргә китә. Шул елның 23 декабреннән 1943 елның июненә кадәр «Алга, дошман өстенә!» газетасында хәрби корреспондент булып эшли, аннары аны икенче урынга күчерәләр.
Соңрак ул Өченче Белоруссия фронтына караган 11 нче гвардия армиясенең 83 нче гвардия дивизиясендә чыккан «За счастье Родины» исемле газетада хезмәт итә. Сугышчан хезмәтләре өчен Шәйхи Маннур Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр белән бүләкләнә.

ЯЗУЧЫЛАРГА

Кадерле Разин[1], Шамов[2], Хәйри[3] һәм А.Гомәр[4] иптәшләр!

Дүртегездән дә бер көннедер хатыгызны алдым. Иптәш итеп, искә төшереп язуыгыз өчен бик рәхмәт. Ләкин мине гафу итегез, дүрт хат урынына берне генә язам. Чөнки бер дә вакыт җиткереп булмый. Фронт (армия) газетасы кешесен күз алдыгызга китерегез, мин кечкенә генә литсотрудник булып эшлим. Редакциягә кайтып, 2-3 көн материалларыңны язып утырасың да, тагын дивизияләргә, полкларга чыгып китәсең. Җәяүле «самолётлар» белән ерак юлларны үтеп, урманнар, сулар кичеп, рота, взвод, отделениеләргә кадәр барып җитәсең, агач төбенә генә посып, фрицларның блиндажын күзәтәсең. Кайчакларда башың очында «чебеннәр» бызылдап, кыйпылчыклар сызгырып та куя. Шундый шартларда кешеләр (боецлар) белән сөйләшеп материал туплыйсың да, тагын юлга чыгасың. Менә шулай көннәр үтә һәм тиз үтә. Эш кызыклы һәм тәвәккәллекле. Талчыгып ялга утырган вакытта табигать матурлыгын күзәтәсең, кошларны тыңлыйсың, чәчәкләр иснисең, шигырьнең берәр строфасын теркәп куясың, шундый чакларда баш очында шрапнель ярылса, самолётлар шаулый башласа, кузгалып, сыздыра бирәсең.

Күп кызыклы кешеләр күрәм, темалар күп, очерк, проза, поэма белән язасы килә. Ләкин хәзергә — «киләчәктә» дисең дә, полевой сумкаңа салып куясың.

Менә өч ай эчендә аннан-моннан 200 юл шигырь яздым. Аларны бүген сезгә җибәрәм, үзегез хөкем итеп һәм басып чыгарырсыз, дип уйлыйм.

Иптәш Разин, элегрәк безнең газетада мөмкинлек киңрәк иде, мин дә очерк, зарисовкалар язгалый идем, хәзер газета кечерәйде, мөмкинлек тарайды. Миннән башка ике язучы бар, алар — штаттагы язучылар. Мин һәм тагын бер Белоруссиядән яһүд язучысы — әдәби хезмәткәрләр. Сиңа әйтәсе сүзем шул: журналны алып укыштырдым. Г.Галиевнең[5] хикәясе бик җылы язылган, әйбәт тойгылы хикәя... Исәнбәтнең[6] «Гөлчирә»се — аның капма-каршысы. Аны укып чыккач, Казанда булсам, бик әче итеп көлгән булыр идем. Журнал моны басып, бик хата эшләгән. Күрәсең,

[1] Разин — Гомәр Бәшировның әдәби кушаматы.
[2] Шамов — Афзал Шамов.
[3] Хәйри — Хәсән Хәйри.
[4] А.Гомәр — Абдулла Гомәр.
[5] Г.Галиев — Гариф Галиев.
[6] Нәкый Исәнбәт.
[7] Мильтон Джон (1608-1674) — инглиз шагыйре.
[8] Данте Алигьери (1265-1321) — итальян шагыйре.

безгә — шагыйрьләргә гыйбрәт өчен, яки үрнәк өчен басылгандыр инде ул. Әлбәттә, ул әсәр рус матбугатына чыкса, Мильтоннар[7], Дантелар[8] һ.б.лар, һ.б.лар «һәлак» булып, тик Исәнбәт кенә калачак. Тагын юкмы икән аның чүплек башында шундый бер әчәге буе сафсата?

Бу юлларны Исәнбәткә антипатиям булганлыктан түгел, бәлки «әсәре» поэзияне мыскыл итү дәрәҗәсендә начар, бездарный, өйрәнчек — сукыр эпигонлык[9] белән язылганга күрә, гомумән, аның хәзерге Ватан сугышка сорый торган мотивлар белән һәм безнең 20 елдан артык яшәп килгән поэзия белән ике тиенлек тә уртаклыгы булганга күрә язам. Әгәр ул чын художник булса, мондый чүп-чарны редакциягә күтәреп килергә һәм бастырырга үзе үк оялырга тиеш иде.

Иптәш Разин, син бит акыллы егет идең, ничек булды соң бу? Минем фикеремә башка шагыйрьләр дә кушылыр, дип уйлыйм (Исәнбәтнең табындашы булмаганнар). Бер яшь шагыйрьнең чын күңел белән язган шигыре (мәсәлән, шул ук журналда Байкал турындагы шигырь), валлаһи, аңардан 100 мәртәбә яхшы! Ялгыша күрмәгез — анда язылганнар белән хәзерге сугыш арасында һичбер алышбиреш юк.

Ярый, хуш. Син рәсем сорагансың, каршы түгел, ләкин фотограф әзерләп өлгермәде. Икенче хатымда минем шыксыз кыяфәтемә карап бер көлерсез.

Иптәш Шамов! Иптәшлек җылылыгы белән язылган хатыңны алдым, бик рәхмәт. Ләкин шулай да сиңа үпкәм бар: минем шигырьләрне ничек ботарлаганыгызны нишләп язмыйсың? Әлбәттә, минем шигырьләр Исәнбәтнең «шедевры» белән чагыштырырлык ук яхшы булмаса да, басылмаслык түгел иде борынгы заманда. Ул шигырьләрне бик күп кешеләр яратып укыйлар иде һәм мин аларны монда да очраткалыйм. Алай бер сызу белән генә юкка чыгару, бигрәк тә синең безнең турындагы фикерләрең күбесенчә үзеңә генә хас булуын искә алганда, ярап бетми торгандыр. «Үзе юкның — күзе юк», мәкале белән эш итәргә ярамый.

Исән булсак, без дә бер кайтырбыз. Ә мин үлгәч — анда сезнең эш — теләсә нишләтегез. Гомумән, әгәр мөмкин булса, поэзиягә кул тыкмаска киңәш бирер идем мин. Ул өлкәнең үз кешеләре бар бит. Ярый, бәхәс күтәреп файда чыкмас, кәгазь генә әрәм булыр.

Хәйри иптәш! Хатың өчен рәхмәт. Менә бу яңа шигырьләрне алып өстәсәң, яхшы булыр иде. Үзем булмагач, минем җыентык адәм көлкесе булып чыга икән инде. Нишләп сез, иптәшләр, шундый вакытта, рәсмилектән әз генә булса да читкә китеп, җанга якын бер иптәшлек күрсәтмисез?! Син бит минем иҗатны беләсең. Нәрсәләр алып өстәргә кирәклекне бик тиз хәл кыла алыр идең. Ни өчен, мәсәлән, «Безнең авыл егете»ннән ана җырын өстәмәскә иде?

А.Гомәр иптәш! Синең хатың минем өчен аеруча кадерле булды. Чөнки син бөтен хәбәрләрне язгансың, мин аларның күбесен белми идем. Әгәр дә мөмкин булса, миңа С.Хәкимнең адресын җибәр. Киләчәктә дә шулай бәйнә-бәйнә язып торсаң, шәп булыр иде. Ләкин ачыграк яз, танып булмый. Баяннар[10], Җәлилләр[11] нинди эштә?

Ярмине[12] күрсәң, әйт: мин өйгә язганда хат саен сәлам куям аңар, ә ул ахры безгә кереп тә карамый, хат та язмый. Мин ул Алпамшаның[13] койрыгын кисәрмен әле кайткач.

Безнең семьялар ничек тора, аларны да теге ябык кибетләргә беркетмәдегезме? Бер кереп хәлләрен бел әле, правление членнары «тартынсалар да», син тартынма, дус, бик аптырамыйлармы икән? Тагын әллә нәрсәләр язасым бар

[9] Эпигонлык — бик соңга калган.
[10] Нур Баян.
[11] Муса Җәлил.
[12] Хәмит Ярми.
[13] Хәмит Ярминең кушаматы.

күк иде, онытылды инде һәм ардым, бик күп яздым. Ярый, хушыгыз.

Барыгыздан да хат көтеп, барыгызга да кайнар сәлам белән —

Шиап солдат. /имза/.

13.У1.42.

ТР МА. Р-6529 фонд. 1 тасвирлама. 115 эш. 1, 1 әйл., 2, 2 әйл. 3 бит. Төп нөсхә.

ХӘМИТ ЯРМИГӘ

Ярми дустым!

Сиңа исән-сау килеп эшли башлаганлыгымны белдерәм. Абдулга сәламеңне тапшырдым. Һәр икебездән дә кайнар сәлам. Башка иптәшләр дә сәлам әйтәләр.

Үзем озакламый командировкага чыгып китәрмен ахры, редактор шулай ди.

Үзең белән сөйләшкәнчә, ип. Мексинага дигән хатны сиңа җибәрәм, үз вакытында аңа тапшырырсың, дип ышанам.

Аннан соң, дускай, сиңа һәм Разинга үтенеч бар. Мин теге фронтта чакта передовойда булуым сәбәпле, өч айлык стаж белән кандидатлыкка үткән идем, ә монда килгәч, ул берьеллыкка әйләнде — П эшелон бит. Шуның өчен, элекке урынымнан моннан биш-алты ай элек соратып алган рекомендацияләрем хәзер искереп, ярамаска әйләнде.

Димәк, кыска гына әйткәндә, синнән һәм Разиннан — үземнең яраткан иптәшләремнән — членлыкка үтәргә рекомендация сорыйсым килә. Аяк астына салмассыз бит? Әгәр шуны тиз генә оештырып җибәрә алсагыз, бик шәп булыр иде. Июльдә елым тула. Үтенечем шушы. Разинга да җиткерче, дустым, һәм бергәләп җибәрегез.

Сагынып, сәлам белән:

Маннур (Шыяп солдат).

28.У1.43.

ГОМӘР БӘШИРОВКА

8.ХП.44.

Гомәр туган!

Бүген, бер дә көтмәгәндә, синең хатыңны алып бик шатландым. Тик аның бик кыска язылуына һәм әдәби тормышлар, яңа әсәрләр турында бернәрсә дә язылмавына гына канәгатьләнми калдым. Мин бит әдәбияттан бик ерак һәм мәхрүм кеше. Син җәя эчендә генә биргән сорауга минем җавап бирерлек хәлем юк. Чөнки мин шушы өч ел эчендә, күп булса, 5-6 номер журнал күргәнмендер. Башкача татар әдәби дөньясы миңа караңгы. Ә соңгы журналларны мин, ялгышмасам, үткән декабрь яки январьда күргән идем шикелле.

Минем хәлгә килгәндә, әллә ни зур үзгәрешләр булганы юк. Гыймадиев белән Шамов (соңгысына карата «...күкрәгеңдә җылы бирсәң, муеныңа сарылыр», дигән борынгы әкият искә төшә) «беркөнлек хәлифә»ләр көче ярдәмендә мине редакциядән кудылар. Мин яңадан һәм бик күптән инде, рус газетасында (дивизия) эшләп киләм. Ә башка яклары белән мин һаман да иске Маннур, тик дус-дошманны тагын да яхшырак таныйрга өйрәндем шикелле.

Синең иптәшләрчә хәлемне белергә теләвең өчен рәхмәт. Минем ничек яшәвем белән кызыксынуың да бик әйбәт эш. Чөнки син миңа рекомендация бирдең, ә мин аның белән партия сафына член булып үттем һәм, ул исемгә моңарчы тап төшерми, югары саклап йөртәм. Әлегә исән-сау, картларча селкенеп йөри торгач, Көнчыгыш Пруссиягә дә килеп җиттем инде. Исән булсак, Берлин дигәнен дә күрербез әле, бәлки. Мин бер яктан гына бик бәхетсез: татар газетасында эшли алмыйм һәм яза, бастыра алмыйм. Менә бу газетага килгәннән бирле бер юл әйбер яза алганым юк, темалар туалар һәм үләләр. Чөнки мин — редакциянең эш аты. Җәяүләп полклар буйлап йөрүдән, газетада ягтыртыла торган барлык темаларга

хәбәрләр һәм мәкаләләр язудан бушана алмыйм. Мин хәзер язучы булудан бигрәк, менә дигән өченче сортлы рус «журналисты» инде.

Сугыштан соң да шул тирәдән ипи эзләргә кирәк булыр ахры, дип уйлыйм. Мин хәзер солдат мунчасы турында һәм, үзем берни дә белмәсәм дә, сугыш кырында ничек хәрәкәт итәргә кирәклек турында бер үк дәрәҗәдә уңышлы тактик мәкаләләр яза алам. Менә шулай булгач, синең миннән җыентыкка әсәр соравыңа бер дә канәгатьләнерлек җавап бирә алмыйм. Кулга тотарлык бернәрсәм дә юк.

Сиңа атап әйтелә торган үпкәм булмаса да, туган, андагы җитәкче иптәшләргә үпкәм күп. Мин үземне язучы, дип ялгыш уйлап йөргәнмен икән. Нәтиҗәдә, минем берәүгә дә, бер тиенгә дә кирәгем юклыгы ачык күренде. Әдәбият өчен мин ноль булып калдым. Мин дә «бронь» астында җил-яңгырдан сакланып ята алыр идем бит. Ләкин мин үз адымымнан башка мәгънә эзләгән идем. Ул — сугышның үзен күреп, аның батырлары турында чын һәм яхшы әсәрләр тудырырга теләүдән гыйбарәт иде. Чынбарлыкта исә, киресе килеп чыкты. Мин әдәбиятта «онытылганнар» исемлегенә барып төштем. Әдәбиятка хезмәт итү урынына, ни тәнгә, ни җанга җылысы булмаган эшләрне башкаручыга әверелдем. Өч ел буе көткән нәрсә шул булды. Фронтта хәзер рус язучыларының йөздән бере генә. Алар да Мәскәү белән ике араны күбрәк таптыйлар һәм фронт газеталарында үз урыннарында эшләп, әсәр тудыралар, бастыралар. Ә без ел ярым-ике елга бер мәртәбә семьяларны күрергә дә аптырап йөрибез. Бу бит фәкать татар язучысы турында кайгыртучы булмаганлыктан гына килә. Мин өч елга бер табаклы җыентык чыгара алдым, аның да яртысы Казанда язылган әйберләр бит.

Хәзер минем шул күләмдә тагын бер җыентыгым бар, ул инде 9 айдан бирле икмәк капчыгымда йөри. Ә шуны Казанга алып кайтып тапшыру турында хыял гына итә алам мин. Минем семья хәзер Казанга кайткан. Аларны үземнең квартирага кертмиләр икән, алар күрше бер бүлмәдә яшәп киләләр икән. Ул нинди почмак, алар суыктамы, җылыдамы, ачмы — тукмы, ялангачмы — мин белмим. Бер иптәшнең дә миңа ул турыда хәбәр иткәне юк. Менә «Маннур иптәш»нең хәле шулай.

Сиңа һәм Союзга хат язмауның бер төрле яшерен сере дә юк. Син радиода чакта язышкалый идек. Син аннан китүкәч, Акком астының йорт һәм квартира санын белмәүдән мин өзелеп калдым. Союзга Кашшаф заманында хат язсам да, җавап булмады. Мин дә шуннан соң язмадым, чөнки Имамый, Таҗи абзый заманнарында да язгалап карадым, барыбер, алардан да җавап алмадым. Шуннан соң инде «иптәшләр минем белән маташырга теләмиләр» икән, дигән нәтиҗәгә килү үзеннән-үзе билгеле.

Бу хат эт эчәгесе шикелле озын булды. Күрәсең, эчтә чүп-чар күп җыелгандыр ахры. Ачуланма, укы да ертып ташла, мин сине иптәш иткәнгә генә яздым. Бу сүзләр белән генә хәлне үзгәртеп булмый бит. Бер генә теләгем бар: тизрәк кайтсам иде дә, эшкә утырсам иде. 15 нче январьда миңа 40 яшь тула. Күп яшәлгән, әз эшләнелгән; калган әз гомер эчендә күбрәк эшләп каласы иде!

Ярый, шушында тәмамлыйк. Хәмитне күрсәң, сагынычлы сәлам әйт.

Дусларча кулыңны кысып, кайнар сәламнәр сөйләп,

бывший Шыяп солдат.

Хуш.

Полевая почта 06468-С. Маннур.

/имза/.

Г.Бәширов кулы белән язылган: 29/1 алдым.

ТР МА. Р-6529 фонд. 1 тасвирлама. 115 эш. 6, 6 әйл., 7, 7 әйл., 8 бит. Төп нөсхә.

Гомәр дус!

Мин синең бер хатыңа җавап биргәнче, синең икенче хатың килеп җитте һәм вәйран итте. Бу турыда нәрсә дип кенә әйтим соң, болай да яралы йөрәк тагын да кискәләнде. Юк, моңа сугыш кына гаепле түгел. Без кешеләребезне саклый белмибез. Муса, Рахман, Шамиль Гәрәй, Алиш, Дәүли, Мифтах, Фатих... Безнең кечкенә семья өчен бу искиткеч зур югалту! Боларны тиз генә үстереп булмаячак. Әдәби кадрларны чәчеп бетердек.

Эч бик поша, хәерле булсын. Үзбәк, казах, азәрбәйҗан һәм башкаларда бу эш болай түгел. Теләсәң ни әйт, бездә язучы итекче дәрәҗәсендәрәк йөри, дисем килә минем. Фатихның талантына, фронттан йөрәк каны белән язган матур шигырьләренә барыбыз да сокланып йөрдек, әгәр ялгышмасам, ул, яраланып, ике мәртәбә Казанга кайтты. Ләкин шунда берәү дә аны алып калыша алмады...

Синең үтенечне мин бик тырышып үтәргә ризамын, аның каберен бик эзләп табасым килә. Ләкин аның полевая почтасы белән генә берни дә эшләп булмый. Чөнки бу тирәдә бик күп халык сугышты, һәм хәзер аларның күбрәк өлеше моннан китеп барды инде. Шулай да мин берничә төрле чара күреп карарга уйлыйм, ягъни тотынам.

1. Шул адрес белән хат язып, аның кулъязмаларын саклауны һәм аның нинди часть икәнен белдереп язуны сорыйм, бәлки бу юл белән мин кайбер нәтиҗәләргә тизрәк ирешермен.

2. Үзебезнең тирәдәге махсус оешмалар аша бу адресларның кайсы частьнеке икәнен белергә тырышам. Әгәр мөмкинлек чигендә булса, шунда ук юлга чыгам. Шулай итеп, бәлки, бер очын таба алмаммы...

Гомәр, Фатих күпме күрде! Дүрт ел йөреп тә кайтты[14]. Гаепсез булып табылды. Шунда ук сугышка китте. Анда чын патриотлыгын кайнар каны һәм кайнар, талантлы шигырьләре белән күрсәтте. Ул, һичшиксез, зур шагыйрь, талантлы егет, канаты, күңеле сынарлык бик күпләрне күрсә дә, язмышның авырлыгына бирешмәгән лачын иде. Союз аның исемен мәңгеләштерүдә нәрсәләр эшләргә җыена? Онытасы түгел иде!

Фикерләрем бик таркау. Мин хәзер бер җылы сүз дә әйтә алмыйм. Тик аның семьясына һәм әдәби коллективка тирән кайгымны белдерүемне тапшыруыңны гына үтенә алам. Аның байтак кына балалары бар иде бугай, ташламагыз!

Аның каберенә делегация җибәрү һәм Казанга мәетен алып кайту, дәүләт исәбеннән күмү, семьясына күзгә күренерлек рәвештә вакытлы ярдәм оештырып булмыймы?

Монда килү мәсьәләсен уңайлы чишеп булыр бәлки, чөнки монда сугыш юк инде хәзер.

Сиңа моңарчы хат язмавым, теге язуыгызның берәр хәлен ишетмәммe, дип тору иде. Ләкин бу көнгә кадәр андый язуның килү-килмәве, димәк, нәтиҗәсе турында да ләм-мим ишеткәнем юк. Ахры килмәгәндер, килсә — шулай сеңгәндер инде.

Ярый, хуш. Тиздән сугыш бетә, дип уйлыйм. Болай да кайтырбыз инде.

Кайнар сәлам. /имза/.

Мирсәй һәм Ярмигә дә әйт.

1 май.

Котлыйм!

Г.Бәширов кулы белән язылган: 27/V-45.

ТР МА. Р-6529 фонд. 1 тасвирлама. 115 эш. 11, 11 әйл. бит. Төп нөсхә.

Хатларны һәм искәрмәләрне басмага ***Әлфия Шамова*** *әзерләде.*

[14] Фатих Кәрим 1937 елның маеннан 1941 елның декабренә кадәр, репрессия шаукымына эләгеп, «халык дошманы» буларак, төрмәдә утыра.

«ГӨЛСЕМ ӨЙГӘ КАЙТАДЫР»

Равил Сәйфетдинов,
төбәкне өйрәнүче

(Авылымдагы бер бәет турында)

«Безнең халык — шигырь вә җыр-бәетләр чыгарырга маил халык. Чү, аз гына бернәрсә шылт иттеме, инде аның турысында иртәгә урамга бәетләр чыга».

Г.Тукай

Яшел Үзән районы Мулла Иле авылының Канак урамындагы челтәрләп-бизәп эшләнгән матур йортка мемориаль такта куелган. Ак мәрмәрдән урамга бик чибәр кыз карап тора. Алтын хәрефләр аның турында болай сөйлиләр: *«Бу йортта хезмәт батыры Гөлсем Хәмидуллина яшәгән. Бөек Ватан сугышы елларында ул Мулла Иленнән Свияжск станциясенә көнтөн фронт өчен ашлык ташыган. 1942 елның 15 октябрь төнендә юлдан адашып, тирән суга төшкән атларын коткарган чакта һәлак булган».*

Бөек Ватан сугышы елларында хезмәт фронтында батырларча, үз-үзен аямыйча эшләп яшь гомере өзелгән кызның якты истәлеген менә шулай мәңгеләштергән безнең авылдашлар.

Мин 1995 елда Гөлсемнең иптәшләре, бергә укыган классташлары, колхозда бергә эшләгән хезмәттәшләре белән сөйләштем, истәлекләрен язып алдым.

Классташы **Әминә Кашапова** сөйли:

— Инде илле өч ел узган булса да, бүгенгедәй хәтеремдә: ул көнне ындыр табагыннан фронт өчен тугыз олау озаттык. Пар ат җигелгән бер олау белән Гөлсем китте. Ак брезент курткадан, кара итәк, кара күн бүрек кигән. Бигрәк сылу, чибәр кыз иде Гөлсем. Ару-талуны һич тә белмәде. Иң авыр эшләргә үзе теләп алына иде. Кешеләргә гаҗәп тә ярдәмчел иде. Кара күзләрен тутырып елмаеп караулары һич тә генә китми исемнән.

Вафира Хәлилова (классташы):

— Ул көнне, 15 октябрьдә, без авылдан Свияжск станциясенә ашлык илткәндә, бертуктаусыз салкын яңгыр яуды. Егерме биш чакрым юлны күп газап белән үттек. Атларга булышып, тездән пычрак ера-ера, арбаларны үзебез этешеп бардык. Җеп бөртеге дә калмады — чыландык, бик туңдык. Барып җиткәч, капчыкларны күтәреп, поезд вагоннарына ташыйташый җылындык. Бик авыр көз иде ул 1942 ел көзе. Ай буена өч кенә төн йокларга туры килде. Гөлсемебез иң авыр чакта да күңел төшенкелегенә бирелми торган кыз иде. Шушы бару — аның соңгы баруы булыр, дип кем уйлаган ул чакта. Гөлсемгә берүзенә төнлә кайтып китәргә туры килде.

Әйе, халык үзенең батырларын, фидакярләрен онытмый. Инде 53 ел вакыт узса да, Гөлсем халык күңелендә тере булып яши. **Гайшә Җамалиева**, **Гөлҗиһан Сабитовалар** да ул көнне Гөлсем белән бергә барганнар олау-

Гөлсем туып үскән нигездәге йортның хәзерге күренеше

ларда. Инде алар ак чәчле әбиләр, күптән лаеклы ялда. Алар, гомер язларына әйләнеп кайтып, кордашлары Гөлсем турында сагынып искә алалар. Авыр яшьлек, горур яшьлек, фидакярь яшьлек турында. Киләчәк өчен янган, киләчәк өчен бирелгән яшьлек турында.

Гөлсем күзгә төртсәң күренмәслек караңгы төндә пар атта ялгыз кайта. Атлар, адашып, куаклар, әрәмәләр араларыннан барып, һич уйламаганда, Әрә елгасы тобасына (иң тирән җиренә) килеп төшәләр. Кыз, атларын коткарырга теләп, боздай салкын суга ташлана. Башта мең бәлаләр белән бер атның камыт бавын ычкындыра, аннары икенчесенә тотына. Ләкин кыз үзе тирән суда дилбегәгә чорнала. Бөтен көчен куеп ычкынырга, чыгарга тырышып, дилбегәләрне тешләре белән чәйнәп бетерә...

Авылга авыр фаҗигале хәбәр тарала. Атна-ун көн эчендә шул елларның гадәте буенча бәет чыга. «Гөлсем бәете». Бу бәет мәктәптә «Туган як» музеенда кадерләп саклана. Укучыларның яңадан-яңа буыннары тәэсирләнеп укый бу бәетне.

Бәеттән өзекләр:
Миннән калган күлмәкләрне
Анда-монда куймагыз.
Әй, туганнар, васыять әйтәм:
Минем кебек булмагыз.

Ал димәде, ял димәде
Гөлсем колхоз эшендә.
Гөлсем мескен гүргә керде
Егерме ике яшендә.

Гөлсем мескеннең атлары,
Коры арба кимерә.
Гөлсем суларга баткачтын
Чыга алмый тилмерә.

Әрә суы тирән икән —
Дәрман кирәк йөзәргә.
Әти-әни бәхил булсын,
Ходай язсын түзәргә.

Атлар мине ташлап китте,
Атлар кайтыр су буйлап.
Гомерегез үтәр инде
Мәңгегә мине уйлап.

Сугыштагы егетем белән
Кавышулар булмады.
Суга батып үлгән чакта
Чыгаручы булмады.

Безнең авыл тегермәне
Дөбер-дөбер тартадыр.
Кара төндә пар ат белән
Гөлсем өйгә кайтадыр.

Атым суларга батканда,
Кулым тезген тотмады.
Туган-үскән нигеземә
Башым исән кайтмады.

Ак яулыклар бәйләдем дә
Җәйләремне җәйләдем.
Тезгенне таба алмыйча,
Кулларымны чәйнәдем.

— Гөлсем атлар өчен үлеп тора иде. Бигрәк тә карап кына эшли иде инде. Сыйпый-сыйпый ашата иде үзләрен, — дип искә ала шул елларда ат карауы булып эшләгән **Рәхимә апа Бикмуллина**.

Гөлсем Хәмидуллина — ишле семьядан. Аның бертуганнары — **Фәрхруй**, **Хәлимә**, **Барый**, **Әхәт** — барысы да гомер буе колхозда намуслы хезмәт иттеләр, авылның иң хөрмәтле кешеләре булып саналалар.

Гөлсем апаның XX гасыр азагында исән-сау булган, аны якыннан белгән чордашлары — Әминә Кашапова, Вафира Хәлилова, Гөлҗиһан Сабитова, Рәхимә Бикмуллиналар инде якты дөньяда юк. Гөлсем апаның бертуганнары да инде вафат. Алар белән яшәү, туган җиргә хезмәт итү, алар белән очрашу, истәлек-хатирәләрен язып алу нинди зур бәхет! Урыннары җәннәттә булсын!

Төп нигездә — Гөлсем туып үскән йортта — энесе Әхәт яшәде. Гаҗәп тыйнак, намуслы, алтын куллы балта остасы иде. Менә аның йорты ничек балкып гора. Һәр чәчәген, һәр бизәген, һәр сырын үзе ясаган. Бу — ул үзе иҗат иткән матурлык — хәләл көче, намуслы хезмәте чагылышы. Гаиләсендә берсеннән-берсе акыллы биш бала тәрбияләп үстерде. Сугыш чорларын җилкәсе белән тартып барган Әхәт тә яшьли китте дөньядан.

Бу йортта хәзер Әхәтнең төпчек улы Шәүкәт гаиләсе белән яши. «Җитмеш төрле һөнәр иясе», — диләр аның турында. Балта остасы да, электр белгече дә... Эшкә оста, булдыклы ир-егет!

...Йорт стенасыннан урамга егерме ике яшьлек кыз карап тора. Косынкадан ташып, калын толымнары чыккан. Ачык матур йөз. Туры, ихлас караш. Мөлаем горурлык. Ачы сагыш аша сизелер-сизелмәс елмая, әйтерсең лә ул эндәшә:

— Рәхмәт, авылдашларым. Безнең яшьлекләрне онытмавыгыз өчен рәхмәт. Авыл нинди матурлана, тормышлар ничек ямьле, кешеләр нинди гүзәл!

Гөлсем туган йортының стенасыннан урамга һаман да шулай карап торыр. Кешеләр һаман да моннан аны искә алып үтә торырлар. Алтын хәрефләр һаман да сөйләрләр: *«Бу йортта Гөлсем Хәмидуллина (1920-1942) яшәгән...»* ■

«Минем шәҗәрәдә – Бөек Ватан сугышы еллары» конкурсы нигезнамәсе

I. Гомуми нигез

«Минем шәҗәрәдә — Бөек Ватан сугышы еллары» конкурсы тарих фәннәре докторы, профессор Фәйзелхак Ислаев инициативасы белән «Безнең мирас» журналы һәм «ТАТМЕДИА» ААҖе белән берлектә үткәрелә.

II. Конкурсның максаты һәм бурычлары

Максат:

1. Шәҗәрәләр аша Бөек Ватан сугышы тарихында татар милләтенең урынын билгеләү, тарихи үзаңын формалаштыруга өлеш кертү.

Бурычлар:

1. Нәсел тарихы нигезендә Бөек Ватан сугышында һәм тылда катнашучыларны барлау.
2. Нәсел шәҗәрәсен төрле форматта, зәвыклы, башкаларга үрнәк булырлык итеп башкару күнекмәсен формалаштыру.
3. Гаилә тарихында гына сакланган шәхесләрне татар дөньясына чыгару.
4. Туган як тарихын өйрәнүгә кызыксындыру уяту һәм татар теленә мәхәббәт тәрбияләү.
5. Укучыларда ватанпәрвәрлек һәм әхлакый идеаллар тәрбияләү.

III. Конкурсны оештыру һәм үткәрү

2014 елның июленнән — 2015 елның маена кадәр.

Катнашучыларның яше чикләнми.

Йомгак 2015 елның 22 июнендә, Бөек Ватан сугышы башланган көнне ясала.

IV. Материалларны кабул итү тәртибе

Тапшырылырга тиешле материаллар:

— Төрле ысулда эшләнгән гаилә шәҗәрәсе, А4 форматында, 1 бит.

— Сугышта яисә тылда катнашучы турында бер битлек инша (14 нче шрифт, интервал — 1, формат А4). Өстәмә материал — шәхеснең фотосурәте.

— Материалларны әзерләүче турында белешмә: исем, фамилия, әтисе исеме тулысынча; туган елы, эшләгән яисә укыган урыны; элемтәгә керү өчен телефон яисә электрон почта адресы булу зарур.

— Материаллар yanamiras@mail.ru почтасына яки редакциягә (Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2 йорт) җибәрелә.

— Һәр конкурсант 2015 елның икенче ярты еллыгына «Безнең мирас» журналына язылган квитанциянең күчермәсен тәкъдим итә.

V. Бәя бирү шартлары

1. Шәҗәрәнең башкарылу үзенчәлеге (иҗади якын килү).
2. Башкарылу зәвыклылыгы, затлылыгы.
3. Шәҗәрәдә урнаштырылган буыннар саны.
4. Инша эчтәлегенең Бөек Ватан сугышы елларында булган гыйбрәтле вакыйганы чагылдыруы.
5. Иншаның язма сөйләм таләпләренә туры килүе.

VI. Йомгаклау һәм бәяләү

«Минем шәҗәрәдә — Бөек Ватан сугышы еллары» бәйгесенә нәтиҗә жюриның йомгаклау утырышы карары беркетмәсе нигезендә «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире боерыгы белән рәсмиләштерелә. Катнашкан барлык авторларга сертификатлар, җиңү яулаган авторларга редакциянең дипломнары һәм истәлекле бүләкләр тапшырыла. Шәҗәрәләрне аерым китапка туплап чыгару ихтималы да бар.

Редакциядән: Конкурска язмалар күп килә башлау сәбәпле, алга таба аларны **www.beznenmiras.ru** сайтына гына урнаштырачакбыз.

Сулдан уңга: Аграфена Васильева, Рәшит Шамкай, Гөлнәзирә Зайцева һәм милиционер ролендә – мин фәкыйрегез. 1975 ел

СҮЗ ҺӘМ СУРӘТ

Рәдиф Сәгъди

Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында «Солдат хатыны» (Н.Анкилов пьесасы буенча) дип аталган спектакльне башлап җибәрергә санаулы минутлар калган... Казан театр училищесында укып йөргән чак иде ул. Академия театрында массовкада катнашкан өчен 1 сум 50 тиен түлиләр. Ә миңа сүзле роль эләкте, бер җөмлә иде инде ул: «Әйдәгез, гражданка Панкратова, сез кулга алынасыз!». Шуның өчен миңа 3 сум 50 тиен тама. 1976 елны үзем теләп армиягә китәсемне белгән курсташ егетләр: «Ролеңне миңа калдыр да, миңа калдыр», — дип, арттан да ияреп йөрделәр...

***

Россия Герое, полковник Радик Әбрар улы Бариев (бүгенге көндә — авиация генерал-майоры) Мари-Эл республикасының Бәрәңге районына кайткач, район хакиме Әлфәт Ибраев шалтыратты. Геройның туганнан туган абыйсы Әлфәт Габделхак улы: «Радик кайта, килеп кит әле» — дип мине кунакка чакырды. Өч мәртәбә геройлыкка тәкъдим ителеп тә, әлегә фәкать бер Алтын

Мин Россия Герое Радик Бариев һәм аның якын туганы Әлфәт Ибраев хозурында. 2006 ел

Йолдыз гына күкрәгендә балкый аның. Россия Президенты Владимир Путин, шушы олуг бүләк белән тәбрикләгәндә, аңа болай дигән: «Радик Әбрарович, өч Алтын Йолдызны да берьюлы биреп булмас, әмма да ләкин, әлегә берсен аласыз инде!»

***

Дустым, язучы Вакыйф Нуриев белән Биектау районының Әлмәндәр авылы сабан туена бардык. Менә хикмәт: Әлмәндәр авылында «Әлмәндәр» карт — Шәүкәт ага Биктимеров һәм аны сагалап йөрүче «Әҗәл» — Равил ага Шәрәфиевне очраттык. Алар белән фотосурәткә төшәчәгебезне белгән булсак, Вакыйф та, мин дә, әдәбият буенча Нобель премиясен бирү тантанасына дип, Лондон каласыннан ук махсус кайтарткан затлы фракларыбызны киеп килгән булыр идек. Һай, белгән булсак... ■

Янәшәмдә татарның асыл ир-егетләре. Уңнан сулга: Равил Шәрәфиев, Шәүкәт Биктимеров, Вакыйф Нуриев. 2007 ел

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор **РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВ**ның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни
(Йосыф Хасс-Хаҗиб)

Гомер эзсез түгел, михнәтең эзсез,
Хезмәтең үлчәүле, михнәт — үлчәүсез.

Бик ачынмый кеше гомер үткәнгә,
Ачынадыр эше зая киткәнгә».

...Азга канәгать, тик күңле бай булсын,
Кулы ару-пакь һәм йөзе ай булсын.

Фикерле, белә дин-шәригатьне дә –
Намус һәм вөҗдан бар шундый кешедә.

Бийләр табигате нечкә булу чын,
Таза булмаса аш, ашамас, дустым.

Ашчы ару булса, ару аш салыр,
Ару булса аш-су сөеп ашалыр.

Тәрбиясез кеше ашны да боза:
Кирәксезгә ашны тота, кул суза.

Сок кешенең саксыз кыланышыннан
Саклан, төрле ауру тарала шуннан.

Шуны әйтим – нинди булса да ир-ат,
Һичкем юк үзеңнән ышанычлырак.

Кешегә ышан, тик үзең бул пеше.
Үзеңнең ашың ич, үзеңнең башың!

Бу очракта ошбу мәкаль урынлы
(И, изге егетем, онытма шуны):

Ышан бүтәннәргә, тик күзәт, тикшер:
Үз мәнфәгатеңдә — үз күзең үткер.

Барча газиз шәйдән үз жаның газиз,
Газиз җаныңны син сакла һичсүзсез.

...Матур булсын ашчың, йөреше җитез,
Кырынган һәм буйчан, күңле—теле төз

Матур йөз кешегә күренер ару,
Ару булмаган аш тамакка кару[1].

Арулык-пакьлекне Алла ярата,
Пакьлек ир-егетнең данын тарата.

Пакизәлек барча кеше теләге,
Табын ямьле булса, ашың да тәмле.

Кеше кергән икән-аштан ерак тот,
Ашыйсың да килмәс, күрсәң пычракны.

Мөһим һәрбер эштә чынлык-тугрылык
Яманлыкка илтә кыек юл-юрык.

Ашчылар башлыгы кулын тыймаса,
Барча ашчы кулы кыек булачак.

---

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы саныннан басылып килә.
[1] Күрәсең, шундый мәкаль булган.

Ышан бүтәннәргә, тик күзәт, тикшер:
Үз мәнфәгатеңдә – үз күзең үткер.

Аш угрысы торса өсте-өстенә,
Ничек бий табыны ямьле булсын, ә?

Һәр кемсәгә тугры, иге булу шарт,
Иге кеше генә була шиксез шат.

Ни ди, ишет, дөрес холыклы бер ир:
«Тулы шат тормышка әхляк китерер».

Тугры бул – ташламас сине кот кошың.
Тугры юлдан йөрсәң төнгә калмассың.

Хыянәт кай төшкә аягын баса,
Шуннан ямь китә һәм бәрәкәт кача.

Хыянәтче кеше кул тыккан җирдә
Туфрагың таш була, корый диңгезләр.

Тугрылыклы кеше хуҗасын сөяр;
Хыянәттән яны ояты тыяр,

Тугрылыклы кеше бәген үз күрер,
Хезмәте илә ил милкен үстерер.

...Ул булсын акыллы, сабыр, белекле,
Һәм аш вакытында инсафлы, ипле.

Хезмәттә юл-юрык буенча йөрсен,
Кергәндә-чыкканда тәртибен белсен.

Эштә зирәк булсын, әдәпле, җыйнак,
Белемен куллансын һәм булсын тыйнак.

Тугры булса бийгә, көтеп мактауны,
Изге аты аны мәңге сакланыр.

Фәһемле кешеләр изге ат[2] теләр,
Бигрәк ышанычлы була галимнәр.

Ушлы кешеләрдән инсанлык килә,
Белекле кешеләр кешесе була.

Ни ди, ишет, энә, фәһемле кеше:
«Укымышлы кеше — кешеләр башы».

Укыган-вафалы — ул иң чын кеше,
Фида кылыр үзен бүтәннәр өчен.

Вафасыз, әшәке, кылыгы түбән
Җиңел генә кайтыр әйткән бер сүздән.

Менә, әйттем инде, сиңа, илбигем,
Ашчылар башының кирәк ниндие.

Тәмаман баш булсын савыт-тиргегә,
— Тыныч ашасын, — дип торсын, —
бигенәм.

Менә, илбик бу иң зур ашчы хакында
Әйттем мин хәтердә ни барсын да.

Илбик әйтте: — Яхшы аңладым моны
Тагын бер сүзем бар: аңлат син шуны

Хыянәтче кеше кул тыккан җирдә
Туфрагың таш була, корый диңгезләр

Менә хезмәтемдә көрәгә башы,
Ничек оештырсын ул эчү эшен?

Ничек белим шуның ышанычлысын
Һәм эчемлекләрнең кайсы чын?

ҮГДЕЛМЕШ КӨРӘГӘ БАШЫНЫҢ НИНДИ БУЛЫРГА ТИЕШЛЕГЕН ӘЙТӘ

Җавапта Үгделмеш әйтте: – И, илбик,
Бу хәлдә дә ярдәм итәдер белек,

Көрәгәче кирәк күптән сыналган,
Күңеле басылган, туры юл алган.

Бөтен, чын, рәхимле, күңел күзе тук,
Үз эшендә холкы – мисле аткан ук.

Менә шундый булса ул көрәгәче
Ярый, житсә аның бу эшкә көче.

Көрәгәче тота утның[3] төрлесен:
Эчйомшарткычын һәм ашсеңдергечен.

Аның кул астында төрле ут була:
Эчү, ялау өчен һәм дә йотуга.

[2] Изге ат — «изге булу даны».
[3] Утның – шифалы үләннең.

Яшьли әрәм булган күп егет күрдем:
Алар ашка чама куймыйча үлде.

Җимеш, эчемлекләр һәм күмәч-тәмәч
Авызыңа керер аңардан үткәч.

Идарәчегә аш аша хәтәр бар.
Көрәгәче, ашчы тәүләп татырлар.

Ашчы, көрәгәче тугры булмаса,
Илбикләргә бигрәк кыен ләбаса.

Ишет, ни ди бер бик тәҗрибәле бәк:
Ашыңны чамалап ашарга кирәк.

Тамакка игътибар башыңны саклар.
Аз ашаган, соңра, тәмлерәк ашар.

Яшьли әрәм булган күп егет күрдем:
Алар ашка чама куймыйча үлде.

Авызга игътибар бирергә кирәк:
Чире дә, име дә авыздан керә.

...Ушлы һәм белемле булсын эшендә –
Яшәүгә ямь кертә шундый кешеләр.

Яманга катылмый ушлы бер инсан,
Ялгышмассың шундый затка ышансаң.

Кәкре-бөкре агач утка ягыла,
Зинданга хаиннәр тотып ябыла.

Тугры булып эш кыл, и, ирдәм бигем.
Тугрылыктан тыш юк бер көнем минем.

Көрәгәче бик тә тыныч кылансын,
Йөрәге-күңле дә ярсу булмасын.

Дөрес башкарсын эш һәм хезмәтләрне,
Якын юлатмасын түбән затларны.

Үзе әзерләсен эчемлекләрне,
Үзе куйсын бөке һәм пичәтләрне.

Аш-суга кушыла торган утларны
Үзе әзер тотсын, белсен шуларны.

Сәрин, коры җимеш, шәрабь вә гөләп
Һәм башканы күрсен үз күзе беләп.

Ачысын-төчесен игътибарласын,
Табын савытларын алдан барласын.

Бийгә кылган хезмәт алыныр искә.
Кол үз файдасына эшләсен эштә.

Ни-нәрсәгә керсә кеше хезмәте,
Шуңарга баглана җаны һәм дәрте.

Бер акылдар ошбу хакта сөйләгән
Сүз бар (бик файдалы, аңласаң әгәр):

«Тырыш кеше нинди эштә булса да,
Яратып эшләсә, җанын да сала.
Кеше гомерен-көчен биреп эшләсә,
Шатлыгы-кайгысы шул эштә кала».

Ипле генә булсын – шундый табылсын –
Шул булыр илбиккә лаек табынчы.

Аннары сакыйга ярдәмчеләр дә
Сакалсыз һәм матур булсыннар бар да.
Бу эштә егетнең шундые кирәк –
Аның эшен күреп шатлансын йөрәк.

Ни-нәрсәгә керсә кеше хезмәте,
Шуңарга баглана җаны һәм дәрте.

Чырае ачык, саф йөзе – тулган ай,
Чәче кара, буе коеп куйгандай.

Билен кысып буган һәм яурыны киң,
Тән төсе ак, йөзе алсурак, ләкин.

Яшел, күк, сары, ал киемнәр киеп
Йөгерешсен яшьләр аш-су китереп.

Сакый да сакалсыз саф йөзле булсын.
Табынга төшмәсен һичбер чүп, кылчык.
Савытта чүп булса, ашы яраксыз,
Аш-суга төк төшсә ничек ашарсың?

Шуңа күрә галим сүзе хаклы сүз:
«Көрәгәче булсын сакалсыз-төксез».

Көрәгәче ару, саф йөзле булсын,
Шул чакта, ничектер, тәмлерәк сусын.

Матур йөзле ипле кеше ни эшли
– Бары үрнәк була, бары килешле.

Ни ди бер атаклы бәйтләр әйтүче
(Юсык белим дисәң, хәтергә күчер):

«Йөзе матур, сүзе ягымлы булсын,
Ни китерсә, шуннан бал татып торсын.

Ачыкканга сүзе гүя, аш кебек,
Чаңкаганга булсын, гүя ки, сусын».

Күрәгәченең нәкъ шундые кирәк,
Ярдәмчеләре дә булсын шундыйрак.

Шулай булса, аңар инаныр бәк, бий
Якын тотар тәмам, мотлак кирәк дип.

Мөһим эшкә, илбик, сайланмыш ирләр,
Тугры һәм әдәпле кешеләр телә:

Берсе ялавач һәм берсе бетекче,
Берсе сакый, тагын берсе пешекче.

Боларның һәрберсен бик сайлап ал да,
Соңыннан һичкемгә үпкәдә калма.

Юньсезрәк бетекче, ялавач килсә,
Болар кәсәфәте төшәдер илгә.

Пешекче-ашчылар начар булганы
Кәефкә, саулыкка сала зыянын.

Каты тот, и, илбик, кайбер затларны.
Талымлап, сайлап ал эшкә аларны.

Янә дә Үгделмеш әйтте: – И, илбик,
Бөекләрнең аты да, эше дә бөек.

Бөек эштә була баш катырулар,
Шулай итмәгән бий бийлектән колар[4].

Ни ди, әнә, бийнең киңәшче бәге
(Һәр сүзе – акылның саф энҗеләре):
«Айә, теләмә наз, азап телә бий!
Назлар һәрчак азап белән йөри бит.

И, бий, рәхәт түгел, михнәт теләгел,
Михнәт белән чын-чын рәхәт килә гел».

Каты тот, и, илбик, кайбер затларны.
Талымлап, сайлап ал эшкә аларны.

Бий тырышса, тыныч булыр ил, баер,
Ил баеса бийгә бәхет елмаер.

Рәхәтлектә гафил булма, и, кеше,
Кыенлыклар тиз үк килеп җитешер.

Ничәмә-ничә бу ашчы-киңәшче
Хезмәт итсәләр дә, и, дус бий кеше,

Хаҗәтеңне синең белүче – үзең,
Үзеңнән яхшырак белмәс, шул сүзем.

Ни ди, әнә, күпне күргән боерыкчы[5]
(Син аны язып ал, соңынан укы):

«Газиз җаның өчен чынлап күрәшкән
Беркем дә табылмас үзеңнән башка.
Сакла син үзеңне ахырга кадәр,
Һичбер җай калмаса гына маташма».

Әйтәсемне әйттем, и, котлы бийем,
Очраучан чирләрнең утын һәм имен.

Шул —мәзкүр кешеләр баетыр илне,
Бий данын күтәреп, дошманны җиңер.

Моны сөйләдем менә бу бабта,
Тагын сүзләрем бар тагын бер хакта.

Илбик тыңлар булса, мин сөйләп бирәм,
Югыйсә һичкемгә әйтмим – яшерәм.

Җавап бирде илбик: – Сөйлә, и, идез[7]
Нәрсә турында син әйтмәкче идең.

Кирәкле була ул син әйткән һәр сүз,
Фәһемдә дәрья син, гыйлемдә – диңгез.

Һәм Үгделмеш әйтте: – И, котлы илбик,
Сездән тияр илгә – халыкка белек.

Сөйләдем илбиккә хезмәтлек юлын,
Ягьни ничек эшли нинди төр колы.

---

[4] Кола-у – «гөрселдәп авып төшү».
[5] Боерыкчы, боер, боерык – барча борынгы төрки дәүләтләрдә вәзир һәм баш судья.
[6] Идез – «югары акыл иясе» (татар сүзлекләрендә очрый).
[7] Идез – «югары акыл иясе» (татар сүзлекләрендә очрый)

Бийләр дә белергә тиеш кол хәлен,
Бигрәк тә елларча хезмәт иткәнен.

Бийләр хөкем йөртсә коллар өстеннән,
Бий дә азат түгел коллар хөкменнән.

Коллар бийне күпме хөрмәт итсәләр,
Бий дә колны хөрмәт итсен шулкадәр.

Хезмәтче мал өчен хезмәт итәдер,
Әгәр мал тапмаса шунда, үртәлер.

Илбик әйтте: – Сөйләп бирче ипләбрәк,
Хезмәтченең хаккы нидән гыйбарәт?

ҮГДЕЛМЕШ ИЛБИККӘ ХЕЗМӘТЧЕЛӘРНЕҢ БИЙ АЛДЫНДАГЫ ХОКУК-ХАКЛАРЫ ТУРЫНДА СӨЙЛИ

Һәм Үгделмеш әйтте: – Бийләр каршында
Хезмәткәрнең эшенә күрә хаккы бар.

Тәүдә бий туйдырсын аның тамагын,
Соңра булдырырга кирәк-ярагын.

Эш булдыру имгәк, азап, михнәтле,
Шуңа бәкләр эшче колны хөрмәтли.

Җан-тән илә эшли тырыш кол кеше,
Аңар кыйммәт төшә бий сөенече.

Тирләп-туңып, ач-тук, җәяү - сыбайлы[2],
Кылыч, балта һәм ук тәнен яралый.

Чирү-теземдә уң-сулдан, йә алдан
Атлый ул «бийгә тисен, дип, файдам».

Яуда барса алдан – үзе бер калкан,
Бие тере кала, ул үлеп калса.

Шулай ул бийенә сөенеч теләп,
Михнәтендә ялгый көннәрен төнгә.

Бу хезмәтләр өчен, бий, үтә хакын:
Түләп тор акчасын, изге бел атын.

Ни ди, әнә, данлы Өч урдага хан[3]
– Халыктан сайланмыш гадел, чын инсан.

И, холкына олуг бий булган кемсә!
Бөек бел яугирне, ул хезмәт итсә.

Бий кулын озайта тугры хезмәткәр,
Нәкъ ул бийгә төзи авыл һәм шәһәр.

Бий никадәр булса бөек вә көчле,
Хезмәткәрләренә тик ул бурычлы.

И, илбик, кешегә хөрмәт – кешелек,
Кеше күңленә юл тап иң элек.

Кеше күңеленә юл табу нидә?
Аның кыйммәтен һәм хакын белүдә.

Хезмәткәр хезмәтнең әҗерен көтә,
Әҗерен бирмәсәң кешелек китә.

Хезмәтче кыйммәтен билгели бийләр:
Никадәр файдалы икәнен үлчәр.

Һиммәтенә күрә кыйммәте, диләр,
Бәяне чамала хезмәткә тиңләп.

Кеше терлек кебек, бер яктан, илбик,
Боларны тиңләргә дә мөмкин кебек.

Тамагын туйдырсаң әгәр елкының,
Аласың файдасын тиздән үк аның.

Бәге әҗер бирсә һәм мактап алса,
Хезмәтче аңар җан фида кылачак,

Ул инде тугры һәм тыңлаучан булыр,
Бәкне сөендерим дип хезмәт кылыр.

Тәҗрибәле берәү әйткән, ди, моны:
«Белемеңә күрә кул озынлыгы».

Кешегә иге бул – ул җанын бирер,
Аңар берне бирсәң, ул унын бирер.

Кеше аслам күрсә, шуңа кол булыр,
Азапка атылыр, биакыл булыр.

[2] Сыбайлы — атлы (гаскәри). Татар сөйләшләрендә дә актив кулланылыштагы сүз.
[3] Хан сүзе КБ-тә монда беренче тапкыр килә, бәлки ул соңынтын өстәлгәндер.

Кирәк хезмәтчегә эш хакын бирү,
Ярлыны кидерү, ачны туйдыру.

Нинди бий була ул, и, котлы бийем,
Чыгармаса ярлы хәлдән үз илен.

Ни диләр, ишет син карыйлар сүзен
(Карыйлар сүзе ул – егетләр күзе):

«Азапласа да бер имгәк күршесе,
Кешелекле җавап бирә чын кеше,

Кешенең хезмәтен хөрмәт кылмаган
Кеше дип аталмый, ул инде хайван.

Хезмәт итүчеләр ике төр булыр:
Бере азат, бере кулдагы колдыр.

Кол ул хезмәтендә ирексез була:
Аны, тыңламаса, таяклый хуҗа.

Азат үзен үзе хезмәт кылдыра,
Аны кирәк авыр хәлдән йолырга.

Бар азат – буш[4] *кеше – игелек колы,*
Боларга ачып бир игелек юлын.

Азат һәм кол тиңдәш булу шәп түгел.
Азатны динчә тот, колны кол дип бел.

Бийләрнең сәрае – тынычлык җире,
Сәрай тоту сиңа файда китерер.

Хезмәткәр баеса, данлый бий атын,
Бий исеме мәңге калыр шуннан соң.

Бий белән хезмәтче, ялчы арасы
–Нәкъ менә сатасы – сатлык аласы.

Сатучы саткан шәй алучы өчен
Бер мая-теләгән нәрсә эшлисең.

Аны кая, нинди эшкә бүләсең –
Ел, ай, көннәр узгач файда күрәсең.

Шуның кебек уңар ялчы кеше дә,
Хуҗа белән бердәм булса эшендә.

Бәге колга йомшак әйтеп эш бирер,
Ялчы җан-тән белән эшләр күп гомер.

Ялчы, яугир фида кылыр җанын да,
Кылыч орып алыр шәһәр-авыллар,

Дошман муенын кисәр, хәзинә яулар.
Бий теләгәнен табар – нигъмәтләр явар.

Болар, бийем, синең мәнфәгатеңә.
Ялчыга тиешле мәрхәмәт кенә

Әнә сәүдәгәрләр башлыгы әйткән
(Табыш өчен дөнья гизгән базаркян):

«Үз углыңнан якын файдалырак кол;
Дошман була сиңа инсафсыз угыл».

Бар хәрәкәтлеләр табыш эзлиләр;
Табышсыз калган карт аучы тиз үлә.

Яугирләр бийләрнең канат каурые,
Канатсыз кош очмас, и, бийләр бийе.

Бий кодрәткә ират белән ирешә;
Ират илә бийләр төеннәр чишә.

Җыелса батырлар бий тирәсенә,
Бар дөнья керер бий идарәсенә.

Җыйса бий галим һәм һөнәрлеләрне,
Ул хәл итәлмәгән мәсьәлә бармы?

Җиһангиргә галим кирәк мең төмән,
Шулай булса карар аңар бар җиһан.

Арзанлама гыйлем-һөнәрне угыл:
Гыйлем-һөнәр гүя аккош кебек ул.

Аккош сүрәтендә фән-гыйлем коты,
Ягъни аның аккош буладыр аты.

Дәвамы бар ■

[4] Буш монда «ирекле».

СОЛДАТ

Гаяз Исхакый

(роман)

XXI

Төрмәдән этап чыгарга шактый вакыт калган булса да, Садыйк һәм аның иптәшләре, һәммәсе, бөтен әйберләрен хәзерләп, төеннәрен төенләп, акчаларын яшерен урынга тегеп, юл киемнәрен киенеп, күптән бирле конвой көтәләр иде. Боларның көткән нәрсәләре конвой солдатлары, этап кына булса да, болар керә торган яңа тормыш, төрмәдән никадәр начар булса да, төрмә булмас, начарлыкка булса да, үзгәрү булыр дип, шул минутны үзенә бертөрле ләззәт белән көтәләр иде.

Боларның күбесе этапның нәрсә икәнен бик яхшы белсә дә, этапта әллә ничә көннәр, атналар, айлар былчыракта өстерәлергә, һәр минутта, конвой солдатлары тарафыннан мыскыл ителергә, юлда тугры килгән төрмәләрнең әллә нинди надзирательләре тарафыннан бөтен кешелеге аяк астына тапталырга тугры килүен белсә дә, юл буе ачлы-туклы барырга мәҗбүр булуын, төрмәләрдә этап бүлмәләрендә әллә нинди авырулар йөртүе бик якынлыгын хәтерләреннән чыгармасалар да, боларның тормышларының бу үзгәрүе җәһәннәмнең бер кырыеннан икенче кырыена гына күчү икәненә бик чыннан ышанса да, күңел һаман шул үзгәрүне зур шатлык белән көтә иде.

Садыйк та, әлбәттә, болар кебек иде. Аның да бу төрмәдән чыгасы, аның да шул төрмә тышындагы һаваны сулыйсы, шул стенаның теге ягындагы манзараларны күрәсе килә иде. Аны тагы, боларга башка, киләчәктә политик булып Себердә тору уе да шактый кызыктыра. Ул андагы политикларның бер ата, бер ана баласы кебек бергә торуларын, байларының фәкыйрьләренә ярдәм итүләрен, белемлеләре наданнарын укытуларын — берсе өчен икенчесенең җанын аямауларын белгәнгә, аның күңеле дә шул иптәшлек, туганлык тормышына ашкына, шуны тизрәк күрәсе килә, шуның ләззәтен тизрәк татыйсы килә иде. Аның бу киләчәк өмиде, ул тормышка мәхәббәте бик шәп булганга, аның шул тормышка ашыгуы бик куәтле булганга, ул үзенең монда калдыра торган иске тормышын элгәреге кебек кызганмый, аның өчен элгәреге кебек кайгырмый иде.

Әгәр Гайниҗамал булмаса иде, әгәр Гайниҗамал белән болар арасында биш елдан бирле сөешү булмаса иде, Гайниҗамал солдатка киткән Садыйкны дүрт ел көтмәсә иде, Садыйк бу тормыштан бик җиңел аерылыр иде.

Ләкин Гайниҗамалның барлыгы, аның Садыйкны сөюе, аның Садыйк аркасында шулкадәр авырлыклар күрүе Садыйкны һәрвакыт Гайниҗамал алдында бурычлы, бик зур бурычлы иттереп хис кылырга мәҗбүр итә. Ул һәрвакытта бу мәсьәләне уйлаганда, Гайниҗамал моның өчен әллә никадәр егетлек кылуын хәтеренә китереп, аның шул каһарманлыгына каршы үзенең бертөрле дә эш кыла алмавын уйлап эче поша, вөҗданы газаплана иде.

Себергә китү мәсьәләсе мәгълүм булгач, бу эш тагы да ачыграк булу белән, тагы да яктырак төс белән Садыйкның алдына килгән, Гайниҗамал мәсьәләсе каравылдагы солдат кебек Садыйкның вөҗдан ишеге төбенә аяк баскан иде.

Ахыры. Башы журналның 2014 елгы 8 нче санында.

Бүген, этап көнне, Гайниҗамал күрешергә килгәнгә, Гайниҗамал да шул мәсьәләне белешергә килгәнгә, Садыйк иртәдән бирле шуны уйлый, иртәдән бирле шуны төрлегә борып, шуны Гайниҗамалга файдалы иттереп хәл итәргә юл эзли иде. Ләкин һәр уеның ахыры, Садыйк белән Гайниҗамал җиңә алмаслык манигъларга очраган кебек, һәр уйның да очы булып чыга алмый торган тар урамга барып төртелә иде. Гайниҗамалга тәмам өметне өзеп, аерылуны тәкъдим итәргәме?.. Үзенең сөйгәненнән мәңгегә аерылырга, аерылырга түгел, шул аерылуны уйларга да хәтта батырлыгы җитми иде. Ул Гайниҗамал белән тагын кавышуны, солдаттан кайткач, кавышканнарыдай кавышуны тели иде.

Аның өмидләре, уе шул юлдан китеп, Себердә Гайниҗамал белән булачак туйларын, бергә торуларын, бергә сөргендә яшәүләрен, бергә бала-чага үстерүләрен күз алдына чәчәкләндереп китерә башлый...

Тагы өмидсезлек килеп катыша. Тагы Гайниҗамалның мондалыгы, Гайниҗамалның бара алмавы, Гайниҗамал белән ике арада әллә ничә мең чакрымнар мөсафә булуы куәтне ала. Яңадан шул ук фикернең башына кайта, яңадан башлап уйларга мәҗбүр итә иде.

Ул Гайниҗамалга турыдан-туры: «Мәңгегә аерылабыз!» — дип, аның белән бәхилләшергә уйлый. Каты күңеллелек белән: «Һәммәсе бетте!» — дип әйтергә ниятли. Ләкин шул ук сүзне Гайниҗамалга әйтә башлаган иттереп уйлагач, тагы калтырый... Йөрәге сыкрый, бәгъре әллә нинди бик кадерле бернәрсәсен, газиз нәрсәсен алдырырга теләгән кебек, эченнән еглый иде.

Ул тагы яңа планга керешә, тагы юллар эзли. Тагы яңа уй, фикер артыннан чаба. Тагын чынга алмый торган тыкрыкка фикер, уйлар тойгылар барып бәрелә. Гайниҗамал алга килү белән шунда ук бу фикер ерагайганнан ерагая, «киләчәк» юлы чуалганнан чуала иде.

Менә надзиратель күренде. Садыйкка: «Свидание!» — дип кычкырды. Садыйк үзен-үзе сизмәенчә, үзе әллә кайчаннан бирле эзләгән нәрсәсен кинәттән тапкан кебек, бик күптән югалткан газиз нәрсәсен, искәрмәстән хәтерләгән кебек, ук кебек, конторга таба — Гайниҗамалга таба атылды. Ул, баскычтан төшкәнен сизмичә, капкадан кергәнен белмичә, күрешү бүлмәсенә омтылды.

— Гайниҗамал!..

Аның тырышып, кайгысын яшереп мәхәббәтле елмайган күз карашы, Садыйкның мәсьәләсен бердән хәл итте. Гайниҗамалның мәхәббәтле карашы Садыйкның бөтен чишә алмаган төеннәрен бердән чиште. Бөтен кайгыларын, хәсрәтләрен бердән язды...

— Гайниҗамал!..

Бетте... Һичнинди аерылу юк. Мәңгегә юк!..

Солдатка китү аера алмаган кебек, көчләп Себергә җибәрү генә шул күзләрдән аерамы соң?!

Садыйк, мәсьләнең шулай һава кебек җиңел хәл кылынуыннан, фәрештә кебек саф булып китте. Аның күңелендәге бөтен кайгылары эреде, бетте. Аның күз алдындагы бөтен ямьсез моназаралар бердән югалды.

Ул, көлә-көлә, Гайниҗамал белән сөйләште. Көлә-көлә, аның белән киләчәк күрешүне уйлашты. Көлә-көлә, Гайниҗамалның ничек Себергә баруларының планнарын корышты.

Надзиратель: «Свидание бетте!» — дип кычкырды.

Шул тавыш Исрафил суы кебек, Садыйкның бөтен тамырларына йөгереп, аны калтыратты. Күңелендә әллә нинди: «Бетте! Мәңгегә бетте!» — дигән фикер тагын купты.

Корт чапкан кебек Садыйк сикереп торып: «Хуш, Гайниҗамал!» — дип, ике кулын сузды. Аның боз кебек суык кулы Садыйкның йөрәгенә үлем суыгы

йөгертте. Аның күзеннән мөлдер-мөлдер ага торган яшьләр Садыйкның кулына тамып, йөрәген көйдерде, әчен яндырды.

Алар бик озак берсеннән-берсе аерылмаенча, кулга-кул тотышып тордылар. Бик озак күзләреннән ага торган яшьләренең ихтыярыннан ычкына алмаенча, катып калдылар. «Свидание кончилось!», — дигән горурлы тавыш аларны тагы уятты. Гайниҗамал кызу-кызу куеныннан алып, Садыйкка баулы бөти сузды:

— Мә, шуны так! Әбидән калган... Алла дошман күзләреннән сакласын!

Садыйк машина кебек бөтине киде. Машина кебек: «Хуш!» — диде. Барган машина кебек камерага чапты.

***

...Конвой килде.

Садыйк, әйберләрен күтәреп, бөтен иптәшләре белән конторга тулдылар.

Кулларына кара теккән егермеләп конвой солдатлары арасыннан үтеп, беренче бүлмәгә керделәр. Җиңнәренә, погоннарына өч тасма теккән бер унтер, берәм-берәм боларның фамилияләрен кычкырып чыкты. Һәммәсеннән кайда баруын, ничә яшьтәлеген, казённый әйбере бармы-юкмылыгын сорап үтте. Аннан соң иптәшләренә тентергә кушты. Тентү башланды.

Башта яхшылап бәйләгән әйберләрен чишеп, туздырып ташладылар. Аларны берәм-берәм карап-капшап чыктылар. Чыккан кәгазьләрне, китапларны читкә алдылар. Акча-фәлән тапсалар, читкә куйдылар. Аннан соң һәммәсен берәм-берәм чишендереп, бөтен киемнәрен тентеделәр, кесәләрен актардылар. Сүтекләрен дә җентекләделәр. Төймәләрен ташка бәреп тыңладылар. Яка төпләрен бармак белән ватып-ватып карадылар.

Һәммәсе бетте, беркемнән бернәрсә табылмады. Уголовныйларның яшергән пычаклары, сәясиләрнең яшергән акчалары, хатлар — һәммәсе урынында калды.

Әйберләр тагы җыелды. Тагы бер мәртәбә фамилияләрен кычкырып чыктылар. Унтер төрмә дәфтәренә кул куеп, этапны (Садыйкларны) кабул итте.

Аларны, 18 кешене, икешәр-икешәр тезделәр. Бик күбесенең кулларын күршесенең кулы белән тимер чылбыр белән бәйләделәр.

Садыйкка күрше карт кына бер уголовный тугры килде. Аларны латыш солдаты кыска гына бер чылбыр белән бәйләп куйды. Һәммәсе төзелеп бетте.

Конвой башы солдатларга: «Хәзерләнегез!» — диде.

Солдатлар шарт-шарт иттереп, мылтыкларына патроннар тутырдылар. Кылычларын кынычларыннан чыгардылар.

Унтер конвойга: «Каршы килүче булса, атыгыз! Качучы булса — атыгыз! Качучыны үтерә алмасагыз — үзегез җавапка каласыз! Марш!» — диде.

Солдатлар ялангач кылычлар белән боларны камап алдылар.

— Марш!.. Төрмә капкасы ачылды...

Икешәр-икешәрләп, этап чыга башлады...

Төрмә капкасы төбендә әллә никадәр озатучылар каршы алдылар. Еглый-еглый күзләре кызарып беткән этисе-әнисе, читтә генә тора торган Гайниҗамал. Садыйкның богауланган кулын күргәч, әнисе тагын еларга тотынды, этисе чуар яулык белән күзләрен сөртергә кереште. Гайниҗамал, бер сүз дә әйтмәенчә, күзен мөлдерәтеп: «Хуш!» — диде.

— Хуш!

— Этап! Марш!

Урам буйлап, богауларны чылдырдатып, Садыйклар кузгалдылар. Бик озакка кадәр озатучылар аларны озата бардылар. Шәһәрне чыкканчыга кадәр Садыйкның этисе, әнисе, Гайниҗамал читтән килделәр.

Бик озакка кадәр, әнисе әллә нинди ишетелми торган сүзләр сөйләде. Бик озакка кадәр, Гайниҗамал, кызуланып-кызуланып, урам читеннән алга чыгып, Садыйк белән күзгә-күз очрашты. Бик озакка кадәр күз белән саубуллашты. Бәхилләште.

Менә шәһәрне чыктылар. Конвой солдатлары озата баручыларны куарга тотындылар. Аларның ялынулары, ялваруларына карамаенча, 5-10 сажин читтән генә барырга рөхсәт бирделәр. Арттан: «Хуш! Хуш!» — дигән тавышлар ишетелә башлады. Сөргенчеләр дә һәммәсе: «Хуш! Хуш!» — дип җавап бирделәр.

Урман икешәрләп җавап кайтарды.

Менә Садыйкның әнисенең: «Бәбкәм Садыйк, хуш!» — дип яшькә манчып әйткән сүзләре ишетелде. Садыйк: «Хуш!» — дип җавап бирде. Әтисенең: «Хуш, углым!» — дигән калтыраган тавышы колакка бәрелде.

— Хуш, әти!

Садыйкның колагы Гайниҗамал тавышын көтәргә тотынды. Юк…

Садыйк актык мәртәбә күрер өчен, актык мәртәбә Гайниҗамал белән күзгә-күз карашыр өчен борылды. Әнә, Гайниҗамал! Әнә, аның күзе. Әнә, ул әллә нәрсә әйтә…

Садыйк башын селки. Гайниҗамал яшен сөртә.

— Хуш, Гайниҗамал!

Гайниҗамал тавышы урынына конвой латыш солдаты сүгенеп кычкырды да: «Кая карыйсыз?!» — дип, Садыйкның җилкәсенә мылтык түбәсе белән бәрде.

Садыйкның күз алдында чаткылар чәчрәде. Аның бөтен җанын, тәнен хурлану басты. Маңлаена тир бәреп чыкты.

Ул бердән һәммәсен: атасын, анасын, Гайниҗамалны онытты. Һәммәсе бетте… Фәкать ачу чыгу, хурлану гына калды… Ул бизгәктәге кебек калтырый, күршесе уголовный белән бер аякка басып бара башлады.

— Туктагыз!..

Этап туктады.

Солатлар читкәрәк киттеләр, тәмәкеләрен кабыздылар. Бер-берсе белән сөйләшә башладылар. Берничәсе кылычларын кынычларына тыгып, башкалары белән күрештеләр дә, шәһәргә таба юнәлделәр. Калганнары көлешә-көлешә, бер-берсе белән арестантларның кулларындагы богауларны ача башладылар.

Менә Садыйкның богавын алдылар. Әнә, алда теге учитель. Әнә, ераграк кына Себергә китә торган бер марҗа. Әнә, Архангельга йибәрелә торган бер студент… Әнә…

Юл буенда, ераграк түгел, арыш кыры. Ул якта — матур ялан. Ерак түгел генә куаклык, аның артында урман…

Әнә, тегендә, озын иттереп, яшел кыр киткән. Ул кыр Садыйклар авылларына кадәр бара.

Әнә, уңда, зураеп-олыгаеп, Идел ята. Аның теге ягында, иксезләнеп-чиксезләнеп болын киткән…

Еракта гына бер күл ялтырый. Әнә, кыр тургае сайрый. Үзәкне өзеп сайрый. Саубуллаша! Гайниҗамал кебек, ул да бәхилләшә.

Әллә нинди бер куәт Садыйкны артка борды. Әнә, еракта-еракта бик күп халык. Әнә, яулык болгыйлар.

Әнә, әнисенең ак яулыгы.

Әнә, Гайниҗамалның ак алъяпмасы.

Әнә, ул селкә, ак кулъяулык селкә…

«Кил монда! Дүрт ел көттем, тагы кайда киттең?!.» Әйе, чакыра… Гайниҗамал чакыра!..

— Мин кая китәм?.. Ник китәм?.. Дүрт ел көткән Гайниҗамалны ташлап!

Шул яшел кырны, шул киң Иделне, шул җылы кояшны, шул туган илне ташлап ник китәм?..

Конвой: «Марш!»

Менә этап тагы кузгалды. Менә Садыйк тагы атлады.

Юк, мин китмим! Мин үз аягым белән туган илемнән Себергә китмим!

Китмим!

Әнә, тар гына ялан. Әнә, куаклык. Әнә, аның артында зур гына урман. Әнә, аның артында тирән елга... Аның артында иректе тормыш... Гайниҗамаллы тормыш...

Садыйк бердән атылды. Бер сикерүдә, фанарның теге ягына чыкты. Ул ук кебек куаклыкка таба атылды.

Әнә, куаклык, әнә урман, әнә, ялан.

Әнә, Гайниҗамал...

Этапта зур тавыш купты. Латыш солдатлары кычкырышырга керештеләр. «Ат! Ат!» — дигән сүзләр Садыйкның колагына бәрелде.

«Шарт!»

Менә атты.

Хозер Ильяс, сакла!

Тимәде.

Садыйк тагын гайрәтен арттырды. Аның күз алдына көлә-көлә Гайниҗамал килеп чыкты. Ул ак киемнән. Кочагын ачкан.

Тагы «Шарт»!

Тагы тимәде. Инде бер генә сикерергә, бер генә!

Әнә, куаклык! Анда ирек!

Тагы «Шарт»!

Тагы тимәде.

Садыйк куаклыкка сикерде. Мылтык, ливарвир тавышлары арасында әллә нәрсәсе төшкән кебек хис итте.

«Калса, калсын!» дигән кебек, тагын сикерде. Аягы әллә нишләде. Чалынды. Күлмәге белән тәне арасында кайнар бернәрсәнең акканын хис итте...

Йөрәген тотып, тагын бер омтылды. Аягы мунчала кебек йомшарды. Буыны тота алмады. Ул сикергән йиренә йитә алмаенча, яшел үләнле канауга егылды.

Ул ни булганын, үзенең җәрәхәтләнгәнме, юкмылыгын белеп бетермәде. Аны кот очу басты.

Сөңгесен күтәргән, күзе акайган латыш солдаты аны куып җитте. Садыйкның егылганлыгына карамаенча, сөңгесен эченә тыкты...

Садыйкның күз алдына әнисе килде. Әнә алар...

Садыйкның котылуына сөенәләр. Садыйкның иреклегенә шатланалар...

Садыйк котылды... Котылды...

Бу этаптан, бу залим идарәдән, бу вафасыз дөньядан котылды. Шул котылу шатлыгына аның күзе елмайды, йөзе көлде.

Ул: «Аллаһ!» — дип актык сулады да, яшел үлән өстеннән ага торган кайнар каны белән бергә, җан бирде.

Аның йөзендә, күзендә елмаюы, көлүе ябышып калды.

Идел берни булмаган кебек һаваланып агуын дәвам итте.

Яшел арыш басуы, акрын искән җил белән, шул шәһид алдында башын иде.

Сабан тургае Садыйкның аһын, Гайниҗамалның моңын көйләргә тотынды. Этап китте...

Текстны басмага ***Мәсгуд Гайнетдин*** *әзерләде.* ■

«Киткәннәрнең юлы ураулы»... Шагыйрь Мөхәммәт Шәйхинең каләмдәше Фәннур Сафинга багышлап язган шигырен укыгач, күңелгә шундый юллар уелып калды. Әйе, замана кырыс, хәтер сыек. Бик яшьли киткән шагыйрьләрнең түгел, әдәбиятта ат уйнаткан, исән чагында телдән төшмәгән каләм ияләренең дә исемнәре, иҗатлары, әгәр аларны кайгыртучы булмаса, вакыт тузаны астында тиз җуела. Әдәбиятыбызның, димәк, халкыбыз язмышына битарафлыктан килә бу хәл.

КИТКӘННӘРНЕҢ ЮЛЫ УРАУЛЫ...

Факил Сафин,
филология фәннәре кандидаты

Шагыйрьдән чамалап була —
Халыкның нинди көче.
Шагыйрьләр күктән иңә дә,
Яшиләр халык өчен...

Монысы да **Мөхәммәт Шәйхи** шигыреннән. Тик инде икенче шагыйрь — нечкә лирик шагыйрь **Мизхәт Хәбибуллин** вафатыннан соң язылган.

Татар әдәбиятының бай мирасы бар. Миңа соңгы елларда **Кадыйр Сибгатуллин**, **Хәниф Хөснуллин**, **Зариф Мөэминовның** әдәби мирасы белән шөгыльләнергә туры килде. Зариф Мөэминов исеме әдәбият хәдимнәренә бөтенләй таныш түгел. Ачыш, дисәң дә, ачыш! Ярты гасырдан артык ничә повестьте, хикәяләре дөньяга чыгуны өмет итеп чормада яткан бит! Узган ел **«Безнең мирас»** журналында (2014, 2-3 нче саннар) әлеге фольклорчы-әдипнең **«Мәрьям»** повесте басылып чыкты. Әдәби мирасны өйрәнү — шактый четерекле эш. Әдәбиятыбыз — милли рухыбызны сугарып торган иң шифалы сулы чишмә бит ул. Монда бер генә исем дә онытылырга тиеш түгел. Әдәби чор рухын, мәдәни сурәтен тулы килеш күзаллау өчен әдипләрнең әсәрләрен өйрәнү генә җитми. Моның өчен әдәби хәрәкәткә катнашы булган барлык шәхесләрнең мирасын тикшерү таләп итәлә. Бер чор әдипләре иҗатындагы аваздашлыкны, эстетик, рухи эзләнүләрнең үзенчәлекләрен күзәтү кызыклы һәм әһәмиятле нәтиҗәләргә китерә.

Мөхәммәт Шәйхи шигърияттә үзенең тавышын узган гасырның җитмешенче

Разил Вәлиев:

Соңгы елларда туган ягыма — Түбән Камага кайткан саен, мине ниндидер үзем дә аңламаган моңсулык баса, күңелемә, жаныма нидер житми. Йортлар да үз урынында югыйсә, дуслар, туганнар да бар, ә нигәдер күңелнең бер почмагы буш, бер чите китек…

Менә шушы жыентыкка керәчәк шигырьләрне кулга алып укыганда, күңелем сулкылдый башлагач, ниһаять, аңладым: миңа Түбән Камада, юк, Түбән Камада гына түгел, менә шушы якты дөньяда дустым Мөхәммәт, ак күңелле, риясыз табигатьле, шагыйрь жанлы Мөхәммәт Шәйхи житми икән!

Бу каты бәгырьле, мәрхәмәтсез һәм кырыс яшәешкә Мөхәммәт, бер караганда, адашып, ялгыш килеп эләккән изге жан кебек тоела иде миңа. Шуңа күрә дә, Түбән Камага кайтуга, мин, бөтен эшемне онытып, аның янына ашыга идем. Бер мин генә түгел, аны белгән бик күп мосафир Мөхәммәтнең жылы фатирында үзенең күшеккән күңелен жылытып, аның шигъри учагыннан жанына жылы алып киткәндер. Чынаякларга чәй ясагач, өстәлгә кәгазьләрен таратып сала да, Мөхәммәт шигырь укырга тотына. Шигырьләрендә — халык язмышы, мәхәббәт газаплары, туган як моңы, яшәү һәм үлем мәгънәсе.

Мөхәммәт, кешегә ярдәм кирәк булганда, беркайчан да «юк» дип әйтә белми иде. Ярдәме дә күңел юаткыч коры сүз генә түгел, чөнки ул барысын да булдыра, кулыннан килмәгән эш юк. Кирәк икән, чалгы алып, болында каерып печәнен чаба, кирәк икән, балта тотып, кәртинкәдәй өй сала… Ул авылларда әдәби кичәләр оештырып йөрүче дә, яшь шагыйрьләргә төпле киңәшләр бирүче киң күңелле остаз һәм мәрхәмәтле мөхәррир дә, шулар өстенә менә дигән рәссам да…

Мөхәммәт, Ходай Тәгалә биргән

еллар уртасында ишеттерде. Нык итеп, күпләрне сискәндерерлек итеп… Вакытлы матбугатта шигырьләре күренеп торса да, беренче шигырь жыентыгы **«Көн үзәге»** — бары 1984 елда гына дөнья күрә. Тагын ике елдан балалар өчен **«Уткүз»** исемле жыентыгы басылып чыга. Беренче шигырьләре белән үк милләткә хезмәт итәргә килгән шагыйрь икәнен раслый ул. Борынгыдан килгән моңнар, халкыбызның үткәне, тарихта тоткан урыны белән ныклап торып кызыксынуы һәр шигырендә диярлек чагылыш таба. Әмма аларның күпчелеге дөнья күрмичә, шагыйрьнең архивында гына сакланган. Урау юллар үтеп, әлеге архив Татарстанның халык шагыйре **Разил Вәлиев** кулына килеп кергән, ул исә бу мирасны барлап, аерым жыентык итеп төзү эшен миңа тапшырды. Ике еллап вакыт Мөхәммәт Шәйхинең әдәби мирасын, биографиясен өйрәнү, жыентыкны төзү эшенә китте. Кирәклеген, мөһимлеген тоеп, чын күңелдән эшләдем мин моны.

Мөхәммәт Шәйхи (Мөхәммәтвәли Шәйхетдин улы) 1949 елның 25 сентябрендә Татарстанның Мамадыш районы **Еники-Чишмә (Түбән Кыерлы)** авылында колхозчы гаиләсендә туган. Хезмәт юлын колхозда башлап жибәрә. 1971 елда (кайбер мәгълүматларда 1974 елда) Түбән Кама шәһәренә килеп урнаша һәм төзелештә электр белән эретеп ябыштыручы (шагыйрь Мизхәт Хәбибуллин кебек үк) булып эшли башлый. Тиз арада шәһәрнең «Кама таңнары» әдәби берләшмәсендә үз кеше булып танылa, талантлы шагыйрь, рәссам буларак ихтирам яулый. Шагыйрь йөрәге һәрчак хөрлек сорый, шуңа күрә дә, төзелештә эшләүгә караганда, Мөхәммәт күбрәк рәссамлык белән, кулы балта эшенә яткачтын, «шабашка» белән шөгыльләнә. Беренче мәртәбә мине аның белән шагыйрь күңелле, мәгърифәтче-педагог, Чаллы шәһәрендәге 2 нче гимназия директоры **Рифкать** Нурулла улы **Муллин** таныштырган иде. Дөньялар кайный башла-

Сулдан уңга: Мөхәммәт Шәйхи, Фәтхулла Абдуллин, Рәис Маликов һәм Николай Кузнецов – Түбән Кама сабан туенда. 1980 ел

ган туксанынчы елларның башы иде ул. Рифкать әфәнде гимназия диварларын милли тарихыбызны алга куеп бизәтү эшенә керешкән иде. Мөхәммәт шушы эшкә катнашып киткән икән. **Чаллыны** яратып сөйләгән иде. **Түбән Камада** әдәби мохитнең бик үк гади булмаганына зарланып та алды. «Бу берләшмә — нигезенә көнчеллек салынып төзелгән хикмәт оясы булды», — дип, хәсрәтле елмаеп та куйган иде. «Шигырьләрне бер читкә куеп, роман яза башладым әле. Тарихи әсәр язып күрсәтәм әле мин боларга», — дип, Рифкать әфәндегә карап күз кысып куйды. Ул чагында Рифкать Муллин миңа Мөхәммәт Шәйхи турында: «Баштанаяк милли гамь белән янучы шагыйрь, — дигән иде. — Хәзерге вакытта «милләт» дип кычкыручылар күп, ә Мөхәммәт Шәйхи җитмешенче еллар башында ук халкыбыз язмышы, милләт тарихына багышланган гүзәл шигырьләр язды. Шуңа күрә аны, китаплары чыгуга да карамастан, Язучылар берлегенә алмый йөрттеләр», — дип, шагыйрь язмышына ачыклык

гомеренең бик кыска буласын сизгәндәй, һәрчак ашыгып эшләде, ашыгып язды, ашыгып яшәде. Бар нәрсәгә дә җитешәсе, бөтен җирдә дә буласы, бөтен эшләрен эшләп бетерәсе килә иде бугай аның. Күп нәрсәгә җитешсә дә, үз тормышын көйләргә, исән чакта менә күләмле җыентыгын күрергә өлгерә алмый калды...

Шушы җыентыкка кергән шигырьләрне Мөхәммәтнең үз авызыннан да кат-кат ишеткәнем бар иде. Әмма бүген алар миңа башкачарак яңгырый, бүген аларның мәгънәсе тагын да тирәнрәк, чөнки аларга ике дөнья фәлсәфәсе сыйган...

Гасыр башларында бу кадәрле
Авыр булмагандыр Тукайга да...
Асрамага шигырь бирәм, шигырь,
Сәгъди абзый, җаным, син кайда?!

Мөхәммәт Шәйхинең бу шигыре, киләчәк буыннарга атап язылган шагыйранә васыять кебек яңгырый. Шуңа күрә җыентыкка кергән һәр шигырь укучы күңеленә барып ирешер, Мөхәммәтнең шигырьләрен «асрамага алучылар» күп булыр, дип ышанам.

та кертте. Роман мәсьәләсенә килгәндә, чыннан да Мөхәммәт Шәйхи **«Асылтауда асыл кошлар яши»** дип исемләнгән тарихи әсәр яза башлаган. Архивында сакланган кульязмада әсәрнең утызлап бите бар. Әсәр 1236 елгы вакыйгалардан, ягъни Болгар дәүләтенә монгол гаскәрләре һөҗүм чорыннан, 13 яшьлек үсмер малай сөйләве рәвешендә башланып китә. Кереш өлешеннән бер өзектән язарга ниятләгән әсәрнең рухын чамаларга була:

«Һәр кеше үзенең җиде бабасын белергә тиеш. Җиде бабасын белмәгән зат — әле ул кеше түгел. Дөньядан үзенең кем икәнен белмичә китүчеләр дә бар. Әлбәттә, моңа ул гына гаепле түгелдер, димәк, аңа әтисе исән чагында әйтеп калдырмаган. Акыл кергәч, җиде бабасын эзләгәннәр һәм тапканнар да шактый. Кеше үз-үзен хөрмәт итсә, үз бәһасен тойса үткәне турында уйлый, кызыксына башлый. Бу — гомер-гомердән шулай. Эзләнүнең чиге юк. Ә мәнсезлекнең чикләре тагын да киңрәк...

Мин үземне эзлим....
Урманнарга керәм — мин андадыр.
Тауларга менәм — мин андадыр.
Далаларга чыгам — мин андадыр.
Диңгез буена киләм —
мин андадыр...

Кычкырам. Миңа каршы «мин» җавап бирә: «Мин монда!»

Болгар, Суар, Бүләр, Җүкәтау шикелле бөек шәһәрләр гөрләп яшәгән төбәкләргә киләм. Аннан да миңа дәшәләр: «Мин монда!.. Мин монда!!. Мин монда!!! Монда!.. Монда!!! Монда!!!»

Үткән белән бүген арасында, бүген белән киләчәк арасында бәргәләнә-бәргәләнә Хәтер очып йөри... Хәтер — мин! Мин — хәтер!..»

Кызганыч, әсәр фәлсәфи-хисси дулкында шактый өметле башланса да, дәвам ителмичә, шулай ният тә генә калган булса кирәк...

Билгеле, Мөхәммәт Шәйхинең шигырьләре белән таныш идем. Уртачадан озынрак гәүдәле, чандыр кыяфәтле булып истә калган. Бирчәеп беткән уч төпләре кытыршы, куллары авыр, хәрәкәте салмак, ара-тирә сүз кыстырып куя да, башын арткарак ташлап, тын кала. Рәссамнарда була торган поза шулдыр инде, дип уйладым ул чакта. «Аргамак» журналында проза, шигърият һәм әдәби тәнкыйть бүлеген алып баручы буларак, Мөхәммәт Шәйхинең шигырьләрен журналга әзерләп биргән идем инде. Бер шигыре, соңрак, 1992 елда, журналның 7-8 санында басылып та чыкты. Очрашкан чакларда сөйләшкәләп йөрсәк тә, нигәдер, «Аргамак» белән арасы бик якынаеп китә алмады аның.

Разил Вәлиев Чаллы Язучылар оешмасын җитәкләгәндә Мөхәммәт Шәйхи берара пропаганда бүлегендә эшләп алган. Әмма Мөхәммәт Шәйхи бу форсаттан да файдаланмаган, берлеккә керү һаман артка күчерелеп киленгән. Чыннан да Түбән Камада әдәби мохит иҗат кешеләре өчен бик үк җиңелдән булмагандыр. Мизхәт Хәбибуллинның күренекле шагыйрь Кадыйр Сибгатуллинга язган хатында: «Түбән Каманың әдәби торышында атмосфера начар», — дип язган иде. Шуны истә тотыптыр инде, Кадыйр Сибгатуллин талантлы иҗатны вакытында күреп, дөрес бәяләү җитмәгәндә, әдәбиятка зур зыян ясалуы хакында ачынулы сүзләр язып калдыра. Чаллыга килү белән, Мөхәммәт Шәйхинең шигырьләре белән таныша, шигъриятен зурлап сүз әйтә һәм шагыйрьгә берлеккә керү өчен рекомендация яза.

Мөхәммәт Шәйхи — традицион стильдә иҗат итүче лирик-фәлсәфи шагыйрь. Шигъри тыны иркен, шигырьгә салынган образларга хилафлык китерми, тема белән җитди эш итә, шигырьнең «төшен» чыгарып бетерергә омтыла. Хәсән Туфан, аның иҗаты белән ныклап танышса, һичшиксез, М.Шәйхине дә «гүзәл

гамьле» шагыйрьләр рәтендә атар иде. Болар исә — Равил Фәйзуллин, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов, Кадыйр Сибгатуллин...

Мөхәммәт Шәйхи 1996 елның 15 февралендә, бүгенгәчә төгәл билгеләнмәгән сәбәп белән, вафат була. Аның гәүдәсен бер йортның подъездыннан табып алалар. Аннан алда гына рәссам дусты В.Мәхмүтов белән сөйләшеп, гармун уйнап, моңга тулышып утырган булалар. Бу хәбәрне ишеткәч, Василий Мәхмүтов, ярсуына чыдый алмыйча, гармунны тугызынчы каттан аска томыра... Ә аннан да алдарак, вафатына бер атна кала, Мөхәммәт Шәйхи беркайда дөнья күрмәгән шигырьләрен Түбән Камада чыгып килүче «Туган як» газетасына кертеп биргән була. Әлеге шигырьләр газетада берничә ел дәвамында басылып чыга торалар, аннан инде алар, 2001 елда, Разил Вәлиев тырышлыгы һәм Таһир Нәбиуллин ярдәме белән «Милли китап» нәшриятында басылган «Ак буран» исемле җыентыкта урын алалар. «Ак буран» җыентыгы басылып чыккач, Рифкать Муллинның «Шигырьләре үксез булмасын» («Туган як» газетасы, 2002 ел, 5 февраль), Айдар Хәлимнең «Шигъриятебезнең Мокамаемы... әллә яңа Акмулласымы» («Шәһри Казан, 2005 ел, 8, 15, 16 июль саннары) мәкаләләре дөнья күрде. Инде менә, ниһаять, «Якты чишмә» исеме белән яңа китабы да дөнья күрде. Билгеле, бу китапка Мөхәммәт Шәйхинең барлык шигырьләре дә кергәндер, дип әйтеп булмый. Иҗатны барлауны дәвам итәргә кирәк.

Кайтуы кыен киткәч шул,
Кайтуы кыен киткәч...
Бәлки, инде мәңгелеккә
Кайтыр вакытлар җиткән...

Мөхәммәт Шәйхинең иҗаты татар шигъриятендә лаеклы урын алыр, дип ышанам. Аның, урау юллар узып, кайтыр чагы җитте. Мәңгелеккә!

Кадыйр Сибгатуллин:
(1942-1994)

Таланты чамалы гына булып та, әрсезлеге белән үзен танытып, шагыйрь исемен алып йөрүчеләр аз түгел. Ходайдан мул талант, янып торган йөрәк, чын мәгънәсендә шигъри җан бирелсә дә, бик үк күзгә кермәскә, язганнарын бастырып чыгару хакында әллә ни кайгыртмаска хирысрак шагыйрьләр дә очраштыргалый. Бик сирәк кенә. Мөхәммәт Шәйхи – шундый шагыйрь. Аны Язучылар союзына тәкъдим итүебезгә инде өч-дүрт ел гомер үтте. Өченче рекомендация җитмәү сәбәпле, ул шушы көнгә кадәр Союзга алынмаган. Рекомендация бирергә теләмәүчеләр булудан түгел, үзе сорамады, кайгыртмады. Шул рекомендациясен менә мин язам. Аның соравы буенча түгел, үзем теләп. Чөнки күпме көтәргә мөмкин? Союзга шундый шагыйрьләр кирәк.

Мөхәммәтнең шигырьләрен сокланмыйча укып булмый. Кайсы шигырен генә алып карасаң да — ачыш, яңа ачыш, тормыш, әдәбият, иҗат ачышы. Күңеле моң белән, шигырь белән тулган. Примитив моң-сагыш түгел. Тирән, мәгънәле, әрнүле моң. Шуның өстенә яза белү таланты, гаҗәп тыгызлык, кыскалык, осталык...

Кичкә кадәр әле шактый ара...
Түләнмәгән әҗәт — бара.
Үтәлмәгән нәзер — бара.
Көн үзәге, вакыт бара, —

ди ул үзенең «Көн үзәге» дигән шигырендә. Үзенә гаять тә таләпчән Мөхәммәт. Бу таләпчәнлек әнә шул «көн үзәген» тоюдан, кешегә тумыштан ук йөкләнгән зур бурычларны аңлаудан киләдер. Шуңа күрә ул бер шигырендә болай ди:

Сандугач булсаң иде лә
илеңдә, төбәгеңдә: —
Идел-Кама тирәгендә —
халкыңның йөрәгендә!

28.05.1992 ел

МӨХӘММӘТ ШӘЙХИ
шигырьләре

АСРАМАГА ШИГЫРЬ БИРӘМ

Егерменче гасыр.
Син — гасырның
Таш бәгырьле, рухсыз, кансызы…
Үз-үзенә кабер казый кешелек,
Үксеп-әрнеп елый җан, сызып…

Үзен-үзе ата, сата бәндә,
Җанын сата, сата иманын…
Көч һәм байлык — яшәү бизмәнендә,
Көлгә очты вөҗдан, инану…

Намусларга кара сөрем сара,
Хаксызлыкта кала ак ирләр…
Шигырьләрен, булат кылыч итеп,
Көрәшергә чыккан шагыйрьләр…

Көрәш мәйданында шагыйрь — ялгыз,
Көрәш алымнары — искеләр:
Дошманнарын шагыйрь алда көтә,
Ә дошманнар арттан кистерә…

Бүгенгегә инде җан өшерлек,
Нәрсә көтә безне иртәгә?!
Нәрсә көтә, фараз күп булса да,
Якты чынлык инде югалган…

Ава шагыйрь.
Шигырьләре кала,
Үксез сабый сыман дөньяда…
Базарларда оран салыргамы,
«Асрамага шигырь кем ала?..»

Шагыйрьләрен саклый алмасак та,
Шигырьләре үксез булмасын —
Җиргә салкын, җан өшерлек салкын,
Ятимлектә өшеп туңмасын…

И, кешеләр, җылытыгыз аны,
Кырын карамагыз сез аңа…
Ул бит сезгә җылы бирер өчен
Килгән иде якты дөньяга…

Килгән иде, әңгер күмгән җанны
Чыгарырга нурга, яктыга…
…Һәрбер үзгәрешнең туп-ядрәсе
Шагыйрьләргә төбәп атыла…

Китә шагыйрь…
Бәлки, теге дөнья
Ачар аңа җылы куенын…
Бу дөньяда шашып бәйрәм итә
Канга туймас үлем уены…

Егерменче гасыр…
Син — гасырның
Таш бәгырьле, рухсыз, кансызы…
Үз-үзенә кабер казый кешелек…
Үксеп-әрнеп елый җан сызып…
Гасыр башларында,
Бу кадәрле
Авыр булмагандыр Тукайга…
«Асрамага шигырь бирәм, шигырь,
Сәгъди абзый, җаным, син кайда?!»

1995 ел

ҖАН ҮЗӘГЕ

Үзәге нык булган халык
Чыгышын эзли.
Үзәге нык булган халык
Баш иялмый.
Үзәге нык халыкларга
Бер афәт тә,
Заманнарның ач җиле дә
Тия алмый…
Үзәге нык булган халык
Җанын саклый.
Еллар аша шытып чыгып
Тамыр җәя.
Үзәге нык халыкларда —
Яшәү көче.
Тарихта да бу халыкка
Иң зур бәя.
Киткәннәрнең варислары —
Дәвам булган.
Тик исемнәр үзгәргәннәр —
Үзәкләр нык.
Хакыйкатьне раслар өчен
Күз алдына
Һәрвакытта килеп баскан
Ачы чынлык.
Сөннәрме ул, болгарлармы,
Татарлармы —
Кем булса да,
Тамырларда бер кан ага.
Җан үзәге нык халыкның —
Иманы нык,
Ә иманлы үзенең эзен,
Барыбер таба…
Үткәннәрнең кайтавазы
Дулкын-дулкын.
Тарихларның катламнары
Тирән-тирән.
Меңәр елдан меңәр елга
Баса-баса,
Дөнья буйлап мәңге үлмәс
Татар килә…

ШИГЫРЬ УКУ

Үз-үземә шигырь укып чыктым,
Озын чагы иде төннәрнең.
Урам тутырып чабып йөргән җилләр
Кинәт тынып калды бермәлне.

Өй артына сузылып ап-ак көртләр
Тын да алмый шигырь тыңлады.
Уйга чумган дөнья кылларында
Шигъри аһәң ярсып зыңлады…

Уйлата да шигырь, елата да,
Керсен генә шигырь җаныңа,
Ияртә дә китә үз артыннан,
Карамыйча малың, даныңа…

Шигырь уты көчле.
Чын шигырьләр
Бервакытта да бушка атмаган.
Юкка гынамыни шагыйрьләрнең
Җанын кыйган явыз патшалар…

Шагыйрьләрдән котылырга була,
Ә шигырьдән, белмим ул ягын…
Үз-үземә шигырь укыдым да,
Һәм үземне-үзем тыңладым…

Күңелләрнең китек чагы иде,
Авыр чагы иде дөньяның.
Ишетә белүчеләр ишеткәндер,
Тыңлый белүчеләр тыңлады…

…Үз-үземә шигырь укып чыктым,
Озын чагы иде төннәрнең.
Ә аннан соң укыр шигырем бетте,
Күңел түренә үрелеп эзләндем…

Тик бер генә шигырь калган анда,
Ләкин әле аңа иртәрәк…
Мин укырмын аны, соңгы чикнең
Соңгы сызыгына җитәрәк…

Нинди булыр алкыш, әйтә алмыйм,
Йә, кайсыгыз ачык әйтә ала?!
Һәрбер адәм яза торган җыр ул —
«Яшәү-үлем», диеп атала… ■

АЧЫ ТӘҖРИБӘ АВАЗЫ

Габдулла Тукай

● Бездә мөхәррирләр тәмле хыялларга корбан булырга түгел, кирәк эшләремезгә дә аздыр. Әгәр... кыйбатлы мөхәррирләремез һәлак булып бетсәләр, дөньяда тик корчаңгы мөхәррирләр генә калачактыр.

***

● Мин бит... саф, коеп куйган поэт кына түгел, мин дипломат, политик, общественный деятель дә бит. Минем күз күпне күрә, колак күпне ишетә.

● Каләм кулда була торып, яшь шагыйрьгә, мәгълүмдер ки, курку берлән өркү хәрәм.

● Илаһым, рәхмәтең белән шагыйрьнең бәйле телен чиш — дуслар һәм дошманнар хәленнән ул бераз хәбәр бирсен.

● И каләм!.. Яз караны «кара» дип һәм акны «ак», җөпне «җөп» дип һәм шулай ук такны «так». Һәр кеше күңелен күрмә, милләт авыруына бак!

● И каләм!.. Европаны күтәреп син югары күкләргә кадәр, ник төшердең безне — җиде кат җир астына кадәр?

● Фикерегезне языгыз, тик якты булсын фикерегез; фикерегездер — фикеребез һәм фикеребездер — фикерегез. Язуйк һәм басып таратыйк — олы фикерләр кузгалсын, ...дөньяга фикеребез юл алсын. Чөнки фикерләр кайнаса, эшләр дә алга китәр — бу мәгълүм булсын һәркемгә — шушындый безнең фикер. Борынгыдан бирле безнең фикеребез тоткын иде... Фикеребез торсын яңарып гел... Искермәсен, үзара җәнҗал-ызгыштан кыл кадәр ис кермәсен! Фикеребез халыкны таркаткыч җилләр истермәсен, истереп, милләтнең берләшү юлын кистермәсен!

● Хат — күрешүнең яртысы.

● Газета битләрендә бер кешегә сөйләнгән сүз бөтен дөньяга сөйләнә.

● Әфкаре гомуми[36] берлә уйнарга ярамый.

● Бер заман гүргә керер ялгыз башың... Уйлаган башың, каләм тоткан кулың бергә черер.

● Мин Казанны тәхте пай[37] һәм Казан арты татарларын шушы көнгә кадәр милләтен югалтмаган вә киләчәктә дә югалтмаячак төп халык дип саныйм. Милли әдәбиятыбыз фәкать шулар телендә, шулар рухында гына булуын телим.

● Әдәбиятымызның асылы, җәүһәре булган безнең Казан телендә фикерләр «келт» итеп кенә искә төшәләр.

● И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле! Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

● И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең берлән синең, кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем.

● И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам: ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, Ходам!

● Халык әдәбияты, бер дә кәгазьгә язылмаса да, буыннан буынга ишете-

Дәвамы. Башы журналның 2014 елгы 9 нчы санында.

леп, халык күңелендә бер дә онытылмый торадыр.

● Яшәсен халык әдәбияты, яшәсен туган тел!

***

● Тәнкыйть — кирәкле шәйдер.

● Әйе, без язганнарда да кимчелекләр һәм зур кимчелекләр булырга мөмкин. Без мәкаләләребезнең башына: «Бу мәкалә яки бу шигырь барлык кимчелекләрдән пакь», — дип язмадык лабаса!

● Һәр матурда начар якның берсе булгай.

● Урманның да бөтен җирендә төлке булмый, мәкаләнең дә һәр сәтырында көлке булмый.

● Әсәр «эз» булса, мин аның арысланмы, куянмы эзе икәнен ачык белә алам.

● Цензор белән он иләүче хатын арасында аерма шул гына: берсенең иләге төбендә — эшкә ашмаганрак нәрсәләр кала, берсенекендә — иң кадерле нәрсәләр генә кала.

● Һичбер шагыйрь, шигыренең бер юлы ахырын «такмак» дип язгач та, каләмен колагына кыстырып, мич арасыннан кыштыр-кыштыр «шакмак» эзләп йөрергә мәҗбүр түгелдер… Такылдамак белән мәүзүн сүз[38] сөйләмәк икесе башка-башка булырга кирәк.

● Мөмкин кадәр шигырьне аз язсагыз да, матур вә хуш иттереп языгыз. Сәнаигы нәфисә[39] аз гына бер хата сәбәпле тупас һөнәрләрдән булып китүе бар.

● Шагыйрьгә матур шигырь язу читен. Әмма бер дә язмый тору аннан да читен.

● Һәр язганыгызны нәфис вә изящный дип әйтсәм, мин сезгә дуст булудан бигрәк, монафикъ[40] булудан куркам.

● Оригинальный нәрсәне мактау табигыйдер.

● Әле без татарларда теория словесности вә шигырьләр өчен хорей, дактиль-фәләннәр ясалмаган чакта, вәзен вә гармонияләр төрлечә булса да зарар юк, фәкать мәгънә кирәк, гүзәл ифадә[41] кирәк.

● Поэзия эзләргә булганда, Иделнең югары ягыннан бигрәк, түбән тарафы муафикъ.

● Болынга бозау керсә — «түчә!», игенгә чыпчык төшсә — «көшш!», базга песи керсә — «прс!» дисең. Әмма әдәбиятка шушындый кешеләр керсә — ни дисең? Аптырап, уйлап торасың да, бер дә кууны аңлатырга сүз тапмагач, язучының колагына гына: «Энем, моннан болай мондый нәрсәләр язмаска тырыш!» — дисең.

● Дарелголүмнән[42] яңа укып чыккан бер яшемезгә… нинди әсәрләрне укымак кирәк? Моны сайлый белергә, тәнкыйть булмаса, мөмкин түгелдер. Чөнки аңар яхшы рисалә табу бөтенләй борчак басуы өстендә бер билгеләнгән борчакны табу кадәр читендер… Әгәр бер рисаләне укып та, тиз генә тәнкыйтен дә табып алса, аңар бик уңай буладыр.

● Тупаслар белми шигърият дигән сүз кадрене.

● Әдәпсез сүзләр бар. Шундый сүзләргә юл киселсен иде.

● Мин мәктәпләребезнең хәл теле илә миннән ярдәм көткәнен күрдем. Мин моңа салкын кан белән карый алмадым. Мәктәп китаплары язарга башладым… Бу… минем законный хакым иде. Татар балаларының рухына файдалы тәэсирем булачак, иншалла.

● Тәнкыйть итүченең дә кем очрады шул булуы тагы ярамыйдыр. Мөнтәкыйд булыр өчен, әлбәттә, үзләре дә әдәбият галәмендә күп ат уйнаткан тәҗрибәле вә әхлаклы адәм булуы матлубтыр[43].

[36] Әфкаре гомуми — җәмәгать фикере;
[37] Тәхте пай — башкала;
[38] Мәүзүн сүз — тезмә сүз;
[39] Сәнаигы нәфисә — нәфис сәнгать;
[40] Монафикъ — икейөзле;
[41] Ифадә — аңлата белү;
[42] Дарелголүм — университет;
[43] Матлуб — таләп ителә.

Текстны басмага ***Зиннур Мансуров*** *әзерләде.* ■

ТУКАЙ ШИГЪРИЯТЕ – ТӨРКИЯДӘ

Алия Мөбарәкшина

Милли әдәбиятыбызның «зур фәхерле, чын бриллиант каш»ы – бөек шагыйребез Габдулла Тукай төрек әдәбиятының госманлы дәвере әсәрләре, аеруча, Мөхәммәд Чәләбинең «Мөхәммәдия» китабы белән илһамланып иҗат мәйданына килде.

Шуңа күрә дә Җамал Вәлиди, Галимҗан Ибраһимов, Габдрахман Сәгъди, Фуад Көпрелезадә кебек күренекле әдәбият белгечләре аның башлангыч иҗат чорын «Мөхәммәдия» дәвере» дип атадылар. Моның шулай икәнлеге XX гасыр дәвамында рус, татар, төрек, азәрбайҗан, казах һ.б. милләт галимнәре тарафыннан кат-кат ассызыкланды. Әле Мотыйгулла хәзрәт мәдрәсәсендә укыган елларда ук, ул төрек диван әдәбияты һәм ауропалашуга йөз тоткан Яңа заман француз мәдәнияте һәм әдәбияты традицияләрен үзләштергән төрек Тәнзимат чоры әсәрләре белән кызыксына. Г.Кәрам сүзләренә караганда, «Хәтта бервакытларны ул, Төркиягә китеп, Истанбул дарелфөнүненең әдәбият шөгъбәсендә укуын дәвам итмәк фикеренә дә төшкән иде. Ләкин, берьяктан авыруы, икенче яктан матди ихтыяҗ аны күп өмидләреннән мәхрүм итте» (Г.Кәрам. Габдулла Тукаев//Аң. — 1914. — №7. — Б.130-133.)Сәгыйть Рәмиев янына Әстерханга кунакка баргач та,

Төркиягә бару хыялы кабат калкып чыга. Кызганыч ки, мөстәкыйль дәүләт булып яшәгән төрек җиренә авыру Тукай аяк баса алмый.

Тукайның исеме, шәхесе, шигърияте турында мәгълүматлар Төркиягә бары тик аның вафатыннан соң гына барып ирешә. Госманлы вакытлы матбугаты битләрендә шагыйрьнең үлеме турында кайгы уртаклашу, тәгъзияләр, тормыш һәм иҗат юлы турында мәкаләләр дөнья күрә. Соңрак, Төркия Республикасы оешкач та, әле бездә — Татарстанда — Төркия белән әдәби-мәдәни бәйләнешләрне өйрәнү тыелган елларда да, төрек галимнәренең татар шагыйре иҗаты турында фәнни-тәнкыйди мәкаләләре газета-журналларда, әдәби җыентыкларда басылып килә. 1960 елларда Төркиядә «Тукай» мәдәни җәмгыяте оештырыла. 1965-1968 елларда 10-12 битлек «Тукай бюллетене»нең 24 саны дөнья күрә. Советлар Союзы җимерелеп, илдә сәяси үзгәрешләр башлангач кына, татар студентларына Төркиягә барып белем алу, Татарстанда төрек гимназияләре ачылу (ни кызганыч, аларның эшчәнлеге туктатылды) галимнәребезгә Төркия фондлары, архивлары һәм китапханәләрендә эшләү, дистә еллар буена өйрәнергә рөхсәт ителмәгән хезмәтләр белән таныша алу мөмкинлеге туа.

Соңгы ике дистә ел эчендә Төркия архив-китапханәләрендәге Тукай иҗатына бәйле материаллар, аз-азлап булса да, Казанга кайта һәм фәнни яктан өйрәнелә башлады. Төркиядә нәшер ителгән, татар шагыйре иҗатына зур мәйдан биргән «Казан» журналының Татарстан Милли китапханәсендә кайбер саннары саклану шул хакта сөйли. Андагы Тукайга бәйле кайбер материаллар, татарчага тәрҗемә ителеп, Зөфәр Мөхәммәтшинның «Ил йолдызы» (2006) хезмәтендә дә урын алды. Гомумән алганда, тарихы бер гасырлык булган Тукай турындагы фәндә шагыйрь иҗатын төрек әдәбияты белән бәйләнешләр яссылыгында өйрәнү тукталып тормады. Посттоталитар дәвер — совет әдәбияты белемендә төрек-татар мәдәни һәм әдәби бәйләнешләре күзлегеннән Г.Халит, И.Нуруллин, Р.Нәфыйков, Р.Ганиева, Р.Башкуров хезмәтләре языльды. XXI гасыр башында — Татарстан белән Төркия арасындагы сәяси, икътисади, мәдәни, әдәби мөнәсәбәтләр тагы да ныгый төшкәч, Тукай иҗатын төрек әдәбияты белән бәйләп, киңрәк һәм тулырак өйрәнү мөмкинлеге туды. Шәхсән үземнең дә «Габдулла Тукай иҗатында төрек тексты» дигән темага кандидатлык диссертациясен язарга алынуым шул хакта сөйләсә кирәк.

ТР ФА Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының аспиранты буларак, ТР Мәдәният ми-

нистрлыгы тарафыннан үткәрелгән конкурста, «Тукай һәм Төркия» дип исемләнгән проект белән катнашып, җиңү яулавым да шул юнәлештә уңышлы адым булды. Шуның нәтиҗәсе буларак, ТР Мәдәният министрлыгы һәм Г.Ибраһимов исемендәге ТӘһСИ җитәкчелеге ярдәме белән Төркия архивларында төрек галимнәре, язучышагыйрьләренең Тукай турында язган хезмәтләрен барлау, аларның копияләрен Казанга алып кайту, 2016 елда Габдулла Тукайның 130 еллык юбилеена тәгәлләү күздә тотылган Тукай энциклопедиясенә мәкаләләр язу бурычын алга куеп, фәнни җитәкчем һәм энциклопедияне төзү өчен җаваплы галим, филология фәннәре докторы Зөфәр Рәмиев белән Төркиягә юл тоттык.

Мәшһүр Истанбул безне җылы кояшы белән каршы алды. Мәһабәт таш мәчет манараларыннан иңгән азан тавышлары гүзәл шәһәрне илаһият нурларына коендыра. Күп миллионлы халык яшәгән мегаполисны дөньяның ике кыйтгасына — Ауропа һәм Азиягә бүлеп куйган Босфор дулкыннарының талгын тирбәнеше, соклану белән тулы күз карашларыбызны иркәләп, ерак гасырларга — солтаннар идарә иткән шанлы империя дәверләренә алып китә. Кайчандыр Византия дәүләтенең башкаласы булган Константинополь-Истанбул гүзәл табигате белән «шәһәр безне ничек кабул итәр» икән, дип борчылган җаннарыбызны да тынычландырды. Хәер, борчылырга урын да булмады кебек: филология фәннәре кандидаты, Окан университеты доценты Илсөяр Рәмиева эшлекле сәфәребезне оештыруда, Төркия фондлары, китапханәләре белән бәйләнешкә керү җәһәтеннән зур ярдәм күрсәтте. Беренче эш итеп, Илсөяр ханым, ТР Мәдәният министрлыгына мине чакырып рәсми кәгазь юллаган «Аяз Таһир Төркестан Идел-Урал» фонды җитәкчесе Түләй Дуран белән очрашуны оештырды. Татар әдәбияты классигы Гаяз Исхакыйның Төркиядә сакланган шәхси әйберләрен күптән түгел генә Татарстанга алып килгән Түләй ханымның Яуширмә авылы һәм Казан каласыннан алып киткән тәэсирләре әле суынып та өлгермәгән иде. Бөек ватандашыбызның мирасын саклауны үзенең изге бурычы итеп санаган җитәкче белән әңгәмә бик тә җылы узды. Ул Гаяз Исхакыйның яңа томнарын төзерлек материалларның әле байтак булуы, язучы мирасын Ватанына кайтаруда мөмкин кадәр ярдәм итәчәге турында сөйләде. Очрашуда Түләй Дуранның остазы, тарихчы галим Эртугрул бәй Зекаи Үкте дә бар иде. Ул фонд исеменнән «Мин дә бер төрекмен» исемле саллы китабын безгә һәдия итте. Тагын бер очрашу Төрки дөньяны өйрәнү вакыфында булды. Анда без әдәбиятчы галим, профессор Мәтин Көсе белән очраштык. Ул сентябрь башында Казан федераль университеты тарафыннан уздырылган Төрки дөнья Халыкара иҗтимагый фәннәрнең XII конгрессында катнашкан; Казан Кремле, Изге Болгар, Зөя, Чабаксарда экскурсия-сәяхәтләрдә булган. Бу хакта «Төрки дөнья. Тарих» дигән айлык мәдәни журналда Татарстаныбызның истәлекле урыннарының фотолары белән бизәлгән күләмле мәкаләсен дә бастырып өлгергән. Шунысы да игътибарга лаек: журналның титул битендә Казан университетының төп бинасы рәсеме урын алган. Фондта төрки дөньяның төрле почмакларыннан килгән кунакларның милли символик бүләкләреннән оештырылган музей һәм китапханә дә бар. Без дә фондка Шәрык әдәбиятлары белгече, профессор Р.Ганиеваның әле яңа гына дөнья күргән «Урта гасыр һәм яңа заман төрки әдәбиятларында Шәрык Ренессансы традицияләре» монографиясен бүләк иттек. Мәтин бәй безгә Габдулла Тукай иҗатына кагылышлы материалларны кайсы китапханәләрдән табу мөмкинлеге һәм каталоглар системасы турында тәфсилле мәгълүмат та бирде.

Төрек редакцияләренең Габдулла

Тукайга кагылышлы ниндирәк мәгълүматлар бирүе хакында XX йөз башы татар вакытлы матбугаты битләрендә дә байтак фикерләр әйтелә. «Вакыт», «Кояш», «Шура», «Сибирия» кебек басмалардагы астөшермәләр буенча язмаларның әчтәлеген ачыклау максатында, Баязид китапханәсенең сирәк әсәрләр һәм кулъязмалар бүлегендә дә берничә көн булдык. Без биредә «Төрек сүзе», «Ислам мәҗмугасы», «Ислам дөньясы», «Мәтин», «Өч газета», «Төрек йорты», «Төрек культуру», «Тасвире әфкяр» кебек Төркиядә чыккан газета-журналларның 1913-1914 еллардагы апрель саннарын өйрәндек һәм аларда Тукай турында берничә мәкаләгә дә тап булдык. «Төрек сүзе», «Төрек йорты» басмаларында шагыйрьнең фоторәсемнәренә зур урын бирелүгә игътибар иттек. Тукаебыз турындагы бу мәкаләләрне киләчәктә, тәрҗемә итеп, татар укучысына да тәкъдим итәрбез, дигән ният бар.

Истанбул университетының әдәбият факультеты һәм Мәркәз китапханәләре, ISAM — Ислам мәдәниятен тикшерү үзәге китапханәсе латин хәрефләрендә дөнья күргән Тукай турындагы фәнни журналларга, конференцияләр җыентыкларына, диссертация һәм китапларга бик бай. «Милли фольклор», «Казан», «Төрки дөньяның тел һәм әдәбият журналы», «Кардәш әдәбиятлар», «Төрек культуру», «Билиг», «Төркият мәҗмугасы», «Төркиләр» һ.б. журналларда Рәшит Рәхмәти Арат, Гали Акыш, Әхмәт Тимер, Төрекмән Фикрәт, Надир Дәүләт, Наилә Бинарк, Зөлфикар Хәмзә, Явыз Акпынар, Гүлһан Атнур, Мостафа Өнәр, Узун Морат, Рәмзия Яруллина һ.б. әдәбиятчыларның татар шагыйре иҗатын яктырткан хезмәтләренә тап булдык. Мостафа Акбашның Габдулла Тукай әсәрләренең тел үзенчәлекләре турындагы докторлык диссертациясенең (1996) электрон вариантын Казанга алып кайту — сәфәребезнең бер уңышы булды. Тукайның күләмле шигърияте һәм аның турындагы хезмәте 1994 елда галимә Фатма Өзкан тәрҗемәсендә төрек укучысына тәкъдим ителгән иде. Инде 2006 елда ТЮРКСОЙ оешмасы «Габдулла Тукай. Сайланма әсәрләр» китабын нәшер итә. Китапта татар шагыйренең Фатма Өзкан тарафыннан тәрҗемә ителгән шигырьләре һәм Асия Рәхимова тәрҗемәсендәге берничә публицистик әсәре һәм дә «Исемдә калганнар» автобиографик повестеннан өзекләр урын алган. Ә 2014 елда Г.Тукайның берничә әсәре һәм аның традицияләрен дәвам итүче татар әдипләренең Тукайга багышланган шигырьләре латин графикасы белән татар һәм төрек телләрендә китап булып дөнья күрә. Төзүчеләре — Бирсел Оруч Аслан һәм Йусуф Өзчобан, аны әзерләүдә Г.Ибраһимов исемендәге ТӘһСИ хезмәткәре Фәридә Таһирова да катнашкан.

Китапханәләрдә эшләгәндә Тукай иҗатына кагылышлы фәнни хезмәтләргә генә түгел, төрек язучыларының Тукай образын үзәккә куйган әдәби әсәрләренә дә тап булдык. Наилә Бинаркның Тукай турында балалар өчен язылган «Тукай хәяте» пьесасын табу әлегә мөмкин булмады. Әлегә пьеса турында рецензиябәяләмәләргә дә юлыкмадык. Шагыйребез турындагы әсәр шулай тарихтан төшеп калырмы, әллә инде аның әлегә татар укучысына тәкъдим ителергә вакыты гына җитмәгәнме — билгесез. Төрек шигырьләрендә Тукаебызның үлемсез иҗаты еш кына апрель яңгыры белән чагыштырыла. Чыннан да, Сания Ишыкай «Апрель яңгыры»нда язганча: «Татар шагыйренең шигърияте ләйсән яңгыр кебек саф, төрки дөньяда мәхәббәт яулаган милли «әдәби символ, баш таҗдыр».

Бүген Төркиядә Тукай иҗатына игътибар зур: аның әсәрләрен тәрҗемәдә укыйлар, төрек әдәбияты белән чагыштырып өйрәнәләр, диссертацияләр язалар, төрки халыкларның уртак бөек шагыйре дип, укучыга тәкъдим итәләр. ■

ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

Сәхифәне филология фәннәре докторы, профессор ЗӨФӘР РӘМИЕВ алып бара.

Габдулла Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры. Тукай образы һәм иҗаты театрның ике спектаклендә чагылыш тапты: «Печән базары» һәм «Зәйтүнәкәй».

«ПЕЧӘН БАЗАРЫ» (2006; режиссёры — Ренат Әюпов) алдан язылган текстка (пьесага, сценарийга) нигезләнеп тудырылмаган. Аның башлангычы — аерым актёрлар тарафыннан Т.ның «Шүрәле», «Су анасы», «Кәҗә белән сарык» исемле мәгълүм әсәрләре сюжетларына таянып ясалган этюдларда (күренешләрдә). Эзләнүләр барышында «Печән базары...» поэмасындагы вакыйгаларны һәм образларны чагылдыру мәсьәләсе дә килеп туа. Булачак спектакльнең финалын үтәячәк бу мөһим этюдка үзеннән-үзе текст сорала башлый. Бераздан, эзләнә-эзләнә, бөтен бер спектакльнең тулы эчтәлеге күз алдына килеп баса, сценарий Т.ның шигырьләре, аның турындагы истәлекләр нигезендә формалаша. Шагыйрьнең үлеме исә аның нәселе бетү белән тәмамлана,

«Печән базары» спектакленнән бер күренеш

әмма ул безгә — киләчәк буыннарга бәяләп бетергесез олы мирас та калдыра. Спектакль II Халыкара театр фестивалендә (Бишкек, 2006) «Иң шәп спектакль» номинациясендә I нче урынны алды, театр бу спектакль белән Төрки халыкларның IV Халыкара театр фестивалендә (Конья, 2011) катнашты.

«ЗӘЙТҮНӘКӘЙ» (Рабит Батулла әсәре, режиссёры — Ренат Әюпов, рәссамы Булат Гыйльванов) спектакле исә (2011) Т.ның Зәйтүнә Мәүлүдова белән фаҗигале мәхәббәте турында. Вакыйгалар бара торган урын бик гади. Буш сәхнә, бераздан уртада ап-ак пәрдәле ак тәрәзә барлыкка килә. Бу тәрәзә Т. тормышының соңгы, үлеме алдындагы фаҗигале якты мизгелләре өмет нурын символлаштыра. Әлеге бизәлешкә Э.Галимова иҗат иткән минор, шул ук вакытта тон ягыннан дәртле музыка да бик тә ярашлы яңгырый. Төп геройның рухи халәтен яхшырак күрсәтү өчен, Р.Батулла пьесадагы вакыйгаларны 1913 елның язына, берничә айга сыйдырган. Спектакльдә сүз Зәйтүнәнең Тукайга булган мәхәббәте турында гына бара. Вакыйга ике яшь йөрәкнең бер-берсенә булган самими, ләкин кайнар, дәртле хисләре турындагы кыска гына тарихтан гыйбарәт. Т. оялчан, тыйнак, ул Зәйтүнә белән очрашудан уттан курыккан кебек курка. Әле генә бәхетле, шат күңелле, шул ук мизгелдә аны моңсулык та биләп ала. Т., борчылып, дусты Фатих Әмирханга мөрәҗәгать итә: «Дустым, әйт әле, чир баскан бәндәнең сау-сәламәт, чибәр туташны сөяргә хакы бармы? Шул фәрештәгә өйләнүем зур гөнаһ булыр иде». Актёр шагыйрь күңелендә барган тартышны күрсәтә. Аның акылы күңелен биләп алган хисләре белән көрәшә. Шул ук вакытта Т. (Р.Галимуллин) әче телле шагыйрь дә булып кала. Әгәр дә кемдер (бу очракта, Сираев) аның шәхесенә, тормышка карашына, фикер хөрлегенә кагыла икән, ул аңа җавап та бирә. Зәйтүнә — үз-үзен аямыйча ярата ала торган кыз. Яраткан кешесе өчен ул гомерен бирергә дә әзер. Актриса (А.Фәйзуллина) спектакльдә романтик героиня образын тудыра. Тормышта Зәйтүнә Т. белән бер тапкыр гына очрашкан. Әмма драматург, Зәйтүнәнең ирләргә хас нык холкын күрсәтү өчен, аларны тагын бер тапкыр очраштыра. Монысы инде хастаханәдә. Пьеса Т.ның Зәйтүнәне палатадан озатып, аның киткәнен тәрәзәдән карап калуы белән тәмамлана. Барысы да хәл ителгән, бернәрсәне дә үзгәртеп булмый. Тукай белән хатирәләр генә кала: *«Әй мөкатдәс моңлы сазым,/ Уйнадың син ник бик аз?// Без китәбез, сез каласыз, / Аерылабыз, ахрысы»*. «Тантана» театраль фестивалендә (2012) спектакльдә Т. ролен башкарган Р.Галимуллин «Дебют» номинациясендә театраль премиягә лаек була.

Театр 2014 елның 22 декабрендә Т.Миңнуллинның «Әйт әле, күбәләк» спектакленең премьерасын тәкъдим итә. Әлеге спектакльдә бәләкәй Апушның авылдан Казанга китеп, икенче гаиләгә тәрбиягә бирелүе алдыннан булган хис-кичерешләре, төрле персонажлар — Күбәләк, Су анасы, Шүрәле, Кәҗә һәм Сарык, Сандугач һәм Каракош белән тылсымлы очрашу вакыйгасы тасвирлана.

Халисә Уразова

Әдәбият

И.Илялова. Тукай и театр. // Казан. — 2006. — №7. С.108-111; Султанова Р.Р. Возвращение образа. Сценография спектаклей о Тукай в татарском театре. Там же. — С.112-114; Илялова И. Кариев театрына — 25 ел. // Сәхнә. — 2012. — №11. — Б.6-9; Р.Сабирова. Сәхнәдә туган пьеса — «Печән базары» // Ялкын. — 2006. №4. — Б.14-15;. Фәрхетдинова Ч.. Зәйтүнәкәй мәхәббәте // Мәдәни җомга. — 2012. — 4 май.

«КЫЙССАИ ЙОСЫФНЫ»
НӘШЕР ИТҮ КЫЙССАСЫ

28 гыйнвар, 1969 ел.
Татарстан Язучылар союзының идарә утырышы

«Кыйссаи Йосыф» китабының тышлыгы. 1983 ел

Катнашлар:

Ибраһим Гази, Гариф Ахунов, Афзал Шамов, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Рафаэль Мостафин, Хатыйп Госман, Азат Әхмәдуллин, Илдар Юзеев, Шамил Абилов, Фазыл Фәсиев, Гомәр Бәширов, Зәки Нури, Ләбибә Ихсанова, Риза Ишморат, Равил Фәйзуллин.

Көн тәртибендә: 1) Борынгы татар әдәбияты үрнәге — «Кыйссаи Йосыф» әсәрен бастырып чыгаруга әзерлек мәсьәләсе.

2) Язучылар Союзының һәм «Казан утлары» журналы редакциясенең эш планннарын тикшерү.

3) Гаризалар.

4) Г.Тукай премиясенә кандидатлар тәкъдим итү.

Ибраһим Гази «Кыйссаи Йосыф» кулъязмалары өстендә озак еллар эшләгән Җ.Алмаз хатын *(Бу хатны табасы иде — **Л.Л.**)* укый.

Хатыйп Госман. Бу мәсәләне кую ничаклы урынлыдыр... Белмим. Эш болай тора: 1960 елда Казан университеты Җәвад Алмазга бу борынгы текст буенча эшләргә бурыч куйган иде. Аванс 12000 (иске акчада). Җыенысы аңа түләнгән акча 30000 сумга җитте.

Аннан ул китеп барды. Тиздән «Кыйссаи Йосыф» кыйссасының 750 еллык юбилее була. Шуннан соң бу эш филология кандидаты Фазыл Фәсиевкә, тапшырылды, 1966 елда институтның эш планына кертелде. Менә хәзер тагын Җәвад Алмаз мәсьәләсе килеп чыкты.

Афзал Шамов. Договор кайчан төзелгән иде?

Хатыйп Госман. 1960 елда.

Азат Әхмәдуллин. Бу эшне дәүләт планына кертү югары оешмалар белән киңәшеп эшләнде. Текст белән эшләүне җиңеләйтү өчен машинка булдырылды. Бу эшнең барышы үткән ел (1968) җәй тикшерелде. Эш әйбәт бара, төгәлләнүгә таба бара... Без бик фәнни итеп чыгарырга ниятләнәбез. Бәлки ул популяр булмас?!

Фазыл Фәсиев. Кирәк булса, материалларны күрсәтә алам. Җәвад Алмазны хөрмәт итәм. «Кыйссаи Йосыф»ны ул башлап җибәрде. Мин бу әсәр белән 1966 елдан эшли башладым. Аның текстологиясен, транскрипциясен эшләдем. Машинка ясаттык. Бу эшне җиңеләйтә. Мин Утыз Имәни вариантын нигез итеп алдым. Башка кулъязмалар белән чыгыштырып барабыз. Аларның вариантларның бирәбез. Казан университетындагы 30 лап кулъязма күздән кичерелде. 450 битле китап булыр дибез...

Гомәр Бәширов. Без Җәвад Алмазның 15 еллап эшләвен беләбез. Менә институт кешеләре дә эшли икән. Ә сез аның *(Ж.Алмазның — **Л.Л.**)* вариантлары белән танышмыйча, үзегезнекен генә чыгарсагыз, бу юл фәнни булыр микән?

Афзаал Шамов. «Кыйссаи Йосыф» турында күптәннән сөйләшәбез инде. Бу үзе тарихка әйләнеп бара. Байтактан бирле артыннан йөрибез. Алмазны кайтарып эшләтү мәсьәләсе күтәрелсен иде. Җәвад аның русчага подстрочнигын (сүзгә сүз тәрҗемә) ясады. Аның расходларын Язучылар Союзы күтәрде. Минемчә, мәсьәлә бик урынлы һәм кирәкле. Юбилей якынлаша. Әсәрне чыгарырга кирәк. Бүтән халыклар чыгара. Җәвад Алмазны чакырырга кирәк.

Ибраһим Гази. (Җәвад Алмаз хатыннан «Кыйссаи Йосыф» әсәренә кагылышлы урыннарны укып күрсәтә).

Шамил Абилов. 1966 елның кышында Нәвои юбилее көннәрендә мин Ташкентка барырга, Җәвадны күрергә тиеш идем. Ничек сөйләшергә дип Казаннан киңәшләшеп киттем. Җәвад Алмаз да текстны реконструкцияләү ягында түгел. Эш шунда тора: 48 нөхсә каралган, шуның 17 нөсхәсе нигез итеп алына. Эш эшләнеп беткән... Ул 230 битләр чамасы сүзлек төзегән. Фонетик-морфологик анализ ясаган. Русчага тәрҗемәсе бар. Ни өчен хезмәтне нәшриятка бирми? Чөнки ул әйбер договордагыдан күпкә үскән.

Ә болай низаглану — тар күңеллелек. Язучылар Союзының бу эшен мин хуплыйм.

Сибгат Хәким. Бүтән милләт галимнәре безнең бүгенге сөйләшүне тыңлап торса, көләр иде. Җәвад Алмаз фидакяр эш эшли. Монысы тәгаен. Нindидер 60 яки 300 сум өчен талаша, судлаша башласак, бернинди дә эш чыкмас. Ж.Алмаз «Җөмҗөмә солтан»ны эшләде. Ул да басылып чыкмады... Безгә ваклыклардан өстен булырга кирәк.

Хәсән Туфан. «Җөмҗөмә солтан» югалды. Кайда ул? «Дәрдемәнд» китабын алыгыз. Һәрбер юлда хата. Кайда була ул вакытта галимнәр?

Мирсәй Әмир. Текстның булмавы, бу эшнең сузылуына бераз Ж.Алмаз да гаепле булса кирәк.

Риза Ишморат. Минемчә, монда бернәрсә ачык, без Җәвад Алмазны читләтеп үтә алмыйбыз. Чакыртырга кирәк. Тикшерергә кирәк. 750 елллыкны Ж.Алмаз текстынннан тыш уздыру мөмкин түгел...

Хатыйп Госман. Фәсиевнекен эш-

кәртергә кирәк. Алмаз кулъязмасын да алу ягын карарга кирәк…

Рафаэль Мостафин. Ике тәкъдим — Җәвад Алмазны Язучылар Союзы хисабына чакыртырыга. Текстлар белән танышу өчен махсус комисссия төзергә.

Зәки Нури. Язучылар Союзы бу эшнең һаман да алга бармавына борчыла. Югары оешмалардан эшне тизләтүгә ярдәм итүләрен сорарга.

Ибраһим Гази. Фазыл, Сезнең текстта ничә юл?

Фазыл Фәсиев. 1270 строфа, янә 4, килеп чыга 5080 юл.

Гариф Ахунов. Алмазны чакыртырга кирәк. Килеп, эшен күрсәтеп, хисап бирсен.

Карар кылынды: «Кыйссаи Йосыф» әсәре турында озак еллар тикшерү алып барган Җ.Алмазны чакыртып, хезмәте белән танышу чарасын күрергә; Җ.Алмаз һәм Ф.Фәсиев эшләгән текстларны объектив бәяли алырлык комиссия төзүне тиешле оешмалардан сорарга. Ике текстның икесе дә әһәмиятле итеп табылган хәлдә, бастыру юлын эзләргә.

Матбугат йорты бинасына 1969 елда Татарстан Язучылар союзы урнашкан иде

Икенче көн тәртибе: «Казан утлары» журналының икенче кварталга эш планы. Журналның җаваплы секретаре Ләбибә Ихсанова план белән таныштыра.

Язучылар Союзының гомуми еллык һәм 1 квартал планнарын раслау.

Гомумпланга кайбер тәкъдимнәр:

— «Муса Җәлил» теплоходына Язучылар союзыннан вәкил җибәрергә.

— Ленин һәм Татарстан юбилейлары алдыннан әдәбият мәсьәләләре хакында докладлар, чыгышлар ясау өчен район җирләренә язучыларны чыгарырга.

Өченче көн тәртибе. Гаризалар.

Дүртенче көн тәртибе: Г.Тукай исемендәге республика премиясенә кандидатура тәкъдим итү.

Бертавыштан түбәндәге карар чыгарылды: Г.Тукай исемендәге республика премиясенә Ибраһим Газиның «Онытылмас еллар» әсәрен тәкъдим итәргә.

Беркетмәне теркәүче —
идарә әгъзасы **Равил Фәйзуллин.**
29 гыйнвар, 1969 ел.

Равил Фәйзуллин.
60 нчы еллар

«Бер бәйләм беркетмә» сәхифәсен әзерләгәндә, без, моннан 46 ел элек әлеге беркетмәне теркәп куючыга мөрәҗәгать иттек. Күренекле шагыйребез Равил ага Фәйзуллин, шул чакларны искә алып, менә ниләр сөйләде:

– Ярты гасыр чамасы элек язып-теркәп куйган бу беркетмәне укыгач, моңсу һәм беркадәр әрнүле тойгылар да уянып куйды. Моңсулыгы аңлашыла: бик күп еллар үткән, гомер язынннан бик нык еракла-шылган. Ә әрнүле дигәне... Монысына бераз тукталып, булдыра алганча, ул чактагы хәлләрне шәрехләп үтик.

1969 елның башында үткән бу утырышта бик мөһим мәсьәлә күтәрелгән: «Кыйссаи Йосыф»ны (аны «Йосыф кыйссасы», «Йосыф китабы» дип тә йөрткәннәр) татар тарихында, дөньяда раслап калдыру. Мәгълум нәрсә: әсәрнең төп сюжеты безгә генә карамый, ул дистәләгән халыклар өчен уртак; бигрәк тә яһүди һәм төрки халыклар өчен. Әмма шунысы бар: галимнәр раславынча, бу бөек әсәрнең кульъязма вариантлары, нигездә, татарлар яшәгән төбәкләрдә табылган. Алар бик күп. Без студент чакта ул нөсхәләрнең санын 170ләп дип әйтәләр иде. Ерак әби-бабаларыбыз гасырлар буе «Кыйссаи Йосыф»ны ишетеп, тыңлап, укып үскән. Димәк, бу әсәрне безнеке дип, күкрәк киереп әйтергә нигезебез бар. Хәер, шикләнер сәбәп тә юк: XIII гасыр башында конкрет шәхес — Кол Гали тарафыннан борынгы Болгар җирендә язылган бит ул! 1917 елга кадәр аның Казан басмаханәләрендә генә дә сиксәннән артык тапкыр басылып чыгуы да күп нәрсәне аңлата. Шулай да... Уртак мал тирәсендә дәгъва-гауга булучан, диләр. «Кыйссаи Йосыф» мисалына да кагыла бу нәрсә. Революциядән соң шактый зур мөстәкыйльлек, үзбаш алып, СССР составында берничә ел эчендә, һәм матди, һәм рухи үсешкә ирешә башлаган, союздаш саналган төрки республикаларда, шулай ук күршебез Башкортстанда да, үткән гасырның 50-60 елларында «Кыйссаи Йосыф» әсәренә игътибар көчәя, «ул әсәр — безнеке!» диючеләр ишәя. Үзләрендә табылган берничә данә кульъязмаларга таянып, үз телләренә якынайтып чыгарылган яңа басмалар пәйда була. Бу очракта безгә нишләргә иде соң? Бу әсәр турында яңа буыннарга хаклыкны ирештерергә, киң җәмәгатьчелек алдында тарихи дөреслекне янәдән расларга кирәк иде! Ничек итеп? Әлбәттә, беренче чиратта, үзебездә, әсәрнең үзенә лаек рәвешле, яхшы полиграфик ысул белән, берничә телдә, фәнни нигезләп яңа шәп басмасын чыгарырга! Өстәвенә, билгеләнгән юбилей елы якынлаша...

Беркетмәне җентекләп укыган кеше иң әүвәл шуңа игътибар итәр: «Кыйссаи Йосыф» язмышы турында әдәбиятыбызның нинди зур вәкилләре үзара фикерләшә бу җыелышта! Күбесе — хәзерге заман татар әдәбиятының алтын фондын тудырган әдипләр. (Ул чорда язучылар оешмасының абруе ифрат зур, гомуммиллә т

дәрәҗәсендәге күп кенә мәсьәләләр язучылар белән киңәшләшеп хәл ителә иде. Бу җыелыш та шуның бер мисалы). Төп сүз сөреше шуннан гыйбарәт: чыгачак юбилей басмасының әзерлек дәрәҗәсе ничек? Төзүче-авторлары кемнәр? Шулай килеп чыккан: галим Җәвад Алмаз, дистә еллар буе өйрәнеп, әсәрнең бер вариантын әзерләгән, икенче вариантны Тел, әдәбият һәм тарих институтында Фазыл Фәсиев әзерләп бетереп килә... Кайсын нигез итеп алырга, яки кайсы вариантны сайларга? Укып күргәнегезчә, җыелыш шундый карарга килә: Җ. Алмазны Ташкенттан чакыртырга, әзерләнгән хәзмәтләрне объектив бәяли алырлык комиссия төзергә. Кыскасы, тупланган мирасны таркатмаска, җуймаска, йә ике вариантны килештереп бер нөсхә ясарга, йә икесен дә чыгарырга.

Әйе, яхшы карар. Әмма, ни кызганыч, ул үтәлмәде шикелле. Шулай да, иң мөһиме, китап чыкты — 1983 елны Фазыл Фәсхиев эшләгән вариант нигезендә татар-төрки телендә (русчага сүзгә-сүз тәрҗемә белән) «Кыйссаи Йосыф» дөнья күрде. Зур, матур китап булып чыкты ул: күләме 60 табак чамасы, тиражы да зур — 10 мең данә. (Казанда аңарчы андый затлы китаплардан икене генә хәтерлим мин: 50 нче елларда чыккан «Батырлар китабы» һәм «Татар поэзиясе антологиясе»). Китап, «Кыйссаи Йосыф» әсәренең 800 еллык юбилее алдыннан нәшер ителеп, татар, гомумән, төрки дөньяда вакыйга буларак кабул ителде. Юбилей тантанасы Мәскәүнең иң зур залларының берсе — мәшһүр Колонналы Залда шаулап үтте. Бу тантанада Миркасыйм Госманов (басманың фәнни редакторы), Рәис Даутов (гамәли редактор), Гарәф Шәрәфетдинов (нәшрият директоры) һәм башкалар белән «Мәскәү гулять» итеп йөрүләр һаман истә... Шундый бәйрәми халәттә дә еш кына бөтен гомерен диярлек «Кыйссаи Йосыф»ка багышлаган галим Җәвад Алмаз да искә төшеп-төшеп куйды ул көннәрдә...

Җәвад Алмаз турында берничә сүз. Иң әүвәл энциклопедик белешмә. «Алмазов Җәвад Диндар улы (1916-1979), әдәбият галиме, археограф. 1947-1955 елларда Үзбәкстанда урта һәм югары уку йортларында укыта. 1958-1961 елларда Казан университетында. 1961 елдан Ташкентта яшәп иҗат итә. Хезмәтләре урта гасырлар татар әдәбияты тарихына карый («Татар энциклопедиясе сүзлеге». 33 б.) Бу кешене мин үзем дә беркадәр күреп-белеп калдым. Заманында ул безгә, студентларга, борынгы татар әдәбиятыннан лекцияләр укыды. Уртача буйлы, җитез хәрәкәтле ир-ат булып хәтердә калган. Укытучы буларак, таләпчән; безнең һәркайсыбыз белән «Сез» дип сөйләшә иде. Бик өлкән кебек күренә иде ул безгә. Ә ул вакытта аңа нибары 44 яшь булган. Лекцияләре кызык, мавыктыргыч сыман иде, лектор буларак аудиторияне тыңлата алды. Дөрес, ул чакта лекцияләрне мәгънәви яктан бәяләр дәрәҗәдә түгел идем әле. Ул еллардан исән калган лекция дәфтәрендәге язмалардан чыгып, хәтергә таянып шулай дип әйтәм. Аның университеттан китүе турында төрле сүзләр йөрде. Холкы-гамәле, укыту ысулы беләнме, әллә шәрыкъчарак яшәве беләнме ул кемнәргәдер ошамады. Һәрхәлдә, ул Казанга «төс» булмады, безнең җирлеккә «ябыша» алмады. Әйткәнемчә, мин аны аз беләм. Үткән гасырның 60 нчы елларында аның белән аралашкан кешеләр, әйтик, аксакал галим Мирфатих Зәкиев һәм исән кайбер өлкәннәр күбрәк беләләрдер. Ярый, шәхеснең язмышы бер хәл (бу дөньяда ни генә булмый!), ә менә ул бөртекләп җыйган мирас — борынгы татар әдәбияты ядкарьләре хәзер исән микән? Кемнәрнеңдер кулларында ятамы әллә инде югалып гаип булганнармы?

Текстны басмага
***Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

ХӘСИТӘ

(ТР Милли музее фондларыннан)

Татар хатын-кызларына хас булган бизәнгеч — хәситәне: *«Киң тасмага өске буйдан еш-еш итеп бер яки берничә чылбыр яки дүртпочмаклы җиз тәңкәләр рәте тегелгән, ә аннары калган бөтен өслеге җизләр, акчалар, тәңкәләр, төймәләр һәм бизәнгеч хуҗасы өчен истәлекле башка төр матур әйберләр белән тегеп тутырылган»* — дип тасфирлый Н.И.Воробьев.

Хатын-кызның хәситәгә беркетелгән тәңкәләренә, төймәләренә карап матди хәлен белергә мөмкин булган. Бу аның иренең кереме, байлыгы хакында күрсәтеп торган. Еш кына хәситәнең түбән читендә махсус кесәләрне дә күрергә мөмкин. Аларга нәни Коръән һәм бөти савытлары салынган.

***Руфия Мөхетдинова** әзерләде.* ■

ИЛ КЫЗЫ

Рухия Ахунҗанова

«Таһир-Зөһрә» (Ф.Бурнаш). Зөһрә ролендә – Фатыйма Ильская

Соңгы лекция бетүгә, гадәттәгечә, чыштыр-чыштыр килеп, дәфтәр-каләмнәрне дипломатларга тутыра башладык. Шулвакыт параллель группадан Гөлира Сәйфетдинованың тавышы 20 нче аудитория һавасын ярды:
– Кызлар! Кайсыгыз, миңа ияреп, артистка янына бара?!
«Артистка» сүзен ишетүгә:
– Мин, мин! – дип чәчрәп чыктым.

Юл буе мин Гөлирага бер-бер артлы сорауларымны яудырдым. Ул, бичара, ирексездән, сорау яңгыры астында барды.

Мин РСФСРның халык артисткасы Фатыйма Ильская фатирының бусагасын, көтмәгәндә-уйламаганда, шулай атлап кердем. Ул безнең икебезне дә балкып каршылады. Аның бөтен йөзеннән, бераздан абайлап алдым, шомырттай кара күзләреннән нурлы балкыш бөркелә иде. Мин аның нур чәчеп торган мөлаемлыгын күреп, таң калдым. Якты, мәгънәле карашына сокландым.

Әңгәмә вакытында, аның бәрхет тавышын ишетеп, үземне театрда спектакль карап утыргандай хис иттем. Чөнки тугызынчы дистәне ваклый башлаган артистканың гадәти сөйләме дә югары дәрәҗәдә культуралы иде. Менә дигән сөйләмгә ия булуы күренеп тора! Ул сөйләгәндә, аның гап-гади фатиры яхшы акустикалы бинаны хәтерләтеп куя. Тавышы яңгырап ишетелә. Кайтавазлы тавыш. Күңелгә рәхәт, йомшакягымлы... Андый тембрлы һәм диапазонлы тавыш сирәк кешедә очрый.

Минем каршымда татар театрының тере легендасы, әтисе Салихтан — ике айлык вакытта, әнисе Хиҗәстәдән — ике яшьтә ятим калып, Галимҗан бабасы һәм Гобәйдә әбисе тәрбиясендә, ләкин авыр тормышта, эшкә җигелеп үскән, 13 яшендә актёрлык эшчәнлеген башлап җибәргән Оренбург кызы Фатыйма Ильская үзе утыра иде. Шулвакытта исем китте: псевдонимын да дөрес сайлаганнар бит! Үсмер кыз вакытыннан алып, 65 ел гомерен һәм шәхси тормышын театрга багышлап, халкына һәм иленә тугры хезмәт итеп, ул үзенең чынлыкта Ил кызы булуын күрсәткән. Татар театр сәнгатенең эстафета йөзеге аңа күчүе дә күп нәрсә турында сөйли!

Хисчән, күтәренке рухы аның тышкы гүзәллегенә бик тә туры килгән. Атаклы Зөһрә (Ф.Бурнаш, «Таһир-Зөһрә»), Джульетта (У.Шекспир, «Ромео-Джульетта») рольләрендә нәкъ шундый шәхес кенә уйнарга тиеш булгандыр да. Лирик-романтик пландагы актриса сәхнәдә дә, көнкүрештә дә үзе булып калган. Ул миңа тормышта да артистлыгын дәвам иткән кебек тоелды. Мәсәлән, Фәтхи Бурнашка карата күрсәткән көйсезлекләре (капризлары) үзе үк кечкенә «уен»ны хәтерләткән бит.

Фатыйма ханым ялгыз яши иде. Аңа әңгәмәдәшнең бик тансык булуын мин шундук аңлап алдым. Килгәләп йөрергә рөхсәт соравыма шатланып ризалашты. Дөрес, ул телефон аша да танышлары белән аралашып-сөйләшеп яши икән. Алар: «Аһ, тавышың ла, тавышың!» — дип, соклануларын белдерәләр икән. Шул сүзләр карт артистканың кәефен җибәрә дә икән инде.

— Матур тавышымның кирәге шулкадәр генә хәзер! Менә аякларым сәламәт булсын иде! Дөнья йөзен күрә алмыйча, өйдә ябылуда ятам, — ди ул, кул таягына ымлап. Ләкин бу күңелсезләнүе һич тә озакка сузылмый. Аның һәр сүзен игътибар белән тыңлавымны, авызыннан чыгуын көтеп утыруымны күреп-белеп тора. Шуңа күрә «Ширкәт», «Сәйяр» труппаларында ничек эшләвен кыскача гына сөйли. Беренче тапкыр Казан тамашачысы алдына Фатыйма Хуҗасәетова 14 яшендә «Сәйяр» артисткасы буларак

«Тау чәчәге» (Х.Уразиков). Вера Минкина, Фатыйма Ильская. 1957 ел

чыгып баса. Габдулла Кариев кушуы буенча, Фатих Бәкер Оренбургка хат язып, танышы Фатыйманы эшкә чакыра. Труппа җитәкчесенең тәкъдиме белән, сәхнә өчен «Ильская» псевдонимын сайлыйлар. (Фатих Бәкер — озак еллар Ташкентта яшәгән галим, профессор.) Шул чорлар турында: «Юньле-башлы белем дә ала алмадым», — дип, зарланып искә ала Фатыйма апа. Үзенең сәхнә кумиры Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская булуын әйтә. «Ул да ялгыз яшәде. Берьялгызы үлеп тә китте», — ди ул, уфтанып. «Үзбәктә ачылган Татар театрының баш режиссёры Бакиров иде, мин дә шул труппада уйнадым», — ди. Гражданнар сугышы чорында фронт театрларында да уйнаган ул. Ил тарихы шул рәвешле аерым кешеләрнең тарихына да теркәлеп барган...

Без, пединститутның ике студенткасы, бик еш булмаса да, артистканың хәлен белергә баргалыйбыз. Аена бер тапкыр «Горький исемендәге культура һәм ял паркы» тукталышындагы гастрономнан персональ пенсионерлар өчен әзерләп куелган махсус паек алып кайтып бирәбез. Кем әйтмешли, аннары идән-сәкесен юабыз, тузаннарын сөртәбез. Аның сөйләгәнен тыңлыйбыз, үзебез дә аңа кушылып китәбез. Шушы эшләрне тәмамлагач, кайту ягына җыена башлыйбыз. Туй кунакларын кыстаган кебек, паек ризыклары белән Фатыйма ханым безне сыйларга әзерләнә. «Аштан өстен булмагыз», — ди. Аның күңелен күрер өчен, матур итеп табын көйлибез. Дегустаторлар кебек, тәм-томыннан авыз итәбез дә, табынны җыештырып, хуҗабикә белән саубуллашабыз...

Татар-рус бүлегенең төрле группаларында укыганлыктан, Фатыйма ханым янына Гөлира аерым, мин аерым йөри башладык. Мондый бүленеш минем өчен берникадәр файдалы да булды. Чөнки үземне кызыксындырган темаларга сөйләшү мөмкинлеге артты. Горький урамындагы 17 нче йортта мәшһүр шәхесләр яшәгән. Муса Җәлил дә фронтка шушыннан киткән. Гаилә дуслары булган Җәлиловлар турында артистка рәсми төстәрәк сөйләде. Җәлилне «зур талант» дип атады. Ул, ишле фоторәсемнәр арасыннан аралап,

бергәләп төшкән рәсемнәрен күрсәтте. Соңыннан, елмаеп: «Муса бик мут иде», — диде.

Фоторәсемнәр арасында котлау открыткалары да бар. Берсе шагыйрь Хәсән Туфан кулы белән язылган:

Сез — беренче гөле сәхнәбезнең,
Сезнең иҗат әле дә чәчкәле,
Даһи халык, бөек халыкның сез
Үзе кебек һаман яшь әле!

Туган илебез кебек талантлы сез,
Халык кебек җитез, чая сез;
Эшегезгә лаек сезнең исем:
Чын мәгънәдә Ильская сез!

Ул аны артистканың сәхнә иҗатындагы уңышлары алдында баш иеп кенә түгел, ә хатыны Луиза Салиәскәровага күрсәткән ярдәмен истә тотып та язган булса кирәк. РСФСРның атказанган артисткасы булганлыктан, Фатыйма Ильскаяга, башкаларга караганда, паек күбрәк бирелгән. Шәфкатьле артистка Туфанның хатынына да шуннан өлеш чыгарган. Иренең гомерен саклап калу өчен донор булган, «халык дошманы хатыны» дигән мөһер сугылып, эшеннән дә, фатирыннан да куылган артистканы үлем тырнагыннан барыбер коткарып кала алмаган Фатыйма ханым...

Артист тормышы төрле хәлләргә бай булуы белән дә аерылып тора. Фатыйма Ильскаяга үз исемендәге героиняларны уйнарга туры килә. Мирсәй Әмирнең «Тормыш җыры»ндагы Фатыйма — иң популяр сәхнә образы. Бу спектакльдә артистка, сөйгән яры Басыйрга багышлап, җыр башкара. Димәк, аның җырлау сәләте дә камил булган. «Тормыш җыры»нда кешенең язмышы җырга ышанып тапшырыла. Ил иминлеге өчен борчылу, ил исән булса — үзеңнең дә исән булуың фәлсәфәсе, дөресрәге, туган-үскән илеңнән «бетмәс көч алу» фикере, язучы Гариф Ахунов язганча, халык җырларыннан ук килә торган шушы фәлсәфә — бу җырны үлемсез итә.

С.Җамалның «Фатыйма Сабри» әсәрендә дә төп рольдә — Ф.Ильская.

Бу ике рольне башкарганда да, фронтта һәлак булган газиз улы аның хыялында гәүдәләнә. Кем белә, йөзе-кыяфәте белән дә әнисенә тартым Фуатның йомшакҗылы тавышы, бәлки, театр сәхнәсендә чыңлар иде!.. Ләкин егерме яше дә тулмаган Фуат Бакиров 1943 елның 8 ноябрендә Украинаны азат итүдә барган канлы сугышларда һәлак була... РСФСРның халык артисткасы Рәшидә Җиһаншина үзенең хатирәләрендә менә нәрсәләр яза: *«Сугыш беткәннән соң, Фатыйма апа улының каберенә барды, озак вакытлар Фуатның исән калган дуслары белән хәбәрләшеп торды. Соңрак ул гарәп язучысы С.Җамалның «Фатыйма Сабри» драмасында карт ана — Фатыйма образын башкарды. Ул йомшак күңелле, горур, нык табигатьле ананың сагышын бик тирән итеп гәүдәләндерде. Фәкать зур кайгы кичергән аналар гына шундый тирән хисләрне бирә ала, минемчә, олы мәгънәсендә Ил исемен йөртергә лаек булган Фатыйма Ильская кебекләр генә».*

Без, студент халкы, театрга яратып йөрибез, спектакльләрне карап барабыз. Группадашларым Әлфия Шәйдәүләтова

белән Рузалия Шәрифуллина, «авылга киткәч, мондый мөмкинлек булмаячак» дип, Г.Камал театрыннан кайтып та кермиләр. Күпчелек шулай да концертларга йөри. Группаны тулы составта «Әдәби җомга» кичәләрендә Тукай клубында гына күрергә була. Академ җитәкчебез Мәдинә Шәйхи кызы Җәләлиева Опера һәм балет театрына да культпоходлар оештыргалый. Кыскасы, хәзерге көн тамашасы белән без таныш. Элек ничек булган? Мине шул кызыксындыра. Фатыйма ханым янына барган саен, әүвәлгеләр турында ни дә булса белеп, хәбәрдар булып кайтам. Мин сораштырам, ул иренмичә сөйли. Элек спектакль турында тулы мәгълүмат афишаларда, газета битләрендә басылган. Алар тамашаны килеп карарга чакырган үгетләүләр белән чуарланган. Халыкны җәлеп итү өчен, танцылар оештырылачагы игълан ителгән. Спектакльдән соң, афишада алдан хәбәр итеп, концерт куелу очраклары да булган. Анда аерым артист «сольный» чыгыш ясаган. Афишада баш рольләрне башкаручылар һәм катнашучылар аерым исемлек белән бирелгән. Иң ахырда театр мөдире, баш режиссёр, суфлёр, администратор күрсәтелгән. Билетлар алдан китап кибетендә, китапханәдә сатылган. Спектакль куеласы көнне театр бинасында сатып алырга мөмкин булган. Артистлар атна ахырында, ягъни җомга, шимбә һәм якшәмбе көннәрендә генә уйнаганнар. Атнаның беренче яртысы роль өйрәнүгә, репетиция ясауга киткән. Тамаша көндезге 2дә яисә 3тә, кичке 8дә яки 8дә 30да башланган. Тәнәфес вакытында Салих Сәйдәшев җитәкчелегендәге 20 кешелек оркестр борынгы һәм яңа милли көйләрне уйнап торган. Программада алдагы көндә нинди спектакль, кемнең бенефисы булачагы анонс итеп бирелгән.

Габдулла Кариев җитәкчелек иткән «Сәйяр» труппасының беренче артисткаларыннан Фатыйма Ильскаяның бенефисы аңа 14 яшь тулып узгач ук оештырылган. Бу вакыйга Казанда булган. Талантлы яшь артистка, гомумән, спектакльләрдә, күбесенчә, төп рольләрдә уйнаган. Аны «татар-башкорт сәхнәсенең талантлы артисткасы» дип бәяләгәннәр. Ул туган шәһәре Оренбургны да онытмаган. Узып барышлый булса да, якташларына бер гастроль спектакленнән өлеш чыгара торган булган. Мәсәлән, шушы шәһәрдән күтәрелгән артистка үзен югары биеклеккә җиткергән халкы алдында «имтихан тотып», берсендә Фәтхи Бурнашның атаклы «Таһир-Зөһрә»сен бүләк иткән. 21 яшендә, икенче мәртәбә Казанга килеп, Татар академия театрында эшли башлаган «хәзинә»не, тора-бара, афишаларда, зурлап, «Фатыйма ханым Ильская» дип яза башлаганнар. Талантлы кызын халык та таныган, ә хөкүмәт аңа «ТАССРның атказанган артисткасы» исемен сәхнә эшчәнлеге егерме елдан артып киткәч кенә биргән...

Камил талант иясе хакында заманында «ул бик холыксыз икән» дигән сүзләр дә йөргән. Мондый хәбәр гади халык арасында таралганмы, әллә артистканың үз даирәсендә генәме? Ничек кенә булмасын, үзен кемнәр беләндер дорфа тотуына китергән сәбәпләр бар кебек. Беренчедән, ул — олуг шәхес, бөтен барлыгын иленә биргән. Димәк, биргән кешегә, киресенчә, тияре дә тиеш. Әмма җәмгыять аны эшләми. Гаделсезлек белән көрәшә-көрәшә, талант «эт каешына» әйләнә. Тупас мөнәсәбәтле чиновниклар белән «сугыша-сугыша», үзе дә тупаслана. Текә тауга менгән альпинист сыман, үҗәтләнә-үҗәтләнә, йөрәк каны бәрабәренә, һаман иҗат үрләрен яулый. Ул югары үрмәләгән саен, аның башына «суга торалар». Әйе, бөекләр биеклеккә шәхси югалтулар хисабына күтәреләләр. «Ил кызы» псевдонимын иҗатына юлдаш, компас иткән Фатыйма ханым да гомеренең соңгы көннәрендә ачы үкенү хисләре кичермәгәндер, дип кайсыбыз әйтә ала?! ■

«ЯШӘҮ БАРЫБЕР КЫЗЫК»

ИСЕМЛЕ ҖЫРЛАР ҺӘМ РОМАНСЛАР ҖЫЕНТЫГЫН КҮЗАЛЛАУ

Айдар Фәйзрахманов

Беренче карашка җиңел тоелса да, чынлыкта күп хезмәт, ихтыяр көче, тырышлык таләп итүче һәм, шул таләпләр үтәлгәндә, гаять югары дәрәҗәгә җитә алган җырчы хезмәтендә булуыма да кырык елдан артык гомер узган.

Егерме җиде ел Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры солисты, өч дистә елдан артык эстрада җырчысы, унбиш ел Татарстан Республикасы фольклор музыкасы Дәүләт ансамбленең, биш елдан артык Татар дәүләт филармониясенең сәнгать җитәкчесе, Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры — бер-берсенә үрелеп барган бу хезмәт-вазифалар чылбыры тулаем җырдан үрелгән.

2014 елда дөнья күргән «Яшәү барыбер кызык» дип аталган җыентык та — күңелемдә туган көйләрне профессионал татар шагыйрьләренең шигырьләре белән «ярәштереп» туган җырлардан

тупланган басма. Җырларның язылу вакытлары, тарихлары төрле, ләкин милли моңы, аһәңе, татарча бормалары уртак. Ихлас күңелдән чыккан моң гына чын тыңлаучысын таба. Бу җыентыкка кергән җырлар тамашачы алдында күп тапкырлар башкарылган, бихисап алкышлар җыйган, яратылган. Аларны акка кара белән язып китапка төшерү — тарихта тагын да озакка калдыру өчен бер мөмкинлек һәм минем өчен бик тә әһәмиятле, дулкынландыргыч, шул ук вакытта үз алдыма куйган сорауларга җавап табу һәм дә максатыма ирешүнең бер үрнәге дә. Максатка ирешү дип, мин вокал укытучысы буларак, яшь җырчыларны үстереп халыкка тәкъдим итүне атыйм.

Милләтебезнең профессионал җыр мәктәбенә нигез салучы композиторларыбыз Солтан Габәши, Салих Сәйдәшев, Мансур Мозаффаров, Нәҗип Җиһанов, Рөстәм Яхин, Әнвәр Бакиров традицияләрен дәвам итү, халык көйләренә аваздаш җырлар, романслар язу, аларны яшь башкаручылар иҗаты аша киң тамашачыга җиткерү безнең көннәрдә бик мөһим. Ләкин «татар җыры» атамасын бүген талымсыз такмакларга, көйләре, сүзләре ягыннан камил булмаган кыска гомерле «әсәр»ләргә карата да кулланалар. Гомерен профессионал җыр сәнгатенә багышлаган һәркемнең бу хәлгә йөрәге әрни, күңеле сыкрыйдыр. Җыр сәнгатендәге әлеге хаос белән көрәшүдә мин сайлаган юл — профессионал шигырьләргә профессионал музыка иҗат итү һәм аларны профессионал башкаручылар аша тыңлаучыга җиткерү. Җырлар шул нисбәттән чыгып иҗат ителде. Алар фортепиано белән җырлар өчен дә профессионал музыкант Ильяс Камал, композиторлар Эльмир Низамов, Юлия Бек тарафыннан эшкәртелделәр һәм ноталы басма буларак, җыр сөюче тамашачыга тәкъдим ителде. Вокал ягыннан чыгып караганда, җырлар башкару өчен бик уңайлы, «диапазон», «тесситура», «ритмик сурәт», «көй агылышы» дигән музыка таләпләренә туры килә торган. Әлеге китап урта һәм югары музыка белеме бирә торган уку йортлары өчен алыштыргысыз укыту әсбабы да була ала.

Җырның сүзләре, шагыйрьләрнең профессионал дәрәҗәсе минем өчен һәрчак мөһим булды. Ә бит җыр текстларына салкын карау яисә бөтенләй битараф булу безнең заманда гадәти күренешкә әйләнде. Көйчеләрнең, башкаручыларның, нәтиҗә буларак, тыңлаучыларның да игътибарын күпкырлы фәлсәфи, тәрбияви патриотик кимәлдәге шигърияткә юнәлтү бик мөһим.

«Яшәү барыбер кызык» җыентыгына кергән җырлар арасында Мөдәррис Әгъләмовның «Кеше без» шигыренә язылган җыр бар. Ул инде Татарстан Республикасы фольклор музыкасы ансамбле тарафыннан күп тапкыр башкарылды һәм тамашачы мәхәббәтен яулады.

Кырларда кар гына,
Сукмаклар тар гына,
Юлсыз җир, юл салып
Бар гына.

Юлда бу кичебез,
Бар, димәк, эшебез.
Эз калсын — шуңа да
Кеше без!

Юлларда каты бар,
Кемнәрнең аты бар.
Юлыңны югалтсаң,
Ояты бар.

Бу сүзләрдә халкыбызның ирексез һәм шул ирекне даулаган еллары да, юлыңнан тайпылмый барырга, кеше булуыңны онытмаска чакыру да үтемле әйтелгән.

Су буенда баш иярләр
Сыгылма таллар сиңа.
Алларыма там диярләр
Тал кебек ярлар сиңа.
Ярларыңны ятим итмә,

Талларыңны ятим итмә,
Туган җиреңнән китмә.

Туган илдән аерылмаска Гамил Афзалның бу шигыреннән дә көчлерәк өндәп буламы... Әлеге гаҗәеп шигырьне салмак көйгә салдым.Туган яктагы талларның сакау шавы, талгын инеш агышы, сызылып килгән таң тынлыгын бозмаслык аһәңгә ия булырга тиеш иде ул көй.

«Хөрмәтле җырчы дустым! Син бик авыр, әмма да ләкин бик тә ләззәтле, күп ихтыяр көче, тырышлык таләп итүче, шул ук вакытта дәрәҗәле дә хезмәт сайлагансың. Мин ул юлдан уздым, әле дә барам. Үз халкымның мәшһүр җырчыларының дәвамчысы буларак, бу эстафетаны сиңа тапшырасым килә». Китапка кереш сүземдә әлеге басманы кулына алган яшь җырчыларга мөрәҗәгатем шулай башлана. Яңа буын җырчыларына, әлбәттә, җырчы буларак камилләшүләрен, югары вокал, матур җырлау (bel canto) мәктәбен узуларын телим. Әлеге мәктәп нигезендә белем алган өлкән буын җырчыларыбыз — Азат Аббасов, Зөләйха Хисмәтуллина, Фәхри Насретдинов, Нияз Даутовлар салган җырлау техникасы бар!

Татар халык җырларында яңгырый торган милли аһәңне, музыка телендә «мелизм» дип аталучы бормаларны җиренә җиткереп башкару, шулай ук дөрес сулыш алу, тынга таянып җырлау, җыеп әйткәндә, дөрес вокал белеме таләп итә. Рәшит Ваһапов, Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова, Таһир Якуповлар мәктәбе бу.

Кызганыч ки, соңгы елларда без профессионал җырлаудан шактый читкә тайпылдык. Әмма юнәлешне үзгәртергә, җырны профессионал юлга борырга соң түгел әле. Бу юнәлештә үзен хөрмәт иткән һәр иҗатчының хезмәт куюы кирәк. «Яшәү барыбер кызык» җырлар һәм романслар җыентыгы — җырчыларга профессионал кимәлдәге җырлар тәкъдим итү юнәлешендә шундый бер талпынуым.

Уйна, йөрәк, бары тормыш көен,
Кылларыңны сузып,
Кичерәсе мизгелләргә сөен,-
Яшәү — барыбер кызык!

Яңа туган таңны котлап киләм,
Кулларымны сузып,
Авырлыклар, сабырлыклар белән —
Яшәү — барыбер кызык!

Яшәвемнең төп мәгънәсе булган ҖЫР! Синең алдыңда башымны иям һәм сиңа хезмәт итүем белән горурланам. Син дә минем белән горурланасыңдыр, дигән өметем бар... ■

Мәскәүдәге Кызыл мәйданның иң түрендәге беренче мавзолей 1924 елның 27нче гыйнварында, Владимир Ильич Ульянов (Ленин) вафат булып берничә көн үтүгә үк әзер була. Беренче мавзолей пирамида рәвешендә агачтан салына. Бүгенгесе — өченчесе — гранит таштан төзелә.

Ленин — җир шарының алтыдан бер өлешендә моңарчы күрелмәгән биниһая зур социаль, мәдәни, сәяси һәм икътисади эксперимент-инкыйлаб ясаган бөек шәхес. Минем кебек балачагы СССРның торгынлык чорына туры килгән буын әле яхшы хәтерлидер: баштарак бөдрә чәчле нәни Володяның сурәте төшерелгән кызыл йолдызны, бераздан — пионер, соңрак исә — комсомол билгесен (анда да — Ленин рәсеме) күкрәк түренә тагып йөрдек. Аңа багышланган җырларны яттан өйрәндек...



...Фазыл Искәндәрнең түбәндәге язмасын әзерләгәндә Ленинга кагылышлы яңа мәгълүматлар белән дә танышырга туры килде. Бактың исә, Ленин «баба»бызның бабасы (әнисенең әтисе) чын мәгънәсендәге алпавыт булган икән! Ә менә оныгы сыйнфый күралмаучылык хисләреннән ташып-шашып торган, диләр. Аның бабасы Израэль Мойша улы Бланк, яһүди диненнән баш тартып, православиене кабул итә, чукынып, Александрга әверелә. 1847 елда ул Казаннан 60 чакрым ераклыктагы Янсала авылында (хәзерге Питрәч районының Ленино-Кокушкино авылы) утар сатып ала. Ул 1870 елда вафат була һәм, кайбер фаразларга караганда, үзенең оныгы Володяны күреп һәм тәрбия кылып та кала алган. Александр Бланк, православие йоласы буенча, Черемыш авылы (хәзер Питрәч районына керә) зиратында җирләнгән...

Александр Бланк

Тәрҗемәчедән

МАВЗОЛЕЙ

Фазыл Искәндәр*

Юлбашчының мәетен мавзолейга кую фикере Сталинның башына килде. Көн саен Мавзолейга агылучы мең вә меңнәр табуттагы Ленинның әйләнеп ятмаганына инанырга тиеш иделәр.

Ул, бәлки, әйләнеп тә яткан, хәтта ки торып ук та утырган булыр иде дә, вәләкин аңа ирек бирмәделәр. Ленин табутында боргаланмыйча гына, фәкать Сталин кушканча гына ятарга тиеш булып чыкты. Бөек юлбашчының хәрәкәтсезлеге өчен яшерен җир асты институты җавап бирә иде.

Сталин барыбер ялгышты булса кирәк. Ни әйтсәң дә, ул үзе дә хорафатларга бик ышана торган кеше иде.

Ленинга табутында әйләнеп ятуның бер кирәге дә юклыгы тора-бара ачыкланды анысы: шулай була ул – кемгәдер чокыр казысаң... Ят инде менә хәзер ул чокырда тыныч кына!

Вәләкин, җитди итеп кенә әйтсәк, монда гаять тә тирән вә әһәмиятле берничә психологик караш бар. Ил башында торучы хакимият бу дәүләтнең яңа демократик төзелешенә үзе дә бик үк ышанып бетми иде, күрәсең. Һәммәсе дә пыран-заран килеп упкынга оча калса, мәңге батмас шушы табутка тотынып, судан ярга йөзеп чыгарга ниятлиләр, ахрысы.

Инде килеп... Чиркәү дә чиркәү, дибез. Әнә шул чиркәү дигәнебезнең бар булмыш хокуклары да торгызылып бетте бугай инде. Соң, шулай булгач, поплар, атакайлар, һәртөрле чиркәү башлыклары ни көтә? Әле һаман да (туксан бер ел дәвамында!) җир куенына тапшырылмаган мәетне бу кадәр үк мыскыллауга ничек түзәләр диген?! Анысы, урыс тарихында чиркәүне Ленин кебек күралмаган, диннең андый ук кан дошманы булган кеше юк иде әле. Мондый вәхшилеккә, ягъни озак еллар җир өстендә махсус мәет яткыруга иң әүвәл бердәм рәвештә руханилар каршы чыгарга тиеш иде ләбаса. Хәер, инде чиркәү үзенең яшәргә хакы барлыгына үзе дә ышанмый булса кирәк.

Рәсәйдә беркем дә үзенең яшәргә хакы барлыгына ышанмый. Мөгаен, шуңа күрә дә без, һаман да, хәл кадәри булдыралганча, бер-беребезнең хокукларын боза-кыса, хәтта пыран-заран китерә-китерә көн итәргә азапланабыз.

Гади халыкның да күбесе Ленинның күмелүен теләми. Бүген аны күмсәләр, иртәгә үк һәммәсен дә эшкә җигәчәкләр бит. Чын мәгънәсендәге авыр эшкә! Ул чагында инде эчкечелек тә, караклык та булмаячак! Пычагымамы андый эш... Һәммәсе дә ничек бар, шулай калсын!

Урыс тарихында чиркәүне Ленин кебек күралмаган, диннең андый ук кан дошманы булган кеше юк иде әле. Мондый вәхшилеккә, ягъни озак еллар җир өстендә махсус мәет яткыруга иң әүвәл бердәм рәвештә руханилар каршы чыгарга тиеш иде ләбаса.

Бөтен иле эчә. Эчә, эчә, эчә... Әнигә дип әле эчмәсен: нәсари дине буенча, үлгән кешене искә алу йоласы (поминка) мәетне җиргә иңдергәч кенә туктала лабаса. Ә мәет әле һаман да өй түрендә ята бирә. Андый чакта эш кайгысымыни?! Иртәгәсе өчен ишәк кайгырган... Өй түрендәге табут эчендә мәет ятканда каян килеп эш кайгысы булсын инде, йә?! Мәет яткач, бу өйдә вакыт та тукталып тора...

Илдә көн күрүчеләрнең, җан асраучыларның барча-барча гөнаһларын бергә җыйнасаң да, алар барыбер төп гөнаһ каршысында чүп кенә булып тоелачак. Ил түрендә – Ил йөрәгендә күмелмәгән мәет ята, димәк, аның белән – бу ил белән – үлем тантана итә...

Әгәр дә терeләр үлене күммәсә, мистик мантыйк кануны буенча, үле тереләрне үзе күмә башлый. Миллион вә миллионнар юк ителде. Инде килеп – кыргыйлану... Илен саклап һәлак булган мең вә меңнәрнең дә сөякләре әле һаман да җирләнмәгән килеш. Ахмаклыкның, имансызлыкның, мәнсезлекнең Бабил** буталышы...

Илнең төп йортында күмелмәгән мәет яткыру – зур гөнаһ. Шул килеш төзү-яңарту эшенә керешү – мәгънәсез эш. Чөнки барыбер җимереләчәк.

Урысчадан ***Марат Закир***
тәрҗемәсе ■

* Фазыл Искәндәр (Фазыл Абдулла улы Искәндәр (1929) – күренекле шагыйрь һәм прозаик, күпсанлы премияләр лауреаты.
** Бабил – борынгы Вавилон (Баб-Илу) манарасын төзегәндәге буталыш күздә тотыла. – *Тәрҗ.*

ШӘЙХИ МАННУРНЫҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Ш.Маннурның китапханә-музее

ТУГАН ЯК
ҺӘМ ӘДИП КАДЕРЕ

Марат Закир

Ул елларда безнең яклардагы сабан туе Шыя елгасы буендагы мәйданда ике авылга бер – уртак була торган иде. «Безнең яклар» – дигәнем – Мамадыш районының Тулбай һәм Дусай авыллары.

Мин Аны — Шәйхи Маннурны — тәүге һәм соңгы тапкыр әнә шул сабан туенда күрдем. Әниемнең: «Язучы абыең әнә шул була инде, улым», — дигәне хәтердә.

Минем — җиде яшьлек малайның — язучы дигән затны әле гомеремдә беренче мәртәбә генә күрүем иде. Шәйхи Маннур чак кына алга табанрак бөкрәя төшкән бик тә олпат гәүдәле, чал чәчле бабай булып күз алдында калган һәм бу бабайдан нindидер үзенә күрә бер илаһи, шул ук вакытта бик тә садә нур сирпелә сыман иде. Ул чагында әле мин язучы дигән затны бер дә ашамый-эчми торган, безнең күк гади җир кешеләреннән бөтенләй дә үзгә булган изге җан иясе итеп күз алдына китерә идем.

Янә берничә елдан соң мин Шәйхи Маннурның **«Агымсуларга карап»** дип аталган китабын укып чыктым һәм… шаккаттым. Теге чакта үз күзем белән күргән язучы бабай, бактың исә, нәкъ безнеңчә гап-гади авыл телендә яза вә сөйләшә икән ләбаса! Мин дигән малай, олан, түтәй, әтәй-әнәй, Олы җиңги, Галиәттәй, Мәгъмүрәттәй… Менә сиңа вәйт — безнең **Дусай**, күрше **Тулбай**, **Шәмәк**, **Тәкәнеш** авыллары турында да язылган икән бит әле монда!

Әлеге китапны укып чыкканнан соң, язучы дигән бу илаһи җан иясе минем өчен үтә якын, үтә үз, хәтта әйтер идем ки — үземнең бабаемдай тоела башла-

ды. Менә бит ул нишләтә — гап-гади, әмма хис белән акыл бергә үрелеп барган саллы сүз вә җөмләләрнең куәтекодрәте!

Мәктәбебездә исә безне Шәйхи Маннурның эре хәрефләр белән язып куелган дүртьюллык шигыре каршы ала иде:

Татарчаны да яхшы бел!
Русчаны да яхшы бел!
Икесе дә безнең өчен
Иң кирәкле, затлы тел!

Бәлки әле шул шигырен язган чагында ук әдип татар телен рус теле белән бер дәрәҗәгә күтәрү өчен киләчәктә хәл кадәри гамәли адымнар ясарга тырышачагыбызны чамалагандыр, шуңа өметләнгәндер дә. Һәрхәлдә, илдәге татар баласы укыган барча мәктәпнең иң түренә язып эләрдәй зирәк, фәһемле сүзләр бу.

...Инде янә берничә елдан соң безнең **Олыяз-Тәкәнеш** төбәгенә ел саен унбишенче гыйнварда төркемтөркем язучылар кайта башлады. Туган авылы Тулбай зиратында җирләнгән каләмдәшләре Шәйхи Маннурның кабере янында аның рухын яд кылырга кайталар иде алар. Инде өч дистә елдан артык биредә әнә шулай 15 гыйнварда олуг әдибебезнең туган көне тантаналы рәвештә билгеләп үтелә, үзе васыять иткәнчә, яшь язучыларга, югары хезмәт күрсәткечләренә ирешкән якташларына аның премиясе тапшырыла. Бу чара тора-бара үзенә күрә бер изге вә күркәм йолага әверелде.

***

Шәйхи Маннур — әдәби хезмәтләре өчен 1939 елда ук Хезмәт Кызыл Байрагы орденына — ул чагында илнең иң олы бүләгенә — лаек булган беренче татар шагыйре. Атаклы **«Гайҗан бабай»** поэмасы, йөзләгән шигырьләре, лирик повестьлары, **«Муса»** романы белән халкыбыз күңелен яулаган әдип ул. Сүз уңаеннан, «Муса» романының бер өлешен ул, туган авылы Тулбайга кайтып, шунда берничә ай дәвамында яза.

Шәйхи Маннур — бар гомерен иҗатка, әдәбиятка багышлаган шәхес. Һич тә гаҗәп түгел: туры һәм төртмә сүзле, уйлаганын ярып әйтә торган, татар әдәбиятының намусы, дип йөртелгән бик тә принципиаль бу әдипне байтак кына яшь каләмдәшләре әле бүген дә үзләренә үрнәк вә остаз итеп саныйлар. Ни гаҗәп, әмма хак: шигърият сафлыгы сагында торган әдипнең сугыштан кайткач та язган менә бу юллары һәр заман өчен дә искермичә яңгырый:

Сак булыгыз, гамьсез гулливерлар,
Лилипутлар килә шигырьгә!

***

Шәйхи Маннур — вафат булгач та җәсәден туган авылы зиратына күмәргә, каләм хакыннан җыелган бар акчасын яшь язучыларга премия итеп бирергә васыять калдырган, әле исән чагында ук үз акчасына туган авылында китапханә төзеткән беренче татар әдибе. Мөгаен, әнә шул рәвешле ул туган төбәгенә башкалабызның игътибарын юнәлтергә тырышкандыр. Шөкер, зирәк әдип морадына ирешкән дә! Ә бит, уйлап баксаң, Казан — гаять зур эш-гамәлләргә сәләтле, кодрәтле урын. Мамадыш төбәгендәге соңгы өч дистә елдагы уңай үзгәрешләрдә, алгарышта бәрәкәтле якташым Шәйхи Маннурның да өлеше бар, дип исәплим мин. Әйткәнемчә, инде утыз биш ел дәвамында татар язучылары, өлкән каләмдәшләренең истәлеген олылап, аның туган ягына кайтып торалар һәм шул дәвердә Мамадыш төбәге, аеруча Олыяз-Тәкәнеш яклары, күзгә күренеп үзгәрде. Биредәге һәр авылга төзек, шәп юллар илтә, газ-су кергән, һәр авылда кибет, мәктәп, балалар бакчасы, медпункт, мәдәният йорты, мәчет балкып утыра. Иң мөһиме — Шәйхи Маннурның олпатлыгын гына түгел, ә бәлки аны хөрмәтләп кайткан язучыларны да таный-олылый белә торган җитәкчеләр эшли бу төбәктә. Әдип үзе тәрбияләгән җитәкчеләр! Шәйхи Маннурның Тулбае да кергән **«Чул-**

пан» колхозы белән байтак еллар **Галимҗан** ага **Җиһаншин** җитәкчелек итте. Язучыларны олылый белү гадәте дә, минемчә, аннан башланды. «Аллага шөкер», — диик, хәзер бу гадәт чын мәгънәсендә асыл бер йолага әверелде. Иң мөһименнән дә мөһиме — милли гамьле, әдәбият-сәнгатькә мөкиббән, рухи яктан да сау-сәламәт халык яши биредә.

Янә шунысы куанычлы: заманында Мамадыш районын җитәкләгән, язучыларның җәмгыятьтәге урынын, сүз җегәрен таныган-хөрмәтләгән **Фатыйх Сибагатуллин**, **Экзам Гобәйдуллиннар** — бүген республикабыз күләмендә абруй казанган шәхесләр. Районның хәзерге хакиме **Анатолий Иванов** та алар чорында башланган күркәм гамәлләрне уңышлы дәвам иттерә.

Шәйхи Маннур Мамадыш районында туып-үскән яшь каләмдәшләренә дә һәрдаим игътибар юнәлтеп, хәерхаһлы булып, ярдәм итеп яшәде. Район гәзите каршындагы **«Агымсу»** әдәби иҗат берләшмәсен дә әүвәл ул оештырып җибәрә. Казаннан тәҗрибәле-олпат әдипләрне алып кайтып, алар белән бергә әдәби иҗатка тартылучы яшьләргә киңәш-табыш иткән кеше ул.

Һәр ел саен унбишенче гыйнварда Мамадыш каласының кыл үзәгендәге Шәйхи Маннурның мәһабәт бюст-һәйкәле янында шигырь бәйрәме үткәрелә. Бу һәйкәлнең дә үз тарихы бар. Аның авторы — бөек сынчы-рәссамыбыз **Бакый Урманче** үзе. Казан компрессорлар заводында бик тә затлы чуеннан коелган мондый һәйкәл — Татарстанда берләнбер. Беркайчан да тутыкмый, уалмый торган мәңгелек бу һәйкәлне заводның ул чагындагы директоры, милләтпәрвәр шәхес **Әхмәт** ага **Галиев** җитәкчелегендә бик тә үзенчәлекле алым-технологиягә нигезләнеп койганнар.

***

«Ник янасың?» — диләр дуслар миңа,
Яши алмыйм шул мин янмыйча.
Кешеләрнең күңел почмагына
Энҗедәй дә якты салмыйча», — дип язган Шәйхи Маннур моннан нәкъ алтмыш ел элек.

Гомере буе татар әдәбиятына, халкына хезмәт иткән әдип әлеге шигъри шигаренә һәрдаим тугры кала. Милләтең, Ватаның, туган төбәгең сине онытмый, кадереңне вә кабереңне белә, яд итә икән, димәк, гомерең дә әрәмгә үтмәгән. ■

Мамадыш шәһәре. 2001 ел

«Кәбир һәм Фазыл Туйкиннар: заман, шәхес, чынбарлык» дип аталган төбәкара фәнни-гамәли конференциядә катнашучылар. Әлмәт шәһәре. 2014 елның 17 нче октябре

ТИРӘН ТАМЫРЛЫ ТУЙКИННАР

Эльмира Шәрифуллина

1971-1972 уку елы... Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында укыйм. Мөгаллимебез Мөхәммәт Мәһдиев үзенең студентларына курс, диплом эшләре тәкъдим итә. Исем-фамилиясе үк шигъри яңгырашлы «Фазыл Туйкә (Туйкин), тормыш юлы һәм иҗади эшчәнлеге» дигән тема күңелемә хуш килә.

Мөхәммәт абый сөйләгәннәрдән Фазыл Туйкинның шәхес культы корбаны икәнлеген, аның турында материал табу авыр булачагын, булганнарының да гасыр башында ук чыккан газета-журналларда сибелеп ятканын һәм аларның, шулай ук китап булып чыккан әдәби әсәрләренең дә гарәп имлясында басылганын белсәм дә, эшкә керешәм. Китапханәләргә чумам. Иң беренче эш итеп, сирәк китаплар фондында сакланучы җыентыкларын барлыйм. Алар кулга бирелмәгәнлектән, уку залына яздырып, көннәр буе утырып, кириллицага күчерә башлыйм. Бу эшне әллә ни авырлык тоймыйча башкарып чыгуым, чигү бизәкләре кебек хәрефләрне әнкәйдән дә бераз өйрәнеп, университетта да Лена апа Таҗиеваның гарәп төркемәнә йөреп, яратып үзләштерүемнән булгандыр.

Әдәби әсәрләрен кириллицага

күчереп бетергәч, ул яшәгән елларда нәшер ителгән газета-журналларны актара башладым. Монысы инде бик күпкә авыр һәм тузанлы эш иде. Әмма миңа кызык, чөнки героема көннән-көн ныграк гашыйк була барам. Җитәкчем дә һаман дәрт өстәп, юнәлеш биреп тора. Өфе китапханәләрендә дә «казынырга», бүгенге көндә дә исән булырга тиешле хатыны белән танышырга, истәлекләр яздырып алырга, берәр фотосурәтен, исән булса, берәр кульязмасын алып кайтканда да әйбәт булыр иде, дигән теләк туа.

Хөршидә Туйкинаның адресын табып, Башкортстанның Үзәк дәүләт архивына һәм Башкортстанның Үзәк фәнни китапханәләренә керергә рөхсәт итүләрен сорап, «Казан утлары» журналының баш редакторы Зәки Нури имзалаган хатларны алып юлга чыгам. Юлдашым да бар. Ул — көндезге бүлектә укучы Җәвит дигән егет. Фазыл Туйкинның гаиләсе янына да без аның белән бергә бардык.

Хөршидә апа (без аңа шулай эндәштек, ә ул мулла кушкан исеменең Хөршидсара икәнен әйтмәде) — уртача буйлы, җыйнак гәүдәле ханым. Ак яулыгын озынча итеп бәйләгән; итәге киң итеп тегелгән, бизәкле, үзенә бик килешле, билле күлмәк кигән; аягында ап-ак йон оекбаш иде. Сөйләшүе йомшак, салмак, ипле. Өйләре чиста, идәннәрендә келәм. Кызы, кияве, аларның гаиләсе белән яши икән.

Хөршидсара апа сөйләгәннәрдән блокнотыма түбәндәгеләрне язып куйганмын:

«Фазыл 1931-1937 елларда Габдрахман авылында укытты. Башта Фазылны алдылар. 1937 елның 1 нче гыйнвары иде. Ул вакытта Кәбир абый авырый иде. Аны февральдә алдылар».

Кәбир Туйкин, туганы Фазыл Туйкинны кулга алгач, үзенең һәм туганының кульязмаларын ашыгычлык белән җиргә күмә. Хөршидсара апага: «Әгәр мине алсалар, абзар капкасы баганасыннан фәлән юнәлештә,

Фазыл Туйкин. Уфа, 1912 ел

фәлән адым ераклыкта, фәлән метр тирәнлектә булыр. Дөньялар гел болай тормас, дөрес тормыш килер. Фазыл да кайтыр, бу бер чуалчык ялгышлык», — ди.

«Фазыл да, Кәбир абый да кайтмадылар», — дип сүзен дәвам итә Хөршидсара апа. — Фазылның 1938 елның 11 нче гыйнварында харап ителүен 1953 елда гына белдек. (Соңыннан өйрәнелгән документлар буенча Фазыл да, Кәбир Туйкин да 1938 елның 11 нче февралендә «атып үтерергә» дип хөкем ителәләр. Карар шул елның 15 нче февралендә тормышка ашырыла.)

Кульязмалар турында кабат сорау биргәч, Хөршидсара апа:

«Башта казымадык. Үзем дә берәүгә дә әйтмәдем. Байтак вакытлар үткәч, бик эзләдек, таба алмадык», — дип җаваплады. «Бердәнбер сурәте» дип, бармак бите кадәрле бер фотосын бирде. Аны фотографиядә үрчетеп, зурайтып, зурайтылган вариантын Хөршидсара апаның үзендә дә калдырып, Казанга

алып кайттым. Өстенә утыртма якалы костюм, башына фәс киеп төшкән шул фотосурәтне, кулъязмамның беренче битенә куеп, 1973 елда диплом эшемне якладым.

Бу фото «Казан утлары» журналының 1977 елгы 6 нчы санында диплом эшемнең бер өлеше белән бергә басылып, киң җәмәгатьчелеккә мәгълүм булды. Фазыл Туйкинның тууына 100 ел тулганда шул ук «Казан утлары» журналында инде икенче, галим Җәүдәт Миңнуллин тапкан фотосурәт һәм өстәмәләр белән «Бүген дә хәрәкәттә» исемле уртак мәкаләбез чыкты. Аннан соң да бу тынгысыз җанлы чын педагог, туган җирен, халкын өзелеп яратучы олуг шәхес белән бәйле материалларны гел туплап, җыеп, кызыксынып яшәдем. Туганнары, укучылары белән хат алыштым.

Милләтемнең талантлы, батыр йөрәкле уллары Фазыл һәм Кәбир Туйкиннарның иҗатын туплау, эшчәнлекләрен өйрәнү эше әле дә дәвам итә. Узган ел, 2014 елның 17 нче октябрендә Әлмәт шәһәрендә үткәрелгән «Кәбир һәм Фазыл Туйкиннар: заман, шәхес, чынбарлык» дип аталган төбәкара фәнни-гамәли конференциядә бик шатланып катнаштым. Туйкиннар тамырының бүгенге көчле буынын күреп сокландым. Алар Фазыл һәм Кәбир Туйкиннардан соңгы 3-4 нче буыннар. Туган илебезнең төрле төбәкләрендә хезмәт куючы баһадир ир-егетләр, сокландыргыч кыз-ханымнар: югары уку йортлары ректорлары, ректор урынбасарлары, галим, шагыйрь, табиб, фотосурәтчеләр… Иң мөһиме, бердәм, булдыклы, эшлеклеләр!

Бу эшкә өлеш кертүем, яраткан мөгаллимем белән әлеге изге гамәлнең чишмә башында торуыбызга горурланам. Шушы юнәлештә бөтен күңелен биреп, җиң сызганып эшләүчеләргә уңышлар телим! ■

Фазыл һәм Кәбир Туйкиннар туып үскән Зәй-Каратай авылы – дельталёттан караганда. 2013 ел.
Пилот Радик Туйкин фотосы



Татар энциклопедиясе институты урнашкан бина

ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕНЕҢ татар телендә 4 нче (М — П), рус телендә 6 нчы (У — Я) томы дөнья күрде. Татар энциклопедиясе институты хезмәткәрләре һәм күп санлы авторлар тарафыннан басмага әзерләнгән әлеге хезмәтләрнең баш мөхәррире — **Мазһаров Әхмәт Мазһар улы**, җаваплы мөхәррире — **Сабирҗанов Гомәр Салих улы**.

ТАКТАШ
ҺӘМ АНЫҢ ГАИЛӘСЕ

Шагыйрьнең поэтик куәте кабатланмас рәвештә тылсымлы. Аның турында олы затлар менә ничек яздылар. Шагыйрь Шәйхи Маннур: «Һади Такташ халык тудырган икенче даһи иде. «Җир уллары» – куркыныч бу китап. Бөтереп алып китә торган тирән су кебек куркыныч. Кинәт суырып алыр да, көтелмәгән төпсез чоңгылга батырыр төсле». Хәсән Туфан: «Юк, Һади, мин килгәндә син кабатланмас рәвештә бар идең. Син китердең мине шигырьгә». Башкорт шагыйре Баязит Бикбай: «Ул, Такташ, татар әдәбиятының совет чоры Тукае. Андый шагыйрьләр 100 елга бер генә туалар».

1970 еллар башында минем университет тәмамлап, Татарстан радиосында эшли башлаган чаклар. Хәзер торгынлык дип аталса да, гаҗәеп кызык замана иде ул. Әле XIX гасырның ахырында туып, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов белән бергә аралашып яшәгән, хәтта Габдулла Тукайны, Гаяз Исхакыйны хәтерләгән кайбер шәхесләр әле исән. Ә инде иҗатларының, әдәби эшчәнлекләренең чишмә башы Такташлар чорына туры килгән шагыйрьләр, язучыларның, бик үк якын мөнәсәбәттә булмаса да, безнең белән тыгыз элемтәдә торган чаклары. Ул вакытта, гомумән, әдәбият-сәнгать әһелләренең радиога сукмаклары бер дә суынмый иде. Алар иртән дә, кичен дә радионың әдәби, музыкаль редакциясе тирәсендә чуалалар, яңа әсәрләр китерәләр, тапшыруларда чыгыш ясыйлар, болай эч пошканнан, юл уңаенда да сугылалар, хәл-әхвәл белешеп, хатирә-истәлекләр белән уртаклашып китәләр.

Шулай беркөнне безгә Һади Такташның каенише, озак еллар Татарстан китап нәшриятында мөхәррир булып эшләгән кеше – Касыйм ага Хәмзин килеп керде. Ул үзе болай башка мәсьәлә буенча килсә дә, без җайлап кына сүзне Һади Такташ тирәсенә бордык. Такташны эчкерсез яраткангамы, аның иҗатына гашыйк булганмы, Касыйм ага җизнәсе турында бик озак һәм онытылып сөйләде. Аның сөйләгәннәре радиотыңлаучыларга да кызык булыр, дип, без Касыйм агадан бу хатирәләрне кәгазьгә төшереп килүен үтендек. Ни өчен кәгазьгә? Чөнки ул вакытта радиода яңгыраган һәрбер чыгыш, һәрбер сүз цензура иләге аша үтәргә тиеш иде. Әйтәләр бит, һәрбер яманның бер яхшы ягы була, дип. Бу очракта да шулай килеп чыкты. Шул цензура аркасында әлеге истәлекләр кәгазьгә күчкән һәм, ниндидер могҗиза белән, саргаеп беткән папкаларның берсе сакланып та калган. Ул радиода яңгыраса да, басма рәвешендә бер тапкыр да дөнья күрмәде кебек. Аны шулай ук «Такташ турында истәлекләр» дигән китапта да табып булмый. Шуларны истә тотып, бу истәлекләрне «Безнең мирас» журналына тәкъдим итәргә булдык.

Рөстәм Акъегет

Гөлчәһрә. Казан. 1920 нче еллар

Һади, Рафаэль һәм Гөлчәһрә. Казан. 1920 нче еллар

Әйе, Такташның шигъри юллары бер укуда күңелдә кала. Чокыр-чакырга төшмисең, сүз түмгәкләренә абынмыйсың, сөртенмисең. Киресенчә, ләззәткә-рәхәткә чумасың.

Ул борчулы минутларда да үзенә ихтирам уята иде. Бервакыт шундый тамаша булып алды. 1927 ел. Такташның кәләше Гөлчәһрә Хәмзина яңа күлмәк сатып алып кайткан. Материясе дә шәп, төсе дә аллы-гөлле, әмма чабуы ертык. Нәкъ арт яктан ярты аршын чамасы икегә ярылган.

Кич. Театрга тамаша карарга барырга әзерләнәләр. Һади сырланып тормый. 10-15 минутта киенеп, галстук тагып, тройной одеколон сөртенеп чыга. Әмма яшь кәләш назлана, тегесен сала, бусын ала.

— Галя, син нәстә, әллә ертык күлмәк киеп театрга, да?..

— Ертык түгел, яңа мода.

— Ташла, пожалуйста, сурьёзно әйтәм. Арттан күренә.

— Һади җаным, син не понимаешь, бу — французская мода.

Такташ тын гына басып тора. Елмая, күксел чәчен сыйпап ала, селкенеп куя. Бер адым Гөлчәһрәгә таба атлый. Ярык чабуга кулын тидереп ала.

— Каерма!

— Галя, тыңла. Ничек залдан үтәргә? Анда интеллигенция, Фатих Сәйфи, Нигъмәтиләр, Болак арты татарлары. Сал, кимә!

— Низачто!

Песи балалары идәндә бутала. Яшь кәләшнең чабуына сикерә. Аларга кызык. Ә Такташ рәхәтләнеп көлә.

— Брысь! Атеистлар! — ди Гөлчәһрә.

Ниһаять, чирек сәгатьтән бүлмәдә тынлык урнаша.

Икенче көнне «Җырым сиңа булсын» дигән шигырь туа. Ул яшь кәләшкә төбәп язылган.

«Әйтче, кызый, болай киенергә
Нинди шәйтан сине өйрәтте?
Инде тездән узган күлмәк итәкләрен
Ертык ясау нигә кирәкте?»

Шагыйрь — тәрбияче, педагог, мөгаллим, үгет-нәсыйхәтче.

Түбәндәге юллар Гөлчәһрәгә, хатынына, җәмәгатенә хат булып яңгырый. Ул гаиләнең бердәмлеген, бөтенлеген саклап калырга тырыша.

«Яшьлегемне үзем
теләп бирәм кулыңа,
Ләкин тыңла мине,
иптәш тә бул миңа,
Ана да бул минем улыма».

Бервакыт Такташ артлы урындыкка утырып, фотога төшә һәм карточканы Гөлчәһрәгә Мәскәүгә җибәрә.Фотоның артына шундый юллар яза:

«Кара, Галя, синең картың
Нинди матур булып утырган.
Кара, башкаларга аны алмаштырма,
Кадерен белеп яшә, чукынган».

Шагыйрь, үзеннән битәр, кешеләр турында кайгыртучан иде. 1928 ел иде булса кирәк. Шагыйрьнең каенанасы Зәкия Такташ фатирында кыш чыкты. Русия кышы салкын, ә Зәкия Үзбәкстан һавасына күнеккән. Казан урамына чыкса, бөрешеп, борын очын тотып кайта. Бу хәл Һадины борчый.

— Әни, әйдәле, магазинга. Татторгка, ерак түгел, Проломныйда гына.

— Нәрсәгә, Һади?

— Сиңа тун карыйбыз.

— Алла, акча юк бит, Һади.

— Бурычка алырбыз, минем кредиторлар байлар.

Шаян сүзләр сөйли-сөйли Һади кыска тун сыман нәрсә кия, Зәкия яшел ефәк үзбәк бишмәтен каптыра. Бер сәгать тә үтми, пыхылдап торган тун алалар.

Коръәннең бер аятендә шундый җөмлә бар: «Мин адәмне вә җеннәрне сынау өчен яралттым». Такташ та шундый сынау астында кала. Шагыйрьнең бертуган сеңлесе Хәнифәне уку йортыннан чыгаралар. Янәсе, кулак кызы, укырга хакы юк. Сеңлесен аклау өчен шагыйрь атна-айлар буе анда чаба, монда йөгерә. Тегеннән справка, моннан документ җыя.

Гөлчәһрә Хәмзина Такташтан аерылып китүне гомер буе бәхетсезлек, дип санады. Соңыннан да безнең белән бәйләнеш-араны өзмәде.

Ниһаять, Хәнифәнең әтисе Хәйрулла абзыйның, әниләре Шәмсениса апаның кулак булмавы ачыла. Уртадан түбән хуҗалыклы крәстиәннәр икән. Нәтиҗә шул: Хәнифә башка уку йортында укуын дәвам итә. Шагыйрь тынычлана. Күтәренке күңел белән шигырь яза.

«Партиягә кертмәделәр инде,
Комсомолга дисәм, алмыйлар,
Пионерга яшең үткән диләр,
Менә ничек мине алдыйлар.

Әмма тынычлану кыска гомерле булды. Мәскәүдән, Гөлчәһрәдән хат килеп төште: «Һади! Мине мулла кызы дип, университеттан чыгарырга телиләр».

Мәсьәлә болай булган. Гөлчәһрәнең әтисе Хафиз үзбәкләрнең милли киемен киеп, фотога төшкән. Чапанга охшаган яшел буй-буй тасма бишмәт, чалмага охшаш бүрек, килешлерәк булсын өчен җиз кашлы таяк та тоткан. Портретның бер нөсхәсен Мәскәүгә, кызына җибәргән. Гөлчәһрә аны дус шәрикләренә күрсәтә. «Настоящий ишан, мулла» — ди берсе. Кызыл авызга шул җитә кала. Муллалар — сыйнфый дошманнар. Карточка комсомол комитетына, деканатка мәгълүм була. «Жаль, отличница была», — ди кемдер.

Гөлчәһрә: «Мин мулла кызы түгел. Әти үзбәк милли киемендә төшкән», — ди.

— Докажи! — диләр.

Такташ та, Гөлчәһрә дә документлар белән «коралланa» башлыйлар. Көрнәле дигән авылга да сәяхәт кылалар.Ниһаять, Гөлчәһрә аклана. Хафиз бервакытта да мулла булмаган. Ул — гап-гади укымышлы интеллигент. Кыз укуын дәвам итә һәм МДУны яхшы, бик яхшы билгеләренә генә тәмамлый.

Нишләмәк кирәк, сыйнфый көрәшнең кызган чаклары иде. Бу дөньяда хак та, ялган да кулга-кул тотынып йөриләр. Бигрәк тә өлкән затларга карата имеш-мимешләр күп була. «Казан утлары» журналының 1984 елгы 4 нче санында бер яшь автор Такташ гаиләсе турында болай яза: «Өй җиһазларын шагыйрь үз күңеленә хуш килгәннәрен сайлап үзе сатып алган булган, чөнки аның беренче хатыны аерылышкан чакта соңгы урындыкка кадәр үзе белән алып киткән. Мәскәүгә барып урнашырга карар кылган...» һәм башкалар... Менә бу — бернинди киртәгә сыймый торган чеп-чи хата. Мин Такташ фатирында күп булдым. Анда күз төшә һәм бүлешә торган җиһаз юк иде. Булган тәкъдирдә дә Такташ һәм аның гаиләсе бу кыргыйлыктан югары тордылар. Автор Такташ музее турында яхшы фикер күрсәтә. Музей кирәк. Шагыйрь торган йорт урынында университет бинасы калкып чыкты. Хәсән Хәйри китабында 173 нче биттә шундый юллар бар: «Такташ яшәгән нигездә университетның яңа биек бинасы төзеләчәк һәм андагы ике бүлмә Такташ музеена биреләчәк икән». Яхшы фикер. Әгәр дә Татарстан хөкүмәте җиң сызганып уйлап караса, бик шәп булыр иде.

Дөрес, гаиләдә ниләр генә булмый. Тәкъдир, язмыш һәркемнең аяк астында йөри. Алар аерыла. Такташ Гөлчәһрә Мансуровага өйләнә. Уңган, чибәр, сабыр кыз була ул. Беренчесе дә, икенчесе дә Гөлчәһрә. Ләкин Һади икенче җәмәгате белән 12-13 ай гына торып кала — шагыйрь тиф авыруыннан дөнья куя. Без инде аның иҗатына да, гаиләсенә дә тел тидермик. Берсен күтәреп, икенчесен түбәнсетмик. Шагыйрьнең сеңлесе Хәнифә Такташева миңа болай диде:

«Гөлчәһрә Хәмзина Такташтан аерылып китүне гомер буе бәхетсезлек, дип санады. Соңыннан да безнең белән бәйләнеш-араны өзмәде».

Бу юлларга һичнәрсә өстәмим. Фәкать бер җөмлә белән чикләнәм. Ул

Коръәндә бик кыска бер аять бар. «Адәм баласы һәрвакыт хәсрәт-кайгыда. Әгәр дә иман китерсә, хаклыкны, гаделлекне васыять итсә, ул бәндәнең гамәле изге.

төскә-биткә чибәр, урыс теленә оста, үткен зиһенле хатын-кыз буларак, горур иде. Артык төчеләнү булып тоелмасын, Такташ та, аның әти-әнисе дә, барлык туганнары да яшь кәләшкә олы мәхәббәт белән карады.

***

Бу язманы тәмамлап, радиога бармакчы идем. Кемдер ишек шакыды. Ачтым, ят кеше. Киеме мосафирларныкы. Аркасында — брезент капчык. Авыр булырга охшый.

— Мөмкинме?

— Пожалуйста.

Керде. Йөкне төшерде.

Чамалыйм, төсмерлим дә кебек, ләкин тел әйләндерергә кыюлыгым җитми. Вакыт уза тора. Ул миңа, мин аңа карыйм. Янәсе, сүзсез танышырга телибез, сынашабыз. Мосафир хәрәкәтчел, капчыгын төзәтә, җайлабрак куя, каешларын да рәтли. Секундлар чаба да, чаба.

— Таныйсызмы, Касыйм әкә?

— Чамалыйм да кебек, но мин тәкә түгел, туган.

Елмая, фуражкасын сала, кая эләргә җай эзли.

— Тәкә, димим, әкә, дим.

— Ялгышаммы, юкмы, Сез Такташ бит?

— Әйе, Касыйм әкә, мин Такташ, Рафаэль Такташ.

Нишләптер, изрәп төштем. Кулъяулыгымны алып, маңгай тиремне сөртеп алдым. Әллә нәрсә булды үзем белән. Күз алдымнан яшь чагым, рабфакта укыган чагым, 3 яшьлек Рафаэльнең агач атка атланып төшкән рәсеме-портреты үтеп китте. Хәзер минем алдымда атасыннан ике мәртәбә олы, киң маңгайлы, зур башлы, ак

сакаллы кеше басып тора. Йөзенә тагын бер карап алдым. Әйе, чырае нәкъ Такташныкы, әтисенеке, ә күзләре, күзләре яшькелт, Гөлчәһрәнеке.

— Түргә уз, түргә, Рафаэль, әйдә, әйдә, — дидем. Мин аны беренче мәртәбә 1928 елларда күрдем. Менә хәзер 1990 ел. Күпме язлар, көзләр үткән, ничә мәртәбә тәңкә карлы кышлар узган.

— Касыйм әкә, йомшарырга ярамый, бөтен нәрсә ага, бөтен нәрсә үзгәрә, — диде Рафаэль.

Чирек сәгатьтән без сый-нигъмәт куйган өстәл тирәсендә идек.

— Туганнар каберстанына, әти каберенә чәчәкләр куйдым, — диде Рафаэль.

Мин үз белгәннәремне сөйләдем.

— Мин әтинең авылында, Сыркыдыда да булдым, — дип дәвам итте Рафаэль. — Өй сакланмаган. Мордовия җөмһүрияте дә, Татарстан хөкүмәте дә нигезне саклау өчен чара күрмәгән. Казан каласында да әти яшәгән бина сакланмаган…

Без төрле хәлләрне искә төшердек. Рафаэль әнкәсе карамагында үсә. Ленинград сәнгать академиясен тәмамлый. Үзбәкстанда Сәнгать академиясендә эшли. Үзбәкстанның атаклы сәнгать галименә әйләнә. Әмма үзе турында сөйләргә яратмый. Әнкәсе Мәскәү университетының юридик факультетын тәмамлагач, прокурор, җаваплы партия хезмәткәре булып эшләгән. Сугыш елларында Үзбәкстанның юстиция министры булып хезмәт иткән.

Без озак сөйләштек. Аннары ул Иделгә, дачага китте. Аның авыр йөге рәссам кораллары булган икән. Ул ясаган рәсемнәр, пейзаж, табигать күренешләре җәмәгатьчелеккә яхшы мәгълүм, сәнгать турында язган кайбер мәкаләләре чит телләргә дә тәрҗемә ителгән.

Соңгы сүз итеп шуны әйтик: тарихка фальш-ялган кермәсен. Зур ша-

Һади улы Рафаэль белән. Казан. 1920 нче еллар

гыйрь вафат булганга 60 ел үтте. Әмма, ни кызганыч, бер матди истәлек тә юк. Шул да мәгълүм булсын: каенатасы Хафиз 1940 елда җир куенына керде (Ташкентта). Такташның җәмәгате Гөлчәһрә 1957 елда Мәскәүдә дәфен кылынды. Каенанасы Зәкия 1979 елда 81 яшендә Чаллы каласында вафат булды. Такташның нәселен ике улы — Рафаэль вә Аван* һәм шагыйрьнең оныклары дәвам итә.

Коръәндә бик кыска бер аять бар. «Адәм баласы һәрвакыт хәсрәткайгыда. Әгәр дә иман китерсә, хаклыкны, гаделлекне васыять итсә, ул бәндәнең гамәле изге».

Менә шулай. Юкны — бар, димик, барны — юк, димик. Тагын мондый сүз дә бар: имеш, Такташка тәрәзәдән атканнар, диләр. Бу — нигезсез, уйдырма сүз.

Касыйм Хәмзин

*Һади Такташның уллары Рафаэль дә, Аван да инде вафат. — Ред.

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

ИБНЕ ХАЛДУН (1332-1406) — Вәли-әд-дин Габдеррахман Әбү Зәйд әл-Мәлики әл-Хәлрами (тулы исеме башкачарак күрсәтелгән чыганаклар да бар). Күренекле гарәп тарихчысы, социолог һәм философ. Туниста туган, чыгышы ягыннан затлы гаиләдән түгел. Туган шәһәрендә Коръәнне, хәдисләрне, фикъһене һәм грамматиканы өйрәнгәч, Фәс солтанында хезмәттә була. Анда сарайдагы эчке низаглардан туеп, Испаниягә китә (1362) һәм биредә гарәп идарәчеләренә хезмәт итә, аннары янә Туниста һәм Фәс шәһәре хакимнәре сараенда хат йөртүче булып эшли. 1382 елда Каһирәдә башта мөдәррис (профессор) хезмәтен башкара, аннары аны баш казый итеп сайлыйлар. Гадел булганлыктан, Ибне Халдунның шәхси дошманнары күбәя һәм аны берничә тапкыр хезмәтеннән дә азат иткәннәр, ләкин яңадан чакырып алалар. Аксак Тимер Сүриягә басып кергәч, Ибне Халдун, Мисыр солтанын Сүриягә озата барып, Аксак Тимергә баш ия. Ибне Халдунның нәзакәтьлелеге Урта Азия әмиренең күңеленә хуш килә һәм ул аны Мисырга элекке хезмәтенә — казый итеп җибәрә (1400).

Ибне Халдун тарихчы-прагматик буларак дан казанган.

«Китаб әл-гыйбарә...» («Гыйбрәтләр китабы...») дигән зур хезмәтенең «Кереш» («әл-Мокаддимә» — русчага «Пролегмоны» дип тәрҗемә ителгән) бүлегендә Ибне Халдун тарихка карата, хәзергечә әйтсәк, структур анализ ысулын кулланып, мәдәниятләр тәгълиматын бәян итә.

Галимнең фәнни методы — «вакыйгаларның сәбәпләреннән һәм фактларның үзләреннән дөрес сабаклар алу», ә эш принцибы — «ялганчы демонны гакыл чырагы белән җиңү» булган.

Ибне Халдун фикеренчә, ***тарих***

* Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынннан басылып килә. Автор искәрткәнчә, «...бу сүзлекнең чирек өлеше 2007 елда «Мәгариф» нәшрияты тарафыннан 1000 данәлек тираж белән бастырып чыгарылган иде».

милләтләрнең туу, аларның куәткә ирешү, әкренләп зәгыйфьләнү һәм түбән төшү чорлары кабатлана торган циклдан гыйбарәт. Ибне Халдунча, шәһәр — мәдәни җәмгыятьнең нигезе. Шәһәр кешесе нәзакәтьлерәк һәм ачыграк булганга, ул сугышырга яратмый һәм шул ягы белән бәдәвиләрдән көчсезрәк. Туганлык җепләре белән бәйләнгән бәдәви кабиләләр шәһәрне бик җиңел буйсындырганнар, ләкин дүрт буын алмашынуга шәһәр аларны «боза» һәм алар үзләре яңа буын бәдәвиләрдән җиңеләләр. Тарихта цикллы кабатланулар һәм географик мохитнең мәгълүм бер роль уйнавы турындагы фикере белән Ибне Халдун XX гасырның күренекле тарихчысы Лев Гумилёвның теориясен хәтерләтә. Хәер, тарихтагы цикллар турындагы концепция, милләтләрнең тууы, куәткә ирешүе, әкренләп артка китүе, түбән тәгәрәве, аннары яңарыш кичерүе турындагы фикер Библиядән үк килә. XVII–XVIII гасырларда яшәгән итальян тарих философы Вико Джамбатиста да халыкның балалык чоры — каһарманнар чоры — яшьлек белән алмашына, аңа алмашка җитлегү чоры — гуманитар (кешелек) дәвере килә дип күрсәтә. Аның идеяләре Н.Данилевский, К.Леонтьев, О.Шпенглер һәм, мәгълүм дәрәҗәдә, А.Тойнби фикерләренә якын. *«Империяне кулга төшергәннән соң, — дип яза ибне Халдун, — җиһангирлар үзүзләрен алҗытуга биреләләр... Алар гөлбакчалары һәм фонтаннары булган сарайларга хуҗа булып... Аллаһның әмер биргәнен (көтеп яталар)... Иртәме, соңмы империяләргә картлык килеп җитә, алар да, кешеләр кебек үк, үсәләр, җитлегәләр, ә аннары түбән тәгәри башлыйлар».* Тарихта кабатланулар идеясен аңа кадәр Бируни әйтеп чыккан булган (973-1048).

Шунысы кызык, Ибне Халдунның әлеге фикерен XIX гасыр Казан математигы Н.Лобачевский сүзгә-сүз диярлек кабатлый. Тарихи үсештә кабатлану идеясен Карл Маркста да очратырга мөмкин. Татар әдибе Фатих Кәрими: *«Чөнки тарих — гайне вакыйганың әзманаэ мөхтәлафә [төрле заманнарда] вә әмкянаэ мөгаддә [бик күп урыннарда] тәкрарыннан гыйбарәттер»*, — дип язган (1904). Безнең көннәрдә Н.Д.Морозов тарихтагы ритмлы кабатлануларны тикшергәч, «Бу дөньяда бөтенесе дә алдан ук хәл ителгән һәм билгеләп куелган һәм тормыш китабы әллә кайчан ук язылган», — дигән фикергә килә («Ритмы истории», М., 2001). Ул хәтта киләчәк заман формуласын чыгара алдым, дип саный һәм, асылда, пәйгамбәрлеккә дәгъва итә. Әйтергә кирәк, аның бу китабында акылга муафыйк фикерләр белән беррәттән, хыялый, мистик һәм астрологик фаразларга нигезләнгән нәтиҗәләр дә тулып ята.

Югарыда телгә алынган китабының башка бүлекләрендә Ибне Халдун дөнья яралганнан алып, Мөхәммәд пәйгамбәргә кадәр булган тарихны бәян итә, Африкадагы һәм Испаниядәге гарәпләр, аннары берберлар, Мисырда һәм Азиядәге вак мөселман династияләре турында яза. Аның хезмәтендә Алтын Урда дәүләте һәм Җүчи олысы тарихы да (Туктамыш ханга кадәр) яктыртыла, ләкин галимнең игътибар үзәгендә мәгъриб илләре һәм халыклары тора.

«Цивилизация — яманлыкның гәүдәләнеше ул» дигән ачы фикер дә Ибне Халдунныкы.

Ибне Халдун яһүдиләрне җир йөзендәге иң затлы кавемнәрдән саный, чөнки Ибраһимнан алып Мусага кадәр барлык пәйгамбәрләр дә яһүдиләрнең ата-бабаларыннан чыкканнар, ди ул. *«Хәзерге еврейләрнең мәкерлелеге һәм каты күңеллелеге — аларның илдән куылуы, башкаларга буйсынуы һәм тормыш итү шартлары нәтиҗәсе»*, — дип яза Ибне Халдун. Аның фикеренчә, бу милләт инде бер тапкыр яңарыш кичергән, шушы нәрсә аларның тарихны ничек күзаллавын билгели һәм киләчәккә перспективалар ача.

1883 елда татар галиме Ш.Мәрҗани, Ибне Халдунга ияреп, «Мөкаддимә» исемле әсәрен бастырып чыгарган.

ИДИШ — Атама урта нимес теленнән (yudisch — йәһүди), башкача — маме лошен («әңкәй теле», ягъни ана теле). Йәһүдиләрнең ашкеназ(и) төркеме сөйләшә торган тел, урта гасырларда нимес грамматикасы һәм борынгы гыйбрани (еврей) теле нигезендә оешкан. Кайбер галимнәр (мәс., Векслер) фикеренчә, идиш телен, герман төркеменә кертү белән бер үк вакытта, 15 нче славян теле дип тә карарга мөмкин, имеш.

1919 елда Мәгариф халык комиссариаты идиш телен «еврейләрнең бердәнбер дөрес теле» дип игълан итте (чөнки еврей пролетариаты шул телдә сөйләшә бит!), ә иврит, буржуаз һәм дини элементларның коралы буларак, законнан тыш дип карала башлады. 1920 елларда СССРда идиш телендә укытыла торган мәктәпләр, институтлар барлыкка килде... Ләкин 1930 елларда инде, Сталинның милли сәясәте кискен үзгәреп, еврей мәктәпләре, музейлары, нәшриятлары ябылып бетте.

Холокост елларында һәм СССРда антисемит сәясәте үткәрелү аркасында идиш теле бетүгә йөз тота һәм 1948 елда Израиль дәүләте оештырылганнан соң кабат торгызылган иврит теле тарафыннан тәмам кысрыклана.

Шулай да XX гасырның 90 нчы елларында идиш теленә игътибар яңадан артты дияргә мөмкин, чөнки бу тел еврей халкы тарихында шактый зур урын тота һәм, икенчедән, Украина, Белоруссия, Литва, Россия еврейләре идиш телендә аралашалар, АКШта яшәп калган еврейләр дә үз җәмагәләрендә шул телдә сөйләшә. Дөрес, яшьләр иврит телен өйрәнүне артык күрәләр һәм, кайберәүләр фикеренчә, киләчәктә идиш үле телгә әйләнеп, латин, санскрит һәм борынгы рус телләре белән бер рәткә басарга мөмкин.

XIX гасыр-XX гасыр башларына караган еврей әдәбияты башлыча идиш телендә язылган.

Тагы шунысы кызык, XX гасыр башында Одесса бандитлары идиш телендә сөйләшүдән полицийскийлар аңламый торган борынгы гыйбрани телдә сөйләшүгә күчәргә карар кылганнар. Мәс., бүген дә еш очрый торган жаргон сүз ксива (документ, белешмә) шул кадими еврей теленнән алынган.

ИСКЕ ДАМБА тар. – Иске Казанда Адмиралтия бистәсен һәм «Усияне» (русча Устье – Казансу тамагы) шәһәр белән тоташтыра торган дамба. Аны 1847-1849 елларда төзиләр һәм

Идел пристаньнарын Бакалтайдан яңа урынга күчерәләр. Беренче пароходны Казан 1820 елларда күрә. 1875 елда дамба буенча атлы тимер юл төзелгәч, шәһәрдән пристаньга кадәрге җиде чакрымлык юл беркадәр уңайлаша. Ләкин шәһәрдән Усиягә кадәр юл, җиңел извозчикка утырып барганда да, кимендә 45 минут вакытны алган.

Усия пристане язгы ташу беткәч тә эшли башлап, пароход һәм баржаларны навигация ахырына кадәр кабул иткән.

ИСЛАМ ҺӘМ ЛЕВ ТОЛСТОЙ — Бөек рус язучысы һәм фикер иясе, Петербург Фәннәр Академиясенең шәрәфле әгъзасы граф Лев Николаевич Толстойның (1828–1910) православие диненә тәнкыйди карашы күпләргә билгеле. Шуның аркасында ул рус чиркәвеннән куылып, анафемага сөрелә. Бик күп эзләнүләрдән, уйла-

Лев Толстой



нулардан соң, Лев Толстойның иманы Исламияткә якынайган.

Мөселман кешесенә кияүгә чыккан рус Е.Вәкиловага 1909 елның 15 мартында Ясная Полянадан язган хатында Лев Толстой түбәндәгеләрне әйтә: *«Сүзләрем ничек кенә сәер тоелмасын, христиан идеалларын һәм христиан тәгълиматын асыл мәгънәсендә югары куйганым хәлдә, минем өчен мөселманлыкның тышкы формалары чиркәү православиесеннән чагыштыргысыз өстен торуы шиксез-шөбһәсез. Шуңа күрә, әгәр кеше каршына икенең берсен генә: йә чиркәү православиесен, йә мөселманлыкны тотарга дигән шарт куела икән, гакылы булган һәр кеше боларны сайлаганда шикләнмәячәк һәм һәркем теге катлаулы һәм аңлаешсыз илаһият — Өчлек, гөнаһны йолу, чиркәү сирриятләре, изгеләр һәм аларның сурәтләре, Аллага катлы-катлы дога кылулар урынына бер иманны, бер Алланы һәм аның пәйгамбәрен таныячак…»*

Ә 1884 елгы бер хатын ул түбәндәге сүзләр белән тәмамлый: ***«Һәм шуңар күрә миңа хак мөселманга караган кебек карагыз, шулчагында бөтенесе әйбәт булыр»***.

Даһи фикер иясенең бу сүзләренә комментарий кирәкми торгандыр.

1908 елда Лев Толстойның юбилей көннәрендә Казан мөселманнары аңа тәбрик телеграммасы сугалар. Телеграммага ике йөз мөселман кул куя. ■

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1915 елның гыйнвар ае

Текстны һәм искәрмәләрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Мәҗрухләр карендәшләрен бушлай йөртү

Шифаханәләрдә ятмакта булган мәҗрухлар янына хәл белергә, күрешергә килү вә алар яныннан китү өчен мәҗрухларның якыннарына арзан бәһа белән яки бушлай тимер юлларда йөрергә билет сорап, төрле идарәләргә чиксез күп мөрәҗәгатьләр булган. Бу мөрәҗәгатьләр мәҗрухларны вә гаскәри гаиләләрен химая өчен булган мәркәзи комитетларга җиткәч, бу хосуста Юллар нәзарәтенә мөрәҗәгать ителеп, махсус киңәшүләр булган вә изахлар [аңлатма] бирелгән. Бу хосуста пайтәхеттәге [башкаладагы] мәзкүр идарәләрнең карары вилаять валисе [губернатор] аркылы шәһәр главасына хәбәр ителгән. Бу изахка караганда, гаскәргә алынган гаилә башлыгына гаиләсенә, туган-үскән җирләренә кайтырга гына бушлай билет бирелеп, мәҗрухларның карендәшләренә мәҗрух янына килеп-китү өчен бушлай да, арзан бәһа белән дә билет бирелмидер. Шәһәр управасы бу изахны шәһәр шифаханәләрендәге мәҗрухларга белдерергә карар биргән.

Тыйбби ярдәм җәмгыяте

Шәһәр идарәи мохтәриясенә мөрәҗәгать итеп, төннәрдә нәүбәттә [чиратта] торган табиблар авыруларга ашыгыч ярдәм бирергә чакырылып урамга (Балык базарына) чыксалар, нәүбәттә торырга тиеш булган извозчиклар табу мөшкел булганлыгыннан зарланалар вә шуның өчен шәһәр бу урында извозчикларны нәүбәттә торырга мәҗбүр итә алмасмы, яхуд шәһәр кәрванының атларын җигеп махсус арба куярга муафикъ табылмасмы, диеп үтенгән.

Кояш. — 1915. — №597. — 5 гыйнвар.

Дәлил шәргый

Казан мөселманнары, мөселман бәйрәмнәрендә кибет ябуга мөсагадә ителүен [мөмкинлек булуын] үтенеп, Сенатка мөрәҗәгать итү өчен мөселман бәйрәмнәре хакында әсаслы [нигезле] дәлил табуда читенлек күргәннәр иде. Казан муллалары фәтва әзерләп торсалар да, Идарәи рухания[1] бу фәтваларны тасдыйк итүне [раслауны] кичектерә килә иде. Инде хәзер Габдрахман әфәнде Кушаев[2], Уфага баргач, Казан муллалары тарафыннан табып җибәрелгән фәтваларны Идарәи рухания вә мөфти хәзрәтләреннән тасдыйк иттереп алып кайтуга муаффәкъ булган [ирешкән]. Бу фәтвалар Сенатка күндерелә торган үтенечкә ляихә[3] буларак җибәрелергә уйланадыр.

Кояш. — 1915. — №599. — 7 гыйнвар.

---

[1] Идарәи рухания — Духовное собрание, Диния нәзарәте.

[2] Кушаев Габдрахман Габдулла улы (1862-1917дән соң) — сәүдәгәр. Бу вакытта «Мәрҗани» мәчете һәм мәдрәсәсенең җәмәгать идарәчесе.

[3] Ляихә — берәр эш яки закон өчен төрле яктан карап, тикшереп әзерләнгән тәкъдим.

50 еллык хатирә

Гыйнварның 10ында, сәгать бердә, шәһәр думасы залында шәһәр көтебханәсенең 50 ел дәвамы хатирәсе (юбилей мәрасиме) үтте. Дума әгъзаларыннан бик аз кеше килгән вә мөселманнардан 3 кеше хазир булган иде. Епископ Анатолий иштиракы [катнашы] белән булган дога мәрасименнән соң, шәһәр главасы көтебханәнең 50 ел кылган эшләре хакында мәгълүмат бирде. Вилаять валисенең [губернаторның] мәҗлескә килә алмаганга игътизарын [гафу үтенүен] вә көтебханәгә тәрәккый вә дәвам теләгәнен гарыз итә [белдерә]. Петроград көтебханәи шаһанәи гомумиядән[4], Харьков шәһәр көтебханәи гомумиясеннән[5], Казан университеты табигыят шөгъбәсеннән [бүлегеннән], Рухани семинария ректорыннан тәбрик итеп килгән телеграммалар укыла. Моннан соң университет ректоры, Рухани академия вәкиле сыйфаты илә епископ Анатолий, ибтидаи [башлангыч] мәктәпләр инспекторы, университеттагы асаре гатика [археология] җәмгыяте вәкиле, университетның тәрбия вә тәгаллем [уку] җәмгыяте вәкиле, **мөселманнардан вәкил сыйфаты илә Һади әфәнде Максуди**, Ксения кызлар гимназиясе вәкиле, шәһәр халкы вәкиле сыйфаты илә Л.П.Антонов, мөгаллимнәр мәктәбе мөдире тәбрик итеп вә көтебханәгә арттырылуы матлуб [теләнгән] фикерләрен гарыз итеп [белдереп], нотык сөйлиләр. **Шәһәр главасы В.Д.Баронин**, һәрберенә мөнасиб [яраклы] җавап биргән арада, **мөселманнар арасында мәгърифәт тарату шәһәр Думасының вә шәһәр Идарәи мохтәриясенең иң теләгән нәрсәсе икәнен мөселман җәмәгасенә ирештерүне мөселманар вәкиле сыйфаты илә сөйләгән Һади Максудига хәвалә кыла [тапшыра]**. Шәһәр кешесе сыйфаты илә ирад ителгән [сөйләнгән] нотыкка җавапта, шәһәр малия [финанс] эшләре арткан нисбәттә, көтебханәгә шәһәр кешеләренә биреп җибәрү ысулы да кертеләчәген, **көтебханә өчен махсус бер йорт салыначагын** хәбәр бирә. Епископ Анатолий тарафыннан «Рухани академиянең тарихы» дигән өч җилдле [томлы] китап һәдия [бүләк] ителә.

Шәһәр көтебханәсендә бу көндә 30 мең җилд китап бар икән. Моннан башка, шәһәр көтебханәсенең, 1906 нчы елның 2 нче гыйнварында ачылган «Мөселман көтебханәсе» шөгъбәсендә 1302 җилд китап бар. Бу шөгъбәне тәшкил итүгә 590 сум мәсариф [чыгым] тотылган вә һәр ел гәзитә-журнал вә китаплар алуга 300шәр сум бирелә килә. Ачылганнан бу көнгә кадәр 2500 сум кадәр мәсариф тотылган.

Татарча театр

8 нче гыйнварда «Шәрык» клубында Габдулла Кариев тәхте риясәтендәге [җитәкчелегендәге] «Сәйяр» труппасы тарафыннан «Ачлык кушты»ның[6] 1 пәрдәсе, «Мөгаллимә»нең[7] соңгы 2 пәрдәсе тамашага куелды. Миһманнар [кунаклар] байтак күп иде. Уйнаучылар гомумән чибәр уйнадылар. Байкина урынына дәгъвәт ителгән яңа артистка Р.Гөлнар туташ, сәхнәгә яңарак чыккан кеше булса да, яхшы ук муаффәкыять [уңыш] казанды. Тамашага куелган әсәрләрнең дикъкать итәрлек бер хасыятьләре булса, ул да мәгънәләренә хәләл [зарар] килмәү хасыятедер: әсәрнең башы

[4] Петроград көтебханәи шаһанәи гомумия — Императорская публичная библиотека. Хәзерге Россия Милли китапханәсе.
[5] Харьков шәһәр көтебханәи гомумиясе — Харьковская городская публичная библиотека. Хәзерге В.Короленко исемендәге Харьков дәүләт Фәнни китапханәсе.
[6] «Ачлык кушты» — Я.Вәлинең 5 пәрдәлек драмасы.
[7] «Мөгаллимә» — Г.Исхакыйның 3 пәрдәлек драмасы.

уйналса да хәләл килми, бер генә пәрдә уйналса да хәләл килми, бөтенләй тамашага куелмаса да әсәр үзенең кыйммәтен югалтмый...

Кояш. — 1915. — №602. — 11 гыйнвар.

Мелла һәм мәхәллә кешеләре хөкеме

10 нчы гыйнварда Судебная палатада Мораса авылы имамы Габделбари Шакиров белән шул ук авыл кешеләре Нурулла Хәйрулла углы һәм Хәмидулла Галиулла углының хөкеме булды. Авыл кешеләре имам өстеннән, Габделҗаббар Шиһабетдинов дигән яше җитмәгән егеткә метрическая справка (яше тулган диеп) бирүдә гаепләп, судка биргәннәр. Судебная палата, бу эшне караганнан соң, авыл кешеләренең дәгъваларын хаксыз табып, имамны аклап чыгарды.

Кояш. — 1915. — №603. — 12 гыйнвар.

Аитова ханым мәктәбендә мәүлид кәне

Мәүлид көнендә Фатиха ханым Аитованың кызлар мәктәбендә хәтме Коръән мәҗлесе булып, кызлар Коръән укып, пәйгамбәребез рухына багышлаганнар. Аннан соң, мөгаллимәләрдән Рокыя туташ падишаһ хәзрәтләренә дога әйткән. Шушы догадан соң, шәкертләрнең бәгъзеләре пәйгамбәр с.г.в. хаятен [яшәешен], сыйфатларын һәм аның тәрҗемәи хәлен сөйләгәннәр. Шушы көнгә гаид [нисбәтле] шигырьләр укыганнар. Шулай итеп, бу мәктәп олуг бәйрәмне саф дини рухта, көненә муафикъ [туры килгән] рәвештә бик олуглап, вә шуның илә бергә балалар өчен һәм күңелле, һәм файдалы рәвештә үткәргән.

Фатиха ханым Аитовага тәшәккер

Фатиха ханым Аитова мәктәбенең шәкертләре сугыш мәйданындагы солдатларга бүләкләр җибәргән иделәр. Хәзер шул бүләкләрне алган солдатлардан Фатиха ханымга бик күп рәхмәт хатлары килгән. Шушы хатлардан берсендә: «Сезнең перәннекләрегез безне бик шатландырдылар, без аларны иртән чәй янында ашыйбыз. Искә төшерүегез өчен рәхмәт. Без, солдатлар һәм офицерлар (арабызда безнең дусларыбыз, безнең иптәшләребез булган мөселманнар да бар), сезгә тәшәккер итәбез. Сезнең бу мәрхәмәтегездән тулаем без бик мөтәәссир булдык [тәэсирләндек]», — дип язылган. Башка хатларда шул ук рухта булып, бу бүләкләрнең гаскәриләрне бик шатландырганлыкларын күрсәтәләр.

Кояш. — 1915. — №608. — 19 гыйнвар.

Татарча театр

19 нчы гыйнварда Новый клуб залында «Сәйяр» труппасы артистлары тарафыннан татарча спектакль куелды. Уйналган пьеса казанлы Фатих әфәнде Сәйфи тарафыннан язылган «Ямьсез тормыш»[8] исемле яңа пьеса иде. Пьесаның яңалыгына карамыйча, клубка халык никтер бик күп килмәгән иде.

Бу яңа пьеса хакында хәзергә тәфсилле бернәрсә әйтмичә, бары пьесаның хәзерге тормышның ямьсезлеген тасвирлаудан һәм татар зыялылары арасында бик куәтле үсеп барган милләтчелек мәсьәләсенә сәлбирәк [тискәрерәк] карап, татар зыялыларын авылга, халык арасына чыгып хезмәт итәргә дәгъвәт итүдән гыйбарәт булганлыгын, пьесаның шактый эшләнмәгән һәм

[8] «Ямьсез тормыш» — Ф.Сәйфи-Казанлының 3 пәрдәлек драмасы.

һәрбер мәсьәлә кузгатылып та, тәмам ителмичәрәк калганлыгын гына искә төшереп үтәмен. Пьесада татар яшьләренең араларыннан чит милләт кызларына өйләнүчеләргә мәгънәви нәфрәт игълан итүләре дә тиешсез иттереп пьесаның каһарманнарыннан сөйләттереләдер. Шуның шикелле зур, мөһим мәсьәләләр пьесада байтак кузгатылган.

Соңгы вакытларда «Сәйяр» труппасында бәгъзе бер алмашынулар да булган иде. «Сәйяр»дән киткән Байкина ханым урынына ике яңа артистка алынды. 19 нчы гыйнвардагы спектакльдә Саттар ролендә — Сакаев, Гажби ролендә — Фәйзуллин, Әминә ролендә — Фәйзуллина һәм Рашад ролендә Мортазиннар яхшы уйнадылар.

Пьесаның каһарманы Мөхәммәд ролендә — Тинчурин, Сахиб ролендә Мангушовлар үз рольләрен тәмам җиренә җиткерә алмадылар диярлек, яхшы ук йомшак уйнадылар. Тинчуринның бу рольдә йомшак чыгуы беренче мәртәбә мондый рольне уйнавыннан булса кирәк. Һәрхәлдә, киләчәктә Тинчуриннан бу рольне мөкәммәл уйный алуын көтәргә юл бар. Бары монологларны сөйләгәндә ачыграк һәм тиешле интонация иләнрәк сөйләргә, каһарманнан халыкка бер тәэсир калдырырлык итәргә тырышырга кирәк булачактыр.

Яңа артисткалардан Таждарова ханымның беренче чыгышы иде. Аның хакында киләчәктә өмид барлыгын, уенны уйный, хәзерге бәгъзе бер техническии кимчелекләрен бетерә алачагын әйтергә мөмкин. Ләкин Таждарова ханымга андый яшь кызлар роле бик үк килеп җитми төсле. Шуның өчен рольне алганда үзенә муафиграк [туры килгәнрәк] рольләр алуны тәүсыя [киңәш] итү урынсыз булмас, дип уйлыйм. Гомумән, һәр ике яңа артисткаларга рольләрне яхшырак өйрәнеп, сүзләрне калдырмаска һәм хәрәкәткә табигыйрак төс биреп, сүз илә хәрәкәт арасындагы галяканы [бәйләнешне] сакларга, карап торучыларның тәэсирен бозмас өчен, сәхнәдә урынсыз хәрәкәтсез тору кебек нәрсәләрдән бик сакланырга тәүсыя итәр идем.

Кояш. — 1915. — №611. — 22 гыйнвар.

Мәҗрухларны мәсҗедкә җибәрергә

Мәүлид бәйрәме җитәр алдыннан имамнардан бәгъзе берләренә Казандагы шифаханәләрдә дәваланмакта булган мәҗрух мөселманнардан: «Мәүлид бәйрәменә мәсҗедкә сорап алсагыз иде», — дип мөрәҗәгать иткәнлекләре вә бу мөрәҗәгатьләрнең вилаять валисе тарафыннан имин танылып, шифаханәләргә керергә мөсагадә [рөхсәт] ителгән ахунга озатылганы хәбәре булган иде. Моннан башка мәҗрухларның: «Мөселман юк җирдә, юк, диеп юанасың, әмма Казан кеби мөселман мәркәзе булган җирдә мәүлид бәйрәме вә җомга намазы кеби олуг көннәрдә гыйбадәтханәләргә бармау һәм дә мөселманнарның килеп мәҗрухлар хәлен белмәүләре вә бәйрәм көннәрендә аларга мөрәҗәгать итмәү күңелгә агыр тәэсир итә», — дип, Казан халкыннан зарланып, имамнарга мөрәҗәгатьләр хәбәре дә ишетелгәләп тора иде. Инде хәзер шәһәрнең мәҗрухларны химая комитетына 6 нчы мәхәллә[9] имамы ахун Хисаметдин хәзрәттән мәҗруларны җомга көнәрендә мәсҗедләргә җибәрергә мөсагадә [рөхсәт] ителүен сорап гариза килгән.

Кояш. — 1915. — №613. — 25 гыйнвар. ■

[9] 6 нчы мәхәллә — Әҗем мәчете тирәсендәге мәхәллә.

КЫШ БАБАЙ ИНТЕРВЬЮ АЛА

Марсель Галиев

(Язучыларның «Тынгысыз каләм» дигән дивар газетасыннан)

МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ

Кыш бабай. Йә, энекәш, Яңа елга сезнең планнарыгыз?

Мәһдиев. Планнар матур. Мин бит университетта эшлим. Җәйгә абитуриенткаларны кабул итү миңа йөкләнгән.

Кыш бабай. «ка»лар дисең, кызларны гына аласызмыни?

Мәһдиев. Мин эшләгән елны шулай. Фәлән Фәләнеч булса, мәсәлән, гел әдәбиятне сүгүчеләрне, исәрләрне генә ала. Ә Фәлән Төгәнеч гел егетләрне генә кертергә тырыша. Гали Чокрый белән Кави Латыйпны гына бутамасын…

Кыш бабай. Шулай да татар мәдәниятенә кайсыгыз күбрәк файда китерә?

Мәһдиев. Без үзебез инде…

Кыш бабай. Фән өлкәсендә нинди планнарыгыз бар?

Мәһдиев. Яңа елда мин Тукайның «Гали белән кәҗә» әсәрен тикшермәкче булам. Толстой яки Гейне тәэсирендә язылмадымы икән, дигән шигем бар…

ИБРАҺИМ НУРУЛЛИН

Кыш бабай. Быел нинди ачышларыгыз булды, Ибраһим Зиннәтович?

Нуруллин. Гомерем буе эзләгән әйбергә ирештем. Теге… илле тәңкәне… Акчуриннан тәки алган бит… Тукай.

Кыш бабай. Алдагы елга планнарыгыз?

Нуруллин. Уральскийда иске бишмәт тапканнар. Шуның җөен санап кайтырга барасым бар. Тукайныкы түгел микән, дим…

АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ

Кыш бабай. Яңа елга нинди кәефләр белән киләсез, Аяз Мирсәедович?

Гыйләҗев. Гадәт буенча, каз, пилмән пешерәчәкбез. Хатынга әйтеп куйдым — 12 каз пешерергә, 1301 пилмән ясап куярга. Узган елны 6 каз, 651 пилмән иде, җитмәде.

Кыш бабай. Нигә алай күп?

Гыйләҗев. Чөнки без өйдә хәзер — ике драматург. Белмәссең, өченче малай да яза башласа, киләсе елга 18 каз кыздырырга, 1953 пилмән бөгәргә туры килер...

НУРИХАН ФӘТТАХ

Кыш бабай. Узган елдагы уңышларыгыз, Нурихан Садрилмәнович?

Фәттах. Без, хатын белән икәүләп, Фәүзия Бәйрәмованы «кыйнау» белән шөгыльләндек. Мин тәнкыйть кирәк, дип һәрчак сөйлим, ләкин мине тәнкыйтьләгез, дип әйтмим ич...

Кыш бабай. Яңа елга планнарыгыз?

Фәттах. Ишетүемчә, Фәүзия Бәйрәмованың университетта укучы тагын җиде сеңлесе бар икән әле. Аларын тарихи жанрда язарга кодалап булмас микән дим...

ГАРИФ АХУНОВ

Кыш бабай. Яңа елны нинди уңышлар белән каршылыйсыз, Гарифҗан Ахунҗанович?

Ахунов. Тукай премиясенә куелачак язучыга мәкалә язып ятам.

Кыш бабай. Кем буласы билгелемени инде?

Ахунов. Мин төзегән список буенча алар — ундүрт. Вакыты җиткәч, мәкаләгә исем генә өстим.

ЗӨЛФӘТ

Кыш бабай. Сезнең нинди уңышлар, Зөлфәт иптәш?

Зөлфәт. Ялтада өч табак шигырь язып кайттым.

Кыш бабай. Шәп булган. Анда шартлар әйбәт инде — язарга да язарга...

Зөлфәт. Диңгез суы тозлы икән шул...

МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ

Кыш бабай. Бик салкын бит, Мөдәррис иптәш, нигә юка пәлтә белән йөрисең? Поэмаң чыкты, акчаң мул, алып җибәр Миркасыйм Госмановныкы шикелле эче мехлы күн пәлтә!

Әгъләмов. Дүрт сум унике тиен чакта алмаганны, тугыз сум ун тиенгә менгәч, алып булмый инде ул.

АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Кыш бабай. Яңа елга нинди уңышлар белән киләсез, Азат Гыйльмуллович?

Әхмәдуллин. Мин соңгы елларда 20-30 нчы еллар әдәбиятын өйрәнәм. Гаҗәп кызыклы шәхесләр бар икән безнең әдәбитятта. Мисал өчен: Чинәкәй, Сәмави.

Кыш бабай. Ник. Алар икесе бер кеше түгелме соң, улым?

Әхмәдуллин. Ә?!

РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН

Кыш бабай. Иптәш Фәйзуллин, яңа елга планнарыгыз?

Фәйзуллин. Мин Италиядә Софокл һәйкәленнән артып калган мәрмәрне сөйләшеп кайттым. Исән чакта бюстны ясатып калдырырга кирәк. Гулливерлар шулай итә. Яхшы скульптор таба алмыйм әле. Кызганыч, монументалист Сикейрос үлеп китте. Минем белән контактка керергә өлгерә алмады мәрхүм. Контракт төземәкче идем.

РӨСТӘМ МИНГАЛИМ

Кыш бабай. Сез яңа елны ничегрәк каршылыйсыз, Рөстәм Мингалим иптәш?

Мингалим. Кайчан була соң ул?

Декабрь, 1986 ел

ХӘСӘН ТУФАН

ТАШ ЯУСА ДА...

Таш яуса да иртәгә
Очрыйм, дисәм, иркәмә,
Таш яумый да... яңгыр ява,
Белмим нихәл итәргә?..

Сулар сибәм суганга,
Яңгыр явып торганда,
Су буена төшкәләргә
Сәбәп кирәк булганга.

Тамчы су юк чиләктә,
Кыз да «сибә» җиләккә,
Җиләккә су сипкән булып,
Күренергә кирәккә.

Суган түтәл — сул якта,
Җиләк түтәл — уң якта.
Ул да чыкты, мин дә чыктым
Уртадагы сукмакка.

— Исәнмесез? — янәсе...
Сибәбезме — янәсе...
Әйтер сүзләр күп иде дә,
Истән чыкты һәммәсе.

Яңгыр әллә сизенде:
Сибелде дә сибелде...
Явымнарга юлыккан юл
Якты була шикелле?

Таш яуса да иртәгә
Очрыйм, дисәм, иркәмә,
Яңгыр ява. Яңгырда да
Мөмкин бит су сибәргә.

(«Юмор һәм сатира» дигән җыентыктан, 1966 ел)

Фәрит Вахитов һәм
Зөлфәт Хәйруллин шаржлары.

Мирасворд

Татар хатын-кызларының борынгы баш киеме

... — йомалак

Морза, түрә

Язучы ... Зәйнуллин

Батыр, куркусыз кеше (иск.)

Сиртмә

... — Килмәк явы

Урта гасыр гарәп, фарсы, төрки әдәбиятындагы жанр

Ашлык, он саклау өчен зур әрҗә

Гарәп артикле

Ерак басуда эшләүчеләрнең күчмә өе

... Тимергалин

Кашалот, нарвал

Пәйгамбәр

«... Содур» (Мөхәммәдъяр поэмасы)

Борынгы семитларда баш Алла

... Тайсон

... Базар (борынгы Болгарда сәүдә, һөнәрчелек бистәсе)

Жанна д' ...

... Әсфәндиярова

Борынгы Мисыр фиргавене

Усал, ачы ирония

... Корвалан

Урта гасыр хәзәр-кыпчак шәһәре

Нота

... Гаетбаев

Хуҗа, башлык

Мавритания акчасы

Шәйхи Маннур романы

Борынгы үзбәк

«Ул» алмашлыгының юнәлеш килеш формасы

Степан Разинның көрәштәше

Элмәк кидерү өчен аркылы агач

Чит, таныш түгел

1912-1918 елларда Казанда чыккан журнал

«Идегәй», «Манас»

Ш.Маннур премиясенең 1993 елгы лауреаты

... Минкина

Шагыйрь Рөстәм ...

Өйнең мәртәбәле урыны

Балкан ярымутравындагы борынгы дәүләт

Рәис Габдулла төзеде.

12 нче санда дөнья күргән мирасворднаң җаваплары:

Сулдан уңга: сөлес, Нури, «Манас», саба, ака, уйгур, денарий, Риза, Халиди, «Рух», кари, Тыва, Фаяз, Орхон, он, Анри, Ида, Кайбицкая, Ив, тугры, Аеш, тайм.

Өстән аска: Сәмәндәр, утрак, Лена, Нух, акча, ойрот, соса, кын, тат, Вахит, Киву, йарак, цигай, Ли, Рем, Насыйри, фа, Акыш, гид, Ания, Рабгузи, ярд, Ра, «Азиат».

Юнысов мәйданы. Мулланур Вахитов һәйкәле

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
Елъязмасы / гыйнвар

1000 ел элек (1015)

Бөек шагыйрь Йосыф Баласагуни дөньяга килә.

140 ел элек (1875)

5 гыйнварда философ, күренекле дин галиме, җәмәгать эшлеклесе һәм публицист Муса Бигиев (1875-1949) дөньяга килә.

120 ел элек (1895)

2 гыйнварда күренекле шагыйрь Шәехзадә Бабич (1895-1919) дөньяга килә.

95 ел элек (1920)

28 гыйнварда мәшһүр актёр Габдулла Кариев (Миңлебай Хәйруллин) (1886-1920) вафат була.

Шәрык халыклары коммунист оешмалары Үзәк бюросы органы — «Кызыл шәрык» журналының 1 нче саны (журналның редакторы — Борһан Мансуров, секретаре — Фатыйх Сәйфи-Казанлы) чыга.

90 ел элек (1925)

11 гыйнварда Татар дәүләт академия театрында Муса Җәлилнең «Бибкәй кыз» исемле музыкаль драмасы сәхнәгә куела.

80 ел элек (1935)

Таҗик китап нәшрияты Галимҗан Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романын таҗик телендә (тәрҗемәчесе — Х.Шукруллаев) бастырып чыгара.

65 ел элек (1950)

29 гыйнварда Казанда Шәриф Камалның квартира-музее (Островский урамы, 15 нче йорт) ачыла.

60 ел элек (1955)

Мәскәүнең Зур театрында Фәрит Яруллинның (1913-1943) «Шүрәле» балеты премьерасы була.

55 ел элек (1960)

Тукай районының (хәзер — Арча) Кушлавыч авылында Габдулла Тукай музее ачыла.

50 ел элек (1965)

«Совет әдәбияты» журналында Габдрахман Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романы басыла башлый.

Рөстәм Әхмәт улы Килдебәков 1934 елда Казан шәһәрендә туа. Казан сәнгать училищесын, Львов гамәли һәм декоратив сәнгать институтын тәмамлый. Ул — Татарстанның һәм Россиянең рәссамнар берлекләре әгъзасы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, халык рәссамы, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.

Рөстәм Килдебәков графика һәм монументаль сәнгать жанрларында иҗат итә. Аның әсәрләре Татарстанның, Каракалпакстанның һәм Россиянең шәхси вә дәүләти тупланмаларында саклана.



«Көзгеле кыз». 2014 ел. Киндер, майлы буяу

РӨСТӘМ КИЛДЕБӘКОВ

«Болгар манзарасы». 2013 ел. Киндер, майлы буяу

«БЕЗНЕҢ МИРАС» – 2015 ЕЛДА:

«Мөхәммәтгариф мулла язмаларында Морад хәзрәт зур ихтирам белән телгә алынган. Ул Морад мулланың мөриде (шәкерте) Заһидулла Миңлегул улының «Мөхтәрәм остазымыз Морад хәзрәт хакында» дип исемләнгән язмасын да күчереп алган. Язмада исә кызыклы гына хәбәрләр теркәлгән».
РАИФ МӘРДАНОВ. «КЕМ УЛ МОРАД МУЛЛА?»

«Күпләрнең: «Ленинград эше» бар, «Хәрбиләр заговоры», «Врачлар эше» бар, ә менә «Буа эше» хакында тәүге ишетүебез дип, җилкә уйнатулары ихтимал. Каһәрләнгән утыз җиденең көзендә бөтен республиканы шаулаткан процессны белмәвебез һич тә гаҗәп түгел».
ӘМИР КАМАЛОВ, ИСЛАМ ӘХМӘТҖАНОВ. «БУА ЭШЕ».

«Әйе, бу сугыш безнең кебек күпме баланы ятим итте, күз яшьләрен түктерде. Мин әтиемнең төс-кыяфәтен дә төсмерләмим. Аның хәтта фотосы да калмаган...»
ФОАТ ГАЛИМУЛЛИН. «ӘТКӘМ СУРӘТЕ».

Киләсе саннарда дөнья күрәчәк әтрафлы вә гыйбрәтле язмаларның кайберләре генә әле болар. Ерак гасырлардан сакланып калган һәм әле моңарчы дөнья күрмәгән тарихи, дини-иҗтимагый мирасыбыз, борынгы һәм хәзерге заман әдәбияты үрнәкләре, сәнгать әсәрләре быел да дөнья күрәчәк! Әле моннан тыш та янә ике яңалыгыбыз бар: күренекле галим Мәсгуд Гайнетдин Мифтахетдин Акмулланың безгә билгесез шигырьләрен тапкан! Икенчесе: Чыңгыз Айтматовның «Чыңгыз ханның ак болыты» исемле роман-эссесы татар телендә дөнья күрәчәк!

Индекс:
Татарстанда – 54132
Россиядә – 70275

4 612750 670172